**Рәзил Вәлиев**
КӨЗ БАЛКЫШЫ : ШИГЫРЬЛӘР

**Разиль Валеев**
ОСЕННЕЕ ОЗАРЕНИЕ

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
В97

**Вәлиев, Р.И.**

Көз балкышы : шигырьләр = Осеннее озарение : стихотворения / Разил Вәлиев ; [кереш сүз авт. : Р.Зәйдулла, Р.Мостафин]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 279 б.
ISBN 978-5-298-02050-3

Бу китапта Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты, күренекле шагыйрь, актив җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиевнең шигырьләре туплап бирелде. Аның җитди эчтәлекле, яшәү мәгънәсе һәм тормыш фәлсәфәсенә кагылышлы уй-фикерләр белән сугарылган романтик рухлы әсәрләре укучылар күңеленә хуш килер.

В этой книге собраны стихи талантливого поэта, активного общественного и государственного деятеля, лауреата Государственной премии Республики Татарстан имени Г.Тукая и Республиканской премии имени М.Джалиля – Разиля Валеева. Его содержательные, овеянные духом романтизма произведения о смысле жизни и философии бытия найдут отклик в душе каждого читателя.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02050-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Вәлиев Р.И., 2011

# Дулкын биеклеге

Монда давыл
Дулкын биеклеге белән үлчәнә.

*Разил Вәлиев*

Разил Вәлиев тыштан салмак, сабыр күренә. Салкын кырыслык чалымнары да бар сыман йөзендә. Түрәлек иткән кешегә – ә ул күп еллардан бирле халык депутаты, хәзер Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе – шундый кыяфәт килешәдер дә, бәлки. Хәер, ул читтән караганда гына шундый. Якыннан белүчеләргә исә Р.Вәлиев уенчак күңелле, үткен телле, җор кеше буларак билгеле. Аның теленнән төшкән канатлы сүзләрне, мәзәкләрне каләм әһелләреннән кем генә белми икән?

...Без, университетка кереп, тулай торакка урнашу белән, китап кибетеннән яшь шагыйрьләрнең шигырь җыентыкларын алып кайттык. Кайберләре авылдан ук ияреп килгән иде. Р.Вәлиевнең «Зәңгәр кабырчыклар» китабы да шулар арасында. Кич буе, алмаш-тилмәш кычкырып, шигырьләр укыйбыз, чагыштырабыз, бәялибез.

Шундый уен да бар иде: берәү кычкырып шигырь укый, калганнар аның авторын әйтергә тиеш. Янәсе, үзенчәлеклеме, шагыйрьнең үз стиле бармы?

«Зәңгәр кабырчыклар»да төрле шигырьләр бар, бүгенге күзлектән караганда, әлбәттә, кайберләре өйрәнчектер дә... Әмма авторның холкы, үзгәлеге аларда да ачык сиземләнә иде.

Бүген минем нәрсәләрем юктыр –
белмим...
Өметем бар ләкин,
түм-түгәрәк өметем –
күгем.

Түм-түгәрәк күк – Тәңре! Һәр шагыйрь шуңа якынаерга омтылмыймыни?!

Дөньяны йә үзен үзгәртү турында Р.Вәлиевнең каләмдәшләренә мәгълүм бер шигыре бар. Әдәбият сөючеләр белән очрашуларда ул аны сөйләми калмый. Җәлил дигәндә, «Җырларым» искә төшкән кебек, Р.Вәлиев дигәндә дә, шул шигырь хәтердә яңара:

Чәчәкләргә үз исемем бирәм,
Мең терелəм көнгә, мең үләм.
...Үлем белән якалашканда да,
Акны кара диеп сөйләмәм.

Менә ул шагыйрьнең холык-фигыле. Һәм ул гомере, эш-гамәлләре белән үзенең шигыренә тугры калды, киләчәктә дә шуңа хыянәт итәргә язмасын.

Мин Р.Вәлиевне һич тә аксакал буларак кабул итә алмыйм. Мин бит аның яшь, чем-кара чәчле чакларын да хәтерлим. Әле кичә генә кебек...

...Ундүрт яшемдә мин беренче мәртәбә Казандагы газета-журнал редакцияләренең ишеген кактым. Ишекләр ябык, бикле.

Шундый ишекләргә төртелеп йөри торгач, «Ялкын» журналы редакциясе урнашкан тугызынчы катка менеп җиттем.

Ниһаять, анда бер ачык ишек күренде. Түрдәге өстәлдә калын кысалы күзлек кигән сакал-мыеклы бер абый дөньясын онытып язып утыра. Бусагада озак кына күзәтеп торуымны сизмәде ул.

Күпмедер вакыт шулай басып торгач, мин кыяр-кыймас кына тамак кырып куйдым. Оялчан идем әле ул вакытта... Максатым бик мөһим булса да (шигырьләремне бер шагыйрьдән укыттырып бәясен ишетү), кешене эшеннән бүлеп йөрүнең килешмәгәнлеген аңлаганмын, күрәсең.

Күзлекле абый, сискәнеп, башын күтәрде.

Тавышымны көр чыгарырга тырыштым:

– Шигырьләр алып килгән идем...

– Бүген ял көне ич, – диде ул, гаҗәпләнеп. – Эшкә килүемне каян белдең?

– Мин язучыларның ял көннәре юк дип уйлаган идем.

Ул кычкырып көлде...

Разил Вәлиев белән шулай таныштык.

Әлбәттә, язучыларның ял көннәре юк. Әмма ул чакта Р.Вәлиев эш бүлмәсенә мәҗбүри килеп утыргандыр инде. Онытылып язар өчен, өстәлең белән бергә-бер калу кирәк бит.

Хәер, Р.Вәлиевне хәзер дә ял көннәрендә эшкә килә диләр. Ул – эш аты шул. Күрәсең, язар өчен, аңа күнегелгән даирә, эш иясенең почмактан карап торуы кирәктер.

Аның кабинетында берничә тапкыр булганым бар. Берөзлексез телефон шылтырый, сәркатип кыз кемнеңдер килгәнен хәбәр итә, әрсезрәкләр, ишекне ачып, башларын да тыгып карыйлар. Ә Р.Вәлиевнең һәркемгә вакыты җитә, ул барысына да игътибарлы булырга тырыша.

Шагыйрьләр арасында теләсә нинди эшне җиренә җиткереп башкара торган эшлекле кешеләр сирәк очрый. Р.Вәлиевнең исә һәр эшкә кулы ятып тора, шуңа күрәдер дә ул берниндидей авырлык алдында да югалып калмый. Университетка укырга кергәч, аңа тулай торактан урын бирмиләр. Шәһәрдә таянычы булмаган үсмер егет фатир эзли башлый. Шунда ул Казансу елгасы тирәсендәге урамда яшәүче Вәли бабай белән таныша. Бер иптәше белән шуның җимерек сараен «арендага» алып, алар аны идән-түшәмле итәләр, мич чыгаралар. Идәнгә хәтта, әрҗә такталарын ышкылап, паркет тезәләр. Җимерек алачык чын сарайга (!) әверелә. Шагыйрьләр, шәкертләр сараена!..

Затлылыкка омтылу Р.Вәлиевкә яшьтән үк хас була. Күрәсең, бу сыйфат та нәселдән килә торгандыр.

Аның бабасы каты холыклы, үҗәт, аягында нык басып торучы кеше була. Колхозлашу елларында картның бар малын тартып алалар. Юк, аны сөрмиләр, чөнки авылда тегермәннең рәтен белүче булмый. Ул үз тегермәнендә, ялланып, хезмәт хакы алып эшли башлый. Әмма колхозга керми. Гомерен ялгызак игенче, тегермәнче, тимерче, балта остасы булып үткәрә.

Максатчанлык, үз сүзен бирмәү дә Разилгә аннан һәм озак еллар колхоз рәисе булып эшләгән, республикада дан алган этисе Исмәгыйль абыйдан күчкәндер.

Яшьтән үк җәмәгать эшләренә маһир Р.Вәлиев үзгәрешләр чорында сәясәткә кереп чума. Казан шәһәреннән альтернатив сайланып, халык депутаты була. Ул милләтпәрвәрләрне борчыган мәсьәләләрне ил күләмендә күтәрә белә һәм бу юнәлештә көчен дә, вакытын да кызганмый. Милли мәнфәгатьләр Р.Вәлиев тормышының төп мәгънәсен тәшкил итә.

Кешедә милли рух ничек уяна соң?

«Түбән Камада мәктәптә укыганда, шәһәр малайларының, безне, авылдан күчкән малайларны, «татарва» дип мыскыллап, кыйнарга килүләрен күргәч, үз милләтем өчен ачыну хисе уянды», – ди шагыйрь. Күрәсең, милли язмыш турында гамьләнә башлау өчен ниндидер этәргеч кирәктер.

Иблис җанлы кешеләр таш атканда, яхшы кешене фәрештә канаты белән каплый, диләр. Ул фәрештәнең исеме Шигырь түгел микән? Бураннарда адашканда, Шигырьгә, Гаделлеккә булган ышаныч безне саклап калмыймыни, Тимерказык йолдызы булып күктә пәйда булмыймыни?..

Шагыйрь гомере – шигырь юлларында. Яшьлегендә Р.Вәлиев кысаларны җимереп ташлый, вәзен-кафияләрне санламыйча, алга ыргыла. Ул – ирекле! Тик өлкәнәя төшкәч кенә, шигырь кысалары эчендәге ирекнең тәмен-ләззәтен тулысынча тоеп буладыр, мөгаен. Хикмәт чәчелми, йөрәк кадәр генә булып күкрәк куышлыгына укмаша.

Р.Вәлиев шигырьләрендә көчле холыклы кешенең кулы сизелә. Көчле холыклы кешеләр генә шәфкатьле була ала. Үз-үзен яклый алмаган бәндәдән бүтәннәргә нинди шәфкать көтәсең... Ләкин шигырьләрдәге өмет-ышаныч, теләкләр сагыш төсенә өртелгән. Шагыйрь заманга да, хәтта табигатькә дә ярашып яши алмый. Шигырьләр шул үзгәлектән туа да инде...

Кабул булмый нигә бар теләгем? –
Бу дөньяда мин дә кеше бит.
Янып яшим, дөнья суык чакта,
Дөнья җылы чакта – күшегеп.

Кабул булмаган теләкләрнең, тормышка ашмаган өметләрнең көленнән ярала шигърият.

Р.Вәлиев беренче әсәрләре белән үк әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итә. Мәйданда киң колачлы, тирән акыллы, йөрәгендә хисләр давылы уйнаган язучының пәйда булуына беркем дә шикләнми. «Акыллы хис» шигырьгә генә сыя алмый, Мәскәүдә укыганда ук, ул «Эт кояшы» дигән бәян яза. Шунысын да әйтергә кирәк, үз заманы өчен шактый кызыклы алымнар белән язылган әлеге әсәр бик күп бәхәсләр уята. Беренче карашка анда бер мәхәббәт тарихы гына тасвирлана кебек, әмма тел астында бөтенләй бүтән сүз, бүтән мәүзугъ. Яшь автор һәркемнең үз дөньясы барлыгын, үз йөрәге кушканча яшәргә хакы булуын искәртә.

«Яшисе килә», «Иске сәгать дөрес йөри», «Мирас» бәяннары, бер-бер артлы шигырь китаплары чыга. Шагыйрь сүзләренә дистәләрчә көй языла, пьесалары сәхнәгә менә. «Ялкын» журналында саннан санга Разил абыйлары тәрҗемә иткән төрле халык әкиятләрен укып, балалар сөенә. «Начар кешедән яхшы шагыйрь, яхшы язучы чыга алмый торгандыр. Разилнең шигырьләрен тыңлаганда, проза әсәрләрен укыганда, мин шул турыда уйладым. Аның һәрбер әсәре халкыбыз язмышы өчен борчылып язылган, алар халкыбыз бәгыреннән өзелеп төшкән сыман», – дип яза шагыйрьнең дусты Илһам Шакиров.

Нурихан Фәттахның да шагыйрь турында әйткән сүзләре игътибарга лаек: «Минемчә, Разил Вәлиев – бүгенге көндә татарның иң күренекле, иң данлы һәм атаклы шәхесләренең берсе. Ул язучы гына түгел, сәясәт эшлеклесе дә, армый-талмый татарның бәйсезлеге өчен көрәш алып бара. Моның өчен без аңа һәрвакыт рәхмәт әйтергә тиешбез».

Шагыйрьлекне бизмән белән үлчәп булмый. Һәр шагыйрьнең йөрәгендә иярләнгән ат ята. Р.Вәлиев күңелендәге иярләнгән атның да, борын канатларын дерелдәтеп, каядыр билгесезлеккә ыргыласы киләдер...

Күпме илләр күрелгән, тик туган җирдә генә өмет кебек һаман түм-түгәрәк калган күк йөзеннән сирпелүче карлар керфекләргә үз итеп куна. Һәм, эреп, язга күчәсе моңга әверелә.

Ил-көн турындагы уйлар, сәяхәтләр хатирәсе ак кәгазьгә күчә. Шул шатлыкны, шул сагышны, гамьне тиздән без дә шагыйрь кебек үк кичерербез. Дулкыннар шавын йөрәгебез ишетер.

*РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА,*
*Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты*

# Материк поэзии

Мира живого живая частица,
Малоизвестный, но я – материк.
Хищник в горах моих диких таится,
Чистый в долине струится родник.

*Разиль Валеев*

### Творец своей судьбы

Последние десятилетия в татарской культуре – эпоха невозвратимых утрат. Ушли из жизни «последние мамонты» прежней «ледниковой» эпохи – скульптор Баки Урманче, композитор Назиб Жиганов, писатель и учёный-энциклопедист Наки Исанбет, крупные поэты Хасан Туфан и Сибгат Хаким... Возникло давящее ощущение вакуума, почти физически чувствуемой пустоты. Время идёт, а их место по-прежнему остаётся вакантным.

И всё чаще слышишь: нет, не то нынче поколение, не то... И писатели измельчали, и поэты выродились... Поэтому и интерес к литературе падает. А вот раньше...

Но стоит ли попрекать сегодняшние звёзды вчерашним солнцем? Ведь каждая звезда – такое же светило. Надо только приглядеться к ней внимательнее, рассмотреть её неповторимый блеск и сияние... Одной из таких по-своему прекрасных звёзд на небосклоне татарской поэзии является творчество Разиля Валеева.

Расцвет творчества Р.Валеева приходится на период Л.И.Брежнева, называемый также эпохой «обессиленного тоталитаризма». Диссидентом он не был. Но знал и гонения, и снятие с работы (в основном по наветам своих же коллег – «братьев-писателей»). Но как бы трудно ему ни приходилось, он никогда не поступался собственной совестью. И не терпел бессовестности, нахрапистости и карьеризма в других. За это, собственно, ему и попадало.

Перечитывая сегодня его произведения, видишь, что при всей кажущейся лояльности к режиму его творчество не укладывается в привычные каноны «соцреализма». Герой его лирики привлекает сложностью, противоречивостью характера. Это человек мятущийся, неудовлетворённый, одержимый стремлением изменить жизнь к лучшему.

Писатель не стремится к возвеличиванию своего героя, возведению его в ранг «неприкасаемых». Показывая жизнь в сочетании светлых и тёмных сторон, он избегает готовых штампов. Ибо знает, что упрощать действительность – значит опошлять её, сводить на уровень обывательского восприятия. А это означает смерть искусства.

Есть у настоящего искусства одна примечательная особенность. Оно требует, как говаривали в старину, искупительной жертвы. Нельзя стать кем-то, ничем при этом не жертвуя. Покоем, благополучием, семейным

счастьем... Писатель – творец своей судьбы, он сам выстраивает свою биографию. Так, Р.Валеев, оставив шумную столицу, где он окончил Литературный институт, вернулся в родную Казань. Через несколько лет, уже пустив здесь глубокие корни, завоевав и авторитет, и признание как поэт, прозаик и талантливый журналист, он бросил всё и уехал в Набережные Челны на стройку КамАЗа, чтобы быть ближе к реальной жизни, на себе ощутить её горячее дыхание. Он был единственным татарским писателем, который два месяца провёл в сражающемся Афганистане. Попадал в рискованные переплёты, которые едва не стоили ему жизни. Но об этом знают только самые близкие...

О творчестве Р.Валеева высоко отзывались такие признанные мастера, как Л.Ошанин, А.Гилязов, М.Магдеев, С.Хаким и др. Почти все отмечали философскую глубину его лирики. Поэт зримо и выпукло показывает, что каждый человек – целый материк. И вся необъятная Вселенная – в космосе его души. Его занимает философская проблема всеобщей взаимосвязи: человек как часть мира и мир в душе человека.

Каковы литературные пристрастия Разиля Валеева? Чтобы ответить на этот вопрос, достаточно просмотреть его переводы. Он перевёл на татарский язык «Маленького принца» А.Сент-Экзюпери, «Маугли» Р.Киплинга, рассказы К.Дойла, лучшие стихи поэтов разных национальностей: М.Лермонтова, Р.Гамзатова, К.Кулиева и др. Всех не перечислишь, но это действительно лучшее из нашего общего духовного богатства.

На протяжении всего своего творческого пути, поэт ищет наиболее ёмкое, образное, яркое определение любви. Любви ко всему живому, а не только к конкретному человеку. И горько сетует на то, что не может найти заветного слова. Но чувство любви живёт между строк его поэзии. Читатель это чувствует, осознаёт. Значит, главная цель поэтического слова достигнута.

## Поэт-песенник

Когда-то В.Хлебников провозгласил себя Управляющим Осью Земного шара. Если согласиться с тем, что ось земного шара проходит через сердце поэта, то придётся признать, что В.Хлебников был не так уж далёк от истины. Разве не сердце поэта заставляет Землю вращаться то быстрее, то медленнее? Разве не оно то подстёгивает время, то останавливает его, чтобы запечатлеть на века?

Я размышлял об этом, перечитывая сборник Р.Валеева «Разделим яблоко на пятерых». В сборник включены тексты наиболее популярных песен на слова поэта. Песни эти настолько у всех на слуху, что кажутся народными. Во всяком случае, легче вспомнить певца, в исполнении которого песня полюбилась, чем автора текста.

И это, наверное, не случайная аберрация памяти. В известном триединстве поэт – композитор – исполнитель первоначальный толчок почти всегда принадлежит поэту. Именно он вкладывает в песню душу, находит ведущий образ. Композитор даёт песне крылья, а исполнитель согревает её живым дыханием, обогащает неповторимыми интонациями. Широкая публика, как правило, награждает аплодисментами того, кто донёс до неё песню. Поэт же чаще всего остаётся в тени.

Вот почему я так люблю талантливого поэта и прозаика Р.Валеева, который, кроме того, был также толковым, по-настоящему болеющим за дело директором Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Любители поэзии знают его по сборникам «Синие ракушки», «Корень молнии», «Определение любви» и др. Более широкий круг читателей – по повестям «Собачье солнце», «Старые часы ходят верно», «Жить хочется». Наряду с этим Р.Валеев является самобытным драматургом, давшим второе дыхание жанру музыкальной комедии («Девушки-красавицы»), и вдумчивым, требовательным к себе переводчиком.

Обильный пласт творческого наследия Р.Валеева составляют прежде всего тексты песен. Их у него больше ста – я имею в виду те, что вошли в народ и стали самыми популярными. Музыку на его слова написали такие талантливые композиторы, как Ф.Ахметов, Р.Яхин, М.Яруллин, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Булгари, Р.Ахиярова, Ш.Тимербулатов и др. Тексты эти публиковались неоднократно. Последнее издание, вышедшее в издательстве «Рухият» и снабжённое нотами, называется «Ядкарь», что означает «Память». Это любовно изданная и отлично иллюстрированная книга.

Автор книги убеждён, что в песне живёт душа народа. Даже те, кто по тем или иным причинам утратил родной язык и отошёл от татарской культуры, всё же тянутся к национальной песне. По словам Р.Валеева, каждый раз, выезжая за рубеж, он берёт с собой кассеты с записями татарских песен – как своих, так и чужих. Лучшего подарка для представителей татарской диаспоры за границей не придумаешь. Люди, давно оторванные от своей исторической родины, слушают эти песни со слезами на глазах.

Именно через задушевную лирическую песню поэт прививает слушателям элементарные понятия о чести, совести, человеческом достоинстве, любви к своему народу и своей Родине. Достаточно вспомнить хотя бы его знаменитую песню «Ватаным», ставшую своего рода гимном татарского народа.

Чем же примечательно песенное творчество Р.Валеева?

Каждое время выдвигает своих поэтов-песенников. В тридцатые-сороковые годы это был А.Ерикей. Потом – М.Джалиль, С.Хаким, Н.Арсланов, М.Нугман. В настоящее время пальма первенства в этом жанре, без сомнения, принадлежит Р.Валееву. В его песнях – радость жизни и горечь неразделённой любви, упоение счастьем и лёгкая грусть, надежды и горе. Это песни настроения, воздействующие прежде всего на эмоциональный мир человека. Думается, вовсе не случайно его учителем и руководителем поэтического семинара в Литинституте был поэт-песенник Л.Ошанин.

Песни на стихи Р.Валеева льются свободно, естественно. Кажется, что они просто продиктованы сердцем. Так всегда бывает, когда за каждым словом стоит упорный труд – труд души.

Однажды в среднеазиатском кишлаке я видел, как худой, прокалённый солнцем пожилой узбек ощипывал и прореживал виноградные листья, плотным навесом окутавшие двор. Оказывается, чтобы урожай был добрым,

необходимо периодически обрывать лишние листья. И тогда ягоды, открытые свету, наливаются знойным и сладким солнцем. Не так ли и в поэзии?

Для того, чтобы стиль был светлым, прозрачным, гроздья слов наливались полновесной мыслью, надо лишь «удалить» всё лишнее, случайное. Вот эта краткость в сочетании с яркой и самобытной образностью и привлекает больше всего в песенном творчестве Р.Валеева.

**Тревога за судьбу нации**

Но и песни – только малая часть поэтического творчества Р.Валеева. За полвека творческой деятельности он издал десятки поэтических сборников, каждый из которых стал своего рода вкладом в духовную культуру татарского народа. Автор в своих стихах творит свой поэтический мир – вторую реальность. В этом многообразном мире есть место и страстному политическому призыву, и тихому нежному вздоху. Его стихи рассчитаны не на эстетствующих ценителей, а на самого обычного рядового читателя. В них нет никаких выкрутасов, никаких модных «измов». Всё предельно просто. Но в то же время в них всегда есть немного неба, то есть простора для мысли и воображения читателя. При всей кажущейся простоте поэт умеет избегать стёртых образов и автоматизированных поэтических приёмов.

Широта творческого диапазона позволяет поэту свободно переходить от исповедального монолога к доверительному рассказу о себе и своих сокровенных чувствах и мыслях. Задачу настоящей поэзии автор видит в том, чтобы изменить мир к лучшему:

Или мир я изменю сегодня,
Или сам сегодня изменюсь...

Есть поэты, целиком погружённые в мир чувств. И есть художники интеллектуального склада, выдвигающие на первый план мысли и идеи. Р.Валеева критики справедливо называют поэтом страстной мысли. В каждом его стихотворении провозглашается какая-то мысль. Но мысль, согретая жаром сердца. Каждое стихотворение – своего рода маленькая вспышка, рождённая органическим сплавом мысли и чувства. Чувства поэта предельно обнажены. Чеканные строки сами словно бы просятся на музыку. Вот это умение сплавлять слово и музыку – тоже одна из характерных особенностей поэта.

Когда читаешь его стихи, перед тобой встаёт образ человека твёрдых моральных устоев и философской глубины. Автор предстаёт перед читателями мягким, добрым, лиричным. Но в то же время несгибаемо твёрдым в отстаивании своих убеждений. Привлекает его внутренняя независимость даже в вязкие годы застоя. Так что со сменой идеологических ориентиров ничего из его сборников выкидывать не приходится.

Литературоведы любят рассуждать об этапах творческого пути того или иного автора. Но творчество Р.Валеева на редкость едино, цельно. Его поэтический дар был с ним изначально. Растёт лишь поэтическое мастерство, образная изощрённость, постепенно накапливается жизненный опыт и мудрость. При этом даже в самых поздних стихах автор остаётся молодым. Чувства его всё так же горячи и изначальны.

В прозе Р.Валеева преобладают те же излюбленные темы – любовь к родной земле и её простым трудовым людям, охрана природы, тревога за судьбу татарского языка и национальной культуры.

Но Р.Валеев не только талантливый писатель, но и крупный общественный деятель. В качестве народного депутата он ведёт неустанную борьбу за сохранение родного языка и национальной культуры. Каждое его выступление на заседаниях Государственного Совета отличается принципиальностью, страстностью, умением поднять животрепещущие проблемы и последовательно отстаивать интересы своего народа. В этом плане его можно назвать рыцарем без страха и упрёка.

**Внутренняя культура**

На мой взгляд, главная беда нашей современности даже не в бескультурье, а в поверхности этой самой культуры. Культурный слой у многих настолько тонок, почти прозрачен: поскреби немного, и перед тобой предстанет питекантроп, силой отнимающий то, что ему приглянется, считающий врагами всех, кто не принадлежит к его племени.

Когда я читаю стихи Р.Валеева, я думаю именно об этом – о внутренней культуре нашего современника, то есть о том, что, собственно, и отличает цивилизованного человека от дикаря. В стихах Р.Валеева настойчиво повторяется мысль о том, что культура человека – это его приобщённость к достижениям как своей национальной, так и всей мировой цивилизации, всего просвещённого человечества. Причём, прежде всего к коренным нравственным ценностям своего народа, моральным убеждениям нации. Поэт уверен, что задача поэзии в том и состоит, чтобы лучшее из того, что выработало человечество за долгие века и тысячелетия, стало внутренним достоянием каждого конкретного человека.

Культура может быть религиозной или атеистической, городской или деревенской, чисто национальной или общемировой. Она может опираться на внутреннее чутьё или книжные знания. Самое главное, чтобы у человека была прочно усвоенная и ставшая внутренним достоянием шкала ценностей, то есть то, что принято называть совестью. Именно к этому, казалось бы, эфемерному, понятию то и дело обращается поэт в своих произведениях. Он уверен, что усвоение нравственных ценностей должно начинаться с раннего детства. Усвоить самые простые, даже банальные истины – чтобы идти дальше. Ведь жизнь-то одна! Как же прожить её, если ты душой остался на уровне каменного века? Вот почему в творчестве Р.Валеева такое значение имеют стихи, собранные в этом двуязычном сборнике. Это предельно простые, искренние и добрые строчки, зачастую согретые мягкой улыбкой, без назидательности и скучного морализаторства. Поэтому они неоднократно переиздавались.

Вывод из всего сказанного один: перед нами – целый материк, материк поэзии. Как писал сам поэт:

Я – материк. Я зовусь Человеком.
Что бы моя ни сулила звезда –
ядерным взрывам и атомным рекам
не уничтожить меня никогда!

*РАФАЭЛЬ МУСТАФИН,*
*лауреат Государственной премии Республики Татарстан имени Г.Тукая, Республиканской премии имени М.Джалиля*

# Мизгел

Җир шарына утырып, тәмәке төрдем,
Җир шарына басып сүндердем.
Җир шарында арлы-бирле атлап йөрдем.
Санап чыктым барлык шатлыкларны,
кайгыларны.
Карап чыктым:
кемнең күзе йомык, кемнең ачык
һәм ни өчен.
Бизмәнләдем күз яшьләрен, таң чыкларын –
барын, барын, барын.
Онытып тордым йолдызларның
тик төннәрен януларын.
Бер мизгелгә
уч төбенә куеп тордым
бу Җир шарын.
Әйе, әйе,
мин бер мизгел
шагыйрь булып алдым.

# Мгновение

Облокотясь на шар земной,
курил, пуская кольца дыма
в беззвёздный мрак.
Затем слонялся
по островам и континентам
и сосчитал, как много горя,
как много радости на свете.
Я видел ясные глаза.
Я видел страх в глазах
закрытых.
И захотелось слёзы взвесить,
но слёзы продавили землю.
Искал звезду, забыв на миг,
что звёзды на рассвете гаснут.
Но не нашёл.
В ладони взял
свою огромную планету,
и на неясное мгновенье,
одно счастливое мгновенье
я стал поэтом.

* * *

Минем гомер әле башланмаган,
Мин дөньяга әле килмәгән...
Күкрәгемдә – әнкәм биргән йөрәк,
Иңнәремдә – әткәм күлмәге.

Шатлыгым да үземнеке түгел,
Үземнеке түгел кайгым да.
...Абыемның гомере кыска булган –
Бар хисләрен миңа калдырган.

Мин үткәннәр белән яшим әле...
Эзлим җирдә бабам бәхетен.
Ул менмәгән тауга мендем инде,
Ул үтмәгән озын юл үттем.

Үткәннәргә таба йөзне борып,
Күп таптармын әле бу җирне.
...Үземнекен түгел,
Язам әле
Шагыйрь язмый калган шигырьне.

* * *

Я жизнь свою ещё не начинал
Ни делом настоящим и ни словом.
И бьётся сердце мамино в груди,
Да и рубашка на плечах отцова.

Свою я чашу горя не испил,
Не знаю цену счастью и покою,
Как будто продолжаю брата жизнь.
Она была короткою такою.

Я весь – как будто прошлых дней завет:
Иду простором, что открылся деду,
И, одолев очередной подъём,
Я торжествую дедову победу.

Дожди времён, ветра веков во мне
Шумят, гудят неистребимой болью.
Пою ещё я не свои стихи,
А те, что до меня не спеты были.

## Яшьлек

Якорьларын онытып, юлга чыккан
бу корабта бары бер теләк:
соры ярлар алда күренгәнче,
бер исемсез давыл килеп
адаштырсын иде тизрәк.

## Молодость

На этом корабле без якорей
Одно желанье у его матросов:
Свирепый шторм пусть налетит скорей,
Чем к берегу теченьем их отбросит!

## Бәхет

Кыя ташка менеп, шигырь яздым –
Бу шигырем бәхет турында.
Хозурланып, тауда басып торам,
Болытларга башым орына.

Шундый якын миңа бар кешеләр,
Туган ягым кебек киң җиһан.
Ташлап киткән ярым кире кайтты –
Кулларына алсу гөл җыйган.

Иңнәренә шатлык йөге төяп,
Сизелми дә үтә ай, еллар...
Үзәннәрдә илләр сугышмыйлар –
Сугыш-сугыш уйный малайлар.

Уенчыклар тезеп, шук малайлар
Мәйданнарда ясый парадлар...
Диңгезләре – язгы ташу суы,
Бата анда кәгазь кораблар.

Кичләр җитсә, кулга-кул тотышып,
Әйлән-бәйлән уйный дәүләтләр...
Бар кешеләр шундый киң күңелле,
Бар кешеләр шундый әйбәтләр.

Хозурланып тауда басып торам –
Болытларга башым орына.
Кыяларга менми аңламассың –
Бу шигырем бәхет турында.

## Счастье

Взобравшись на скалу, я высек стих –
я высек стих о счастье. Он таков,
что я в лучах сияю золотых
и головой касаюсь облаков.

Сегодня люди все мне так близки,
на отчий край похож весь белый свет.
Вернулась из разлуки и тоски
любимая ко мне, в руках букет.

Груз радости на плечи положив,
легко проходят месяцы, года...
Внизу народы дружат, каждый жив,

лишь бьются пацаны, с ордой орда.

Игрушечно звучат «огонь!» и «пли!»,
гремит парад, играют марш и туш...
Бумажные уходят корабли
на дно морей, разлившихся из луж.

А вечерами водят хоровод
народы, взявшись за руки дружней,
и душу распахнёт любой народ,
и в круг само добро свело людей.

Мне хорошо, и белый свет хорош,
я головой касаюсь облаков.
А не взойдя на гору, не поймёшь,
что это стих о счастье. Он таков.

* * *

Кабул булмый нигә бар теләгем? –
Бу дөньяда мин дә кеше бит.
Янып яшим, дөнья суык чакта,
Дөнья җылы чакта – күшегеп.

Юлга чыксам, юрый-юрый барам,
Аяз торсын, диеп, гел көннәр.
Тик уемнан кире кайтаралар
Яңгыр көткән хәлсез игеннәр.

Кайнар җилләр исә, ә мин түзәм,
Басса да тир бөтен җилкәмне...
Беләм, чөнки диңгезләрдә шулчак
Бәхетледер кораб җилкәне.

Якты көннең тартам чабуыннан:
«Төннән куркам, китмә, ашыкма!»
Бу уйдан да кире кайтам тагын –
Сөенсеннәр, әйдә, гашыйклар.

Ачу килә кайчак тулган айга,
Йолдызларга, хәтта кояшка...
Ник минемчә түгел бернәрсә дә?! –
Шулай килә туа-тумыштан.

...Үземнеке тора онытылып:
Дус кайгысын бүләм иң элек –
Яшим шулай, кеше шатлыгына,
Кеше бәхетенә сөенеп.

* * *

Конечно, судьба не щедра на подарки...
И всё же подарки – не главный вопрос.
Бывает, продрогнешь ты в полудень жаркий
и жаром горишь в самый лютый мороз.

Бывает, ты радостно молишься небу
за то, что стоит ясных дней полоса.
Но вспомнишь, как тяжко деревьям и хлебу –
и молишь у неба, чтоб дождь пролился.

Бывает, от ветра сгибаешься вдвое,
дорога трудна, изнурителен путь.
Но вспомнишь про парус над мёртвой водою –
и ветер желанен, и думаешь: пусть!..

Ты ночи грядущей боишься и хочешь
бегущему дню натянуть удила.
Но вспомнишь влюблённых, язычников ночи, –
и просишь, чтоб ночь подлиннее была.

Бывает, что горе твоё – словно море,
и кажется, ввек его не переплыть,
но ты, забывая о собственном горе,
спешишь горе друга скорей разделить.

## Язгы шигырь

Ак каеннар арасына кереп,
Гел аклыкка чумып югалдың.
Ак каеннар янып көнләделәр,
Күреп күлдә чәчең юганың.

Мин көнләдем сине сөйгән өчен
Тып-тын торган күлнең суыннан.
Күктә – Кояш. Тик нигәдер синең
Күзләреңнең нуры суынган.

Имәннәргә карап телсез калдың,
Төз наратны алдың кочакка...
Бер мизгелгә шашып карап тордың
Ялкынланып янган учакка.

Урман кочагына кереп чумдың...
Сүз әйтергә хәтта базмадым.
Сине миңа көз китергән иде,
Алып китәр, ахры, язлары.

## Весенний стих

Ты берёзовой рощею шла,
И тебя белизна обступила.
А потом озерцо ты нашла
И в прозрачную воду ступила.

Ты взяла эти волосы где?
Ты задумчиво их распускаешь.
И тебя я ревную к воде:
Так меня ты к себе не пускаешь.

Вышла и прислонилась к сосне,
На дубы и осины смотрела.
Костерок дотлевал в тишине,
Только ветка сухая горела.

Солнце пусть остывает меж сосен.
Пусть продлится ещё тишина.
Хоть тебя подарила мне осень,
Но отнимет, наверно, весна...

## Гашыйк булгач

Бер тамчы су – төссез.
Бер бүлмә һава – төссез.
Океан – зәңгәр.
Күк тә зәңгәр.
Кайчандыр бу күзләр төссез иде...
Хәзер – зәңгәр!

## Любовь...

Капелька воды бесцветна.
Воздух, которым дышим, бесцветен.
А небо – синее-синее.
И океан – синий-синий.
Ещё вчера
твои глаза были для меня бесцветны,
а сегодня... синие.

## Ядкарь

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Уртак иде хисләр, айлы кичләр, –
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мең кат ятлады.
Үткәннәрдән бары шул җыр калды, –
Ул җыр безгә – яшьлек ядкаре.

## Память

Были мы вместе когда-то.
Годы – за молодость плата.
Память назад возвращает.
Судит. Но чаще прощает.

Что же, ведь были мы юны.
Ночи ведь были так лунны.
Многое не воплотилось.
Только и это простилось.

Ради немыслимой цели
Столько мы песен пропели.
Помню я эти мотивы.
Как они были красивы!

## Метаморфозалар

Карый-карый, күзем дөнья булды,
Үсә-үсә, дөнья күзгә тулды.
Ага-ага, инеш Идел булды,
Агып, томан булды Идел суы.

Үсә-үсә, имән бөре булды,
Бөре йөрәгендә чәчәк туды;
Ә чәчәкнең тәне орлык булды,
Җаны очты, сызылып калды юлы.

Үсә-үсә, сабый егет булды,
Әти булды әтисенең улы.
Үсте, үсте, бөтен нәрсә үсте,
Һәм дөньяда зур мәхәббәт туды.

## Превращения

Смотрел на мир – и миром очи стали.
Мир рос и рос – и захлестнул зрачки.
Река – она ручьём была вначале.
Туманом стало существо реки.

Дуб рос и рос – и стал одной из почек.
А в сердце почки родился цветок,
чья плоть, став семенем одним из прочих,
дух испустила в облачный поток.

Дитя росло – и выросло в батыра.
И стал отцом весёлый сын отца.
Всё выросло, во всех пределах мира
родив Любовь без края и конца.

## Яңгыр иле

Аяз иде күгем. Ялгыз идем.
Кавыштырды июль яңгыры.
Яшен яшьнәп, күкләр күкрәгән кич
Күңелемдә һаман яңгырый.

Мин китмәсен диеп яуды яңгыр,
Коеп яуды төннәр буена.

Онытылды үткән гөнаһлар да...
Яңгырда бит эзләр җуела.

Күзләр җитте. Хәзер тагын ялгыз
Йөзем куям яңгыр җиленә.
Минем өчен әле син һаман да
Күк күкрәгән яңгыр илендә.

Октябрьдә манма чыланып, мин
Эзләп йөрим июль яңгырын.
Шул яңгырлы төнне йөрәгемә
Җибәргәндер яшен тамырын.

## Страна дождя

Я с небом ясным был наедине...
Но вдруг проснулось небо в грозном гуле.
Под крышу грома ты пришла ко мне, –
Соединила нас гроза июля.

Хотело небо, видимо, чтоб ты
Навек осталась, светлая, со мною:
Был вечен дождь небесной высоты,
И прах земной венчал он с высотою.

...Не вечен был он. Осень подошла.
Я вновь один. Ищу тебя... Найду ли?..
Наверно, ты, пуглива и светла,
Осталась в нашем грозовом июле...

Октябрь! Молю! Меня в июль верни!
Мольба моя – о небеса! – не вздорна:
Вернись, июль! Ведь молнии твои
Глубокие пустили в сердце корни.

* * *

Мин күктәге йолдызларга гашыйк,
Булсалар да ерак.
Су төбендә – алар янәшәдә,
Ә мин үтәм урап.

* * *

Сколько звёзд во тьме высокой!
Нет числа!
Я решила, что достану –
Не смогла!
Воды реченьки глубокой
Звёзд полны!
Доставать я их не стану –
Не нужны...

## Алма

Алма өзелеп төште
Кызның уч төбенә.

Кем ташлады аны,
Кем ташлады?

Толымнарның тынычлыгын алды –
Кем ул анда, кем ул?

Керфекләргә таң чыклары тезде –
Кем ул анда, кем ул?

– Синме бу?
– Килдеңме?
– Синме?

Беркем дә юк,
Бернәрсә юк –
Бары җил генә...

Уч төбендәге алма
Тәгәрәде җиргә.

## Яблоко

Откуда это яблоко скатилось
В протянутую девичью ладонь?
И сердце в ожидании забилось,
И озарил лицо её огонь.

От этого таинственного света
Росинка на глазах её блестит.
– Любимый, это ты?
Но нет ответа...
Лишь ветер в кроне дерева гудит.

Как много было на ладони света!
Как он сиял!
И вот погас он вдруг...
– Любимый, где ты? Где ты?

Нет ответа.
И покатилось яблоко из рук...

## Мәхәббәт

Монда Кояш
океан төбеннән күтәрелә.
Монда сукбай һәм буйдак Ай –
кул сузымы җитә.
Монда давыл
дулкын биеклеге белән үлчәнә.
Монда болытларның күз яшьләре
иш янына куш кына бит.

Монда бар йолдызлар,
ике пар күз караганга, ахры,
бик якыннар һәм бик тоныклар.
Монда юллар, сукмаклар юк.
Монда адашканнар –
өметсез өметлеләр.
Монда төн һәм көн бар,
кыш һәм җәй юк.
Монда
    шигырь,
        шигырь,
            шигырь –
Шагыйрьләр юк.

## Любовь

Любовь! Земля особой стати,
Там солнце – руку протянуть!
Для шторма
        баллов там не хватит,
Там ветер, плача, рвётся в грудь.
Из туч высоких льются слёзы,
Печаль там – в радужном венце,
Там очи – словно в небе звёзды,
Там звёзды – очи на лице.
Там нет дорог, тропинок нету.
Там – лишь стихи.
И нет поэтов.

## Кабатлана язлар

Гел кабатлап йөрим йөрәгемә:
«Утың, – диеп, – сүнгән».
Тик шулай да үзем читләп йөрим,
Качып йөрим синнән.

Сынап карыйм инде ничәнче кат
Ихтыярым көчен.
Диңгезләргә барып егылдым мин,
Онытылыр өчен.

Кирәк түгел сөю сүзләре дә,
Кирәк түгел назың.
Гел кайтмаска диеп киткән инде,
Үткән инде язым.

Ә хыяллар – хыял гына алар,
Матур сүзләр – ялган.
Мин дөньяда беркемгә дә, ахры,
Бәхет бирә алмам.

Чәчәк төсен инде онытып барам...
Өстәлемдә – җикән.
Бу карсыз кыш минем кышым булыр –

Кара кышлар җиткән.

Тик йөрәгем разый түгел бер дә,
Миннән – иясеннән.
Нигә диеп читләп йөрим, имеш,
Качып йөрим синнән.

Нишләргә соң? Көзнең бар сагышы
Минем җанга инде.
Күңелемә хәзер пакьлек кирәк –
Мин бит кышта инде.

...Көтмәгәндә үзең очрадың син –
Тиле йөрәк хаклы!
Сүзләремне кире алам инде –
Мин йөрәгем яклы!

Тышауланган хисләр – ирек сезгә!
Йөрәк азса азар...
Юккамыни һәр ел саен җирдә
Кабатлана язлар.

## Вернётся весна

«Ах, чего не бывает весною», –
Говорю.
      И натужно смеюсь.
И тебя обхожу стороною,
И встречаться с тобою боюсь.

«То весна ведь была», – повторяю.
Повторяю: «То было давно...»
Я в пучину морскую ныряю,
Я забуду тебя всё равно.

Были яблони белыми всюду,
Расцветала повсюду сирень.
Что с того.
         Я тебя позабуду.
Не бывает весна каждый день...

Камыши раздвигаю рукою.
Лето кончилось.
         Завтра – домой.
Скоро снегом лицо я умою,
Буду признан студёной зимой.

«Буду, буду...» –
Опять повторяю.
А дорога назад – наяву.
И опять я ныряю, ныряю.
И опять, задыхаясь, плыву.

Дома нынче желтеют берёзы,

Но не зря обещают стволы,
Что метели придут и морозы,
Наши улицы будут белы.

Да, я выбегу, чтоб окунуться
В декабре на рассвете в пургу –
И с тобой не смогу разминуться,
И глаза отвести не смогу.

Опьянит ощущенье свободы,
Зазвенит молодая сосна,
Потому что уходят лишь годы,
Потому что вернётся весна.

## Соңгы үтенеч

Янәшәңнән үтеп киткәндә дә:
– Нишләп йөри бу, – дип
орышасың...
Миңа артык берни кирәкми бит,
бары
мине сөймәвеңә,
мин ышанган кебек,
сине сөюемә ышан син.

## Чтоб ты знала

Когда прохожу я мимо,
Сердито глядишь на меня ты,
«Чего тебе надобно?» –
будто
Мне говоришь своим взглядом.
Да нет, ничего мне не нужно.
Хочу, чтоб ты знала только:
Тебя я люблю так же сильно,
Как ты не любишь меня.

## Рәсем

Әйдә рәсем ясыйм әле –
Булсын бер кызык.
Томаны ак кәгазь булыр,
Яңгыры – сызык.

Аннары сине ясармын:
Яңгыр астында
Минем янга ашыгасың
Ак томан аша.

Күз ясармын, зәңгәр буяу
Табалсам әгәр, –
Чөнки синең күзләрең бит
Сагыштай зәңгәр.

Тын калырмын, күзләреңдә
Күренгәч яшьләр.
Шул чагында йөрәгемдә
Яшеннәр яшьнәр.

## Рисунок

Нарисовать тебя? Ну, вот:
Туман по ватману плывёт
Почти прозрачной полосой.
А это дождь идёт косой.

И ты – всё та же – под дождём,
Всё в том же платье голубом.
Набросок ты, ещё вчерне,
Но ты уже спешишь ко мне.

Держу я краску про запас
Для самых синих в мире глаз,
Для самых грустных глаз твоих,
Чего не выразит и стих.

Изображу твои глаза,
Но если в них сверкнёт слеза,
Её сотру я в тишине.
Тогда ты улыбнёшься мне.

## Вәгъдә

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым – шигырьләрем
Һәм дә кара икмәгем.

Күкне бирә алмам сиңа...
Йолдызсыз да итмәмен.
Айны бөтен көе саклап,
Сине, ахры, көткәнмен.

Шатлыкларым тулы килеш,
Кайгымны да түкмәдем.
Йортым тәбәнәк булса да,
Биек әле күкләрем.

Бәлки, бәхетле булмассың...
Бәхетсез дә итмәмен.
Оҗмах бирәм димим сиңа,
Тәмугка да кертмәмен.

## Обещание

Я тебе не обещаю рая.
Сам не знаю, с чем его едят.
Всё, что я имею, – предлагаю, –

всё, что я умею, чем богат!

Есть стихи в избытке, хватит хлеба.
Что ещё прикажешь для души?
Я тебе не обещаю неба.
Но звезду достану... Прикажи!

Что ещё имею за душою?
Невысок мой потолок... Прости!
Небо – высоко над головою,
значит – есть куда ещё расти.

Будешь ли счастливою, – не знаю.
Слёз твоих себе я не прощу!
Я тебе не обещаю рая...
Но и в ад, конечно, не пущу.

## Тамашачы бугай...

Син уйныйсың, һаман шаярасың...
Тик күзләрең моңсу.
Моңсу булгач күзләр, ничек инде
Җанда шатлык тусын?!

Күренмидер соры күзләреңә
Бу дөньяның яме.
Сөйлисең гел үткән гомереңне,
Ә киләчәк – ләм-мим.

Кайгыларың ерак яшергәнсең –
Рухың, ахры, көчле.
Тик тавышың көлгән чагыңда да
Үкси башлар төсле.

Кабызалмыйм сүнгән йолдызларың,
Баш очында юк Ай...
Синең тормышыңда мин бары тик
Тамашачы бугай.

## Зритель

Ты шутишь, смеёшься. А всё же
В глазах неотступна печаль.
Душа твоя словно не может
Осилить грядущего даль.

Ну что же мне сделать, послушай!
Как эту нарушить мне тишь?
Ты мне говоришь о минувшем,
О будущем грустно молчишь...

Ты где-то далёко, далёко –
В далёко ушедшей весне.
Тебе наяву одиноко,

Тебе сиротливо во сне.

Ты шутишь, смеёшься. А всё же
Я вижу трагедии свет.
Я зритель бездарный, быть может,
И мне недоступен сюжет...

* * *

Иң беренче төшкән карлар
Иң соңыннан эри, диләр.
Ә мин сиңа яз көнендә килдем,
Карлар эреп беткән чакта.

Иң беренче янган йолдыз
Иң соңыннан сүнә, диләр.
Ә мин сиңа таң атканда килдем,
Йолдызларың сүнгән чакта.

Күп еласаң, бер көләрсең,
Бик күп көлмә, бер еларсың, диләр.
Мин боларның кайсына да
Ышанырга белмим.

Тик онытма шуны:
Бу дөньяга
Көлеп килсәм киләм,
Ләкин елап үлмим.

* * *

Говорят, что первый снег
исчезает позже всех.
Я к любимой по весне
объявился, – стаял снег.

Говорят, поздней иных
гаснет первая звезда.
А на той заре от них
не осталось и следа.

Говорят, плакун-трава
рассмеётся только раз.
Ты смеёшься, ты права,
что в слезах не прячешь глаз.

Мыслей этих чехарду
не могу принять всерьёз.
Я со смехом в мир иду,
а покину мир без слёз.

## Гаепле

Барысына гаепледер, ахры,
Чал Иделнең яшел нараты.

Сине күрми узып китә идем,
Ул үзенә мине каратты.

Гаепледер, бәлки, кара төндә
Юл күрсәтеп торган якты Ай.
Сукмак булып ул алдыма ятты,
Колагыма дәште: «Якынай!»

Гаепледер аннан яр буеның
Кочагыңдай җылы ал комы;
Гаепледер тагын яңгыр, давыл,
Болыт, яшен, елга дулкыны.

Гаепледер, бәлки, урман җиле...
Көнләштереп, башта ул үпте...
Чыкмас идем Идел ярларына –
Үз йөрәгем, ахры, гаепле.

* * *

Всему виной весна. Она
Меня к реке сманила.
Цветущей свежести полна,
Тебя она явила.

А может, месяц виноват –
Тропинкой лёг под ноги,
И понял я, что нет назад
Ни тропки, ни дороги.

А может, ветер был виной...
Он губ твоих касался.
Коварный, будто надо мной
Смеялся, потешался.

А может, звёзд неясный свет...
А может, луч рассвета...
Весна... Тропинка... Ветер...
Нет!
Наверно, сердце это...

* * *

Сине эзләп, мин тауларга мендем,
Аннан аштым күккә.
Мин яратмыйм, имеш. Күрче менә –
Юкка синең үпкә.

Телисеңме, кара күк йөзендә
Булам янар йолдыз.
Аңладыңмы инде сөюемне,
Күктә дә мин ялгыз.

Наз кирәксә, битләреңнән сыйпап,
Җылы җилдәй исәм.

Хат язармын яшен уты белән,
Мин, дип, яшим, исән.

– Ышандыңмы инде сүзләремә,
Онытттыңмы үпкәң?

– Ышандым... тик минем күңел инде
Башкаларда күптән.

* * *

Взошёл я на крутые горы,
Небес коснулся я рукой
И, одолев степей просторы,
К тебе вернулся я рекой.

С лица ночного небосвода
Звездою падал я, скорбя.
Я стал частицею природы,
Любя одну тебя, тебя!

Дождём
        твоих волос коснулся:
Узнай меня, тебя молю!
И молнией я обернулся
И в небе начертал:
      «Люблю!»

– Поверь!
         Ужель тебе не верится:
Одна любовь в моей душе!

– Поверила...
         а только сердце
Другому отдано уже.

* * *

Син күрмисең, әйе, күрмисең син...
Үзең һаман алга барасың.
Ашыкмачы! Ялгыз үтеп булмый
Кайгы белән Бәхет арасын.

Син сизмисең, әйе, сизмисең син...
Син сизмисең: йолдыз атыла.
Җиргә карап, күрми каласың син,
Син күрмисең: күктә Ай тула.

Син тоймыйсың, әйе, тоймыйсың син:
Көзләр килә, аннан кыш була.
Салкын җилләр әнә ятып елый,
Ятып елый җилләр таш юлга.

Шулай күрми, сизми, тоймый гына,
Күңелең соң кая ашыга?!

Йөрәк җилең ятып елар әле...
...Минем йөрәк тиздән таш була.

* * *

Останься, проникнись участьем!
Виновен, быть может. Прости...
Дорогу к манящему счастью
Смогу ли один я найти?

Уходишь, не ведая даже,
Что падает наша звезда.
Уходишь всё дальше и дальше,
Неужто уйдёшь навсегда?

Неужто отныне на свете
Замолкнут навек соловьи?
Неужто не слышишь, как ветер
Рыдает о нашей любви?..

Неужто не знаешь: настанет
Весна, соловей запоёт?
Когда твоё сердце растает,
Моё превратится в лёд.

* * *

Көзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...
Өзгәләнмә юкка, эзләмә.
Хәзер инде, шәүләң күрер өчен,
Карарсың син минем күзләргә.

Күршеләрдән качтым, кешеләрдән...
Йөрәк һаман башны өйрәтә.
Дуслар да юк, дошман да юк хәзер...
Кереп адаш минем йөрәккә.

Кырыслыгың, горурлыгың оныт,
Миндәй бул, дип, күңел ялвара.
Яна-яна, тәмуг булдым инде,
Йолдыз да юк күктә санарга.

Син кайдадыр читтә, бик еракта,
«Сөям» сүзе сиңа сүз генә.
Сүзләреңнең кайтавазы калды,
Тик исемең калды үземә.

* * *

Я зеркала и окна разобью.
Меня в слезах за это не кляни.
А красоту нетленную свою
захочешь видеть – мне в глаза взгляни.

Пусть вдалеке окажется родня!

Пусть сердце учит голову добру!
И пусть друзей не будет у меня!
Тебе одной я сердце отопру.

Чтоб память успокоиться могла,
душа моя, о гордости забудь!
И так уже от гордости дотла
сгоревшим вижу даже Млечный Путь.

А ты всё ходишь где-то в стороне,
не слышишь разве, как тебя зову?
Я разбиваю зеркало во сне,
а вот осколки вижу наяву...

* * *

I

Бертуктаусыз уйный, шаярасың...
Шатлыгыңны кемнәр уяткан?!
Син бит башка. Син бит уйчан идең,
...Бу җылы җил исә төньяктан.

II

Кара кайгы баскан бүген сине,
Йөри идең элек гел актан.
Син бит башка. Син бит көләч идең.
...Бу салкын җил исә көньяктан.

* * *

I

Ничто тебя сегодня не тревожит,
Скажи мне, кто весну тебе вернул?
Ведь ты другая. Грустная. Быть может,
То тёплый ветер с севера дохнул...

II

Ничто тебя не радует с рассвета.
Печальна ты, всё валится из рук.
Ведь ты другая. Радостная. Это
Дохнул холодный ветер с юга вдруг...

* * *

Иң беренче
уйчан булуыңны сөйдем,
аннан – исемеңне.
Аннан – сүзләреңне,
аннан – борыныңны,
күзләреңне,
«сөям» диюеңне,
минем янга
йөгереп килгән чакта

күкрәкләрең белән бергә
биюеңне.
Хәзер исемеңне сөймим,
бары исемеңне.
Ачуланма,
исемеңне генә алыштырыйм,
бары исемеңне...

* * *

Любимая!
Я всё любил
В твоей надменной гордой стати:
Рассудочный, холодный пыл,
Небрежное рукопожатье,
Усмешку горькую твою,
Глаза, исполненные власти, –
В твоём заснеженном краю
Всё было мне безмерным счастьем.
Я всё, я всё в тебе любил.
И только имя позабыл...

## Сине озатканда

Сагынуым басылмады әле,
Ачылмады синең йөрәгең;
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем.

...Билет юктыр бүген самолётка,
Буш урыннар юктыр поездга,
Трамвайлар тулы халык белән,
...Җил дә әнә моңлы җыр суза.

Адашырсың... күктә йолдызлар юк,
Юл тапмассың... төн бик караңгы.
Тутырыр күк айсыз, йолдызсыз төн
Синең белән минем араны.

Көз сагышы миңа күчә, дисең...
Телисеңме? – Хәзер яз ясыйм!
Чәчәк белән күмәм йөрәгеңне –
Мәхәббәтнең алсу вазасын.

Кирәк түгел чәчәкләрең, дисең,
Кирәк түгел сүзең: «Яз ясыйм».
Калсам – бары мине табарсың син,
Китсәм – сагынып шигырь язарсың...

Ничек итеп җырлар языйм ди мин? –
Ачалмадым синең йөрәгең...
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем.

## Твой отъезд

Как я хотел, чтоб смолкли поезда,
Чтоб самолётам отменили рейсы!
Я чувствовал: отныне навсегда
Разъединят нас небеса и рельсы.

Как я хотел опять весну вернуть,
Чтобы в листве упрятать все вокзалы
И для тебя назад отрезать путь...
«Весны не будет», – ты в ответ сказала.

«Пиши, – сказала ты, – ведь ты поэт...
Пиши о нашем промелькнувшем счастье...»
Но как писать, когда весь белый свет
Твоя слеза – неудержная – застит...

## Сөйләмә мәхәббәт турында

Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Ышандыр иң элек талларны.
Ә миңа тал сөйләр аннары,
Ышандыр иң элек талларны.

Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Сереңне ач башта тирәккә.
Тирәкләр дәшәрләр йөрәккә,
Сереңне ач башта тирәккә.

Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Ышандыр иң элек үзеңне.
Моң бассын сагышсыз күзеңне,
Ышандыр иң элек үзеңне.

## Не говори мне о любви

Не говори мне о любви своей.
Поведай о любви плакучей вербе.
Я больше, чем тебе, поверю ей.
Когда расскажет верба, я поверю.

Мне о любви своей не говори,
А расскажи берёзе, как подруге.
Поверю ей, когда под шелест вьюги
Мне передаст она слова твои.

Не говори мне о своей любви,
В душе оставь хоть уголок надежде.
Поверь сама в свою любовь ты прежде.
И я приду, ты только позови.

## Чакырма

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
Өметтәй олы ул диңгез,
Күз яше кебек тозлы.

Диңгезне мин аңлый алмам,
Минем хыял башкада.
Тик нигәдер бар елгалар
Ага диңгезгә таба.

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
...Сезнең яктан килгән болыт
Күкне күкрәтеп узды.

Күкрәгемне ачып тордым
Саф диңгез һавасына,
Яңгыр түгел, синең сагыш
Болыттан тама сыман.

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
Җибәрми туган ягымның
Давылы, кары, бозы.

Җир кызы ярата мине...
Күзләре диңгез төсле.
Дулкынланган толымнары
Әйтерсең диңгез өсте.

Кайгы кебек олы диңгез,
Күз яше кебек тозлы...
Сагышларым болай да күп,
Чакырма, диңгез кызы.

## Не зови

Не зови в свои просторы.
Там надежда не видна,
Там волна седого моря
Холодна и солона.

Всё равно характер моря
Никогда я не пойму.
Но река, со мною споря,
Рвётся к морю почему?

Ты ли этого хотела?
Ты, я знаю, моря дочь! –
Туча с моря налетела,
Оглушила громом ночь.

Вскрыл испуганную душу
Молнии блестящий нож.

И покой во мне нарушил
Посланный тобою дождь.

Не зови! Не мучь прибоем!
Полюблю – да разлюблю.
Я приговорён судьбою
К лесу, полю, ковылю.

Я судьбой с другою связан,
У неё прибой в глазах.
Душу не смущай рассказом
О далёких парусах.

Пусть летят они по волнам,
Что, как слёзы, солоны,
Чайки вьются там со стоном
В этом нет моей вины...

## Урман чишмәсе

Урман юлында чыктың каршыма,
Такыя үреп кидең башыңа.
Кара урманда көндез адаштым,
Калды урманда моңлы карашым.

Кушымта:

Челтер-челтер ага урман чишмәсе.
Челтер-челтер – суга ятлар төшмәсен.
Челтер-челтер килә синең сүзләрең лә...
Челтер-челтер көлә гүзәлем, гүзәлем, гүзәлем лә.

Зифа каендай синең буйларың.
Карадым сиңа, карап туймадым.
Чишмә суыдай акты чәчләрең,
Чишмә суыдай җанга чәчрәдең.

Кушымта.

Урман яктырды, безне күргә.
Чакырдың мине урман түренә.
Урман чишмәсе, сиңа мең рәхмәт!
Чишмәдәй чиста безнең мәхәббәт.

Кушымта.

## Лесной родник

Живая здесь течёт вода.
Испить изволь –
Она излечит навсегда
Любую боль.
Поверил я и жадно пил,
Томим бедой.
Но боль в душе не утолил

Я той водой.
В душе моей гудит гроза,
Покоя нет.
В глазах моих твоя слеза
Мне застит свет.
А на губах, как твой завет,
Горит огонь,
Хранит твоей ладони след
Моя ладонь.
Шумит целебная вода
И день и ночь,
Но в сердце боль ей никогда
Не превозмочь.
О боль! Её вовеки я
Не утолю.
Неизлечимо болен я:
Тебя люблю...

## Мәхәббәттә алданганнар җыры

Әй бай идем, шундый бай идем мин...
Акылым булды, булды йөрәгем.
Кемнең миннән нәрсә урлаганын
Күз яшьләрем аша күрмәдем.

Әй бай идем, шундый бай идем мин...
Бер бөркетем калды читлектә.
Анысын да югалтыр дип уйлап,
Тәрәзә артында соңгы чик көтә.

## Утраченная любовь

Я был богат, богат безмерно,
А нынче – пустота в груди.
Всё позади.
    И смерть, наверно,
Ждёт-поджидает впереди.

Я был богат.
    Был разум светел.
Я богател день ото дня,
Но, благодушный, не заметил,
Как кто-то обокрал меня.

Я был богат.
    Лишь беркут-птица
Осталась у меня одна...
Но кто-то за окном таится
И ждёт, что вылетит она.

* * *

Бүген тагын мине ташлап киттең...
Төне буе сине эзләдем.

Таңга кадәр мөлдерәшеп торды
Бар йолдызлар – синең күзләрең.

Синең күзләрең күк бар йолдызлар,
Синең гәүдәң кебек ак таллар,
Син киткән юл кебек Айның юлы...
Мин адашам, батам, буталам.

Йолдызларга үреләм – буем җитми,
Кочагыма керми таллар да...
«Ул кайда?» – дип, гөлләр сорасалар,
Мин ни диеп әйтим аларга?..

Син кайт инде. Йолдызларны кызган...
Алар кабат йолдыз булсыннар.
Кояш чыгып килә... Кояш юлы
Син кайтачак алтын юл сыман.

* * *

Ушла...
Всё было как во сне,
И стало в мире одиноко.
Мерцала грустно в тишине
Твоя звезда с небес высоких.

Тебя являла мне везде
Одушевлённая природа.
Был отсвет лунный на воде
Дорогой твоего ухода.

Тальник незримый начертал
Твой силуэт в вечернем свете.
Твоё мне имя прошептал
Усталый одинокий ветер.

Вернись!..
Ведь знаешь ты: цветы
К утру потребуют ответа,
Спросив, куда пропала ты.
Что я отвечу им на это?..

* * *

Мажаралар дөньясында
Мажаралар бетәрме?
Мажарасыз картлыгымны
Бу йөрәгем күтәрме?

Дөнья тулы күзләремнән
Бу юләрлек китәрме?
Зәңгәр дулкын, ап-ак бәхет
Миңа кагылып үтәрме?

Зөһрәләрдән калган серне

Ул соң миңа сүтәрме?
Күлгә төшкән Ай шикелле,
Әллә соң тик үртәрме?

Мажаралар дөньясында
Мажаралар бетәрме?
Бер мәхәббәт табар өчен
Бер яшьлегем җитәрме?..

## Экспромт

В этом мире без покоя
Обрету ли я покой?
Что со мною происходит?
То ли мир, то ль я такой...

Белый свет глаза мне застит:
Много света – много слёз.
Сколько счастья пережил,
Сколько горя перенёс!

Над загадкой, сердце, бейся
От заката до утра –
Своей тайны не раскроет
Незабвенная Зухра[1].

В этом мире без покоя
Обрету ли я покой?
Нет! Найти любви не хватит
Юности моей одной.

* * *

Юкәнең – балланып килгән,
Миләшнең ап-ак чагы.
Төне буе көлде алар,
Янды урман учагы.

Таң атуга, миләш китте...
Юкәне кортлар сарды.
Усал гайбәт тараттылар
Карурман куаклары.

Олы алан уртасында
Юкә ялгызы калды.
Миләш карт имән төбендә
Куак белән шаярды.

Урманда көз. Орлыклы һәм
Җимешле агачлары...
Тик юкәнең каны зәңгәр,
Миләшнең бәхете сары.

* * *

Была пора цветенья клёна,
Рябины белая пора,
Ах, как восторженно, влюблённо
Они шептались до утра!

Ах, как они клялись друг другу
В любви друг друга не забыть,
А белокипенная вьюга
Над ними продолжала плыть.

И день прошёл, и ночь настала...
Набросив белую фату,
Рябина в темноте пропала –
Ушла безмолвно в темноту.

Там дуб стоял, отшельник света,
 К нему пришла она, бела.
...Весна прошла, минуло лето,
И осень грустная пришла.

Как не грустить! Стекают звёзды
По веткам клёна, солоны,
Горят рябиновые гроздья,
Или рубиновые слёзы
Минувшей ветреной весны?

* * *

Хатларыңны утка яктым синең.
«Сагыш» сүзе, «сагынам» сүзе, «сөям» сүзе янды.
Үткән язда утка салып мине
«сөям» сүзен, «сагынам» сүзен, «сагыш» сүзен
алган идең.
Кире бир аларны!
Гөнаһларым бик күбәйгән икән...
Синең янга йөгергәндә,
юлымдагы бер йөрәкне таптаганмын.
Хәзер түлим аны.
Карашымның бер җылысын көтеп,
салкын йөргән кызны
күрә торып,
көлә-көлә,
янар елларымны алдың.
Кире бир аларны!
Ә... юк...
алар... янды инде...
Хатларыңны утка яктым синең.

* * *

Сегодня я сжёг твои письма.
Слова отпылали твои,
Что были исполнены смысла
Неверной, ушедшей любви.

Тебя не корю, что так вышло,
Но только верни мне скорей
Слова, что исполнены смысла
Любви постаревшей моей.

Какую свершил я ошибку!..
Я вспомнил, как вечность назад
Другая ловила улыбку
И мой снисходительный взгляд.

Цветами она усадила
Дорогу мою впереди
И словно навеки простила,
И словно сказала: «Иди...»

Пошёл я слепою дорогой,
Цветы я, смеясь, растоптал.
О Боже! Как долго, как долго
Я этой дорогой плутал!..

Корю себя, что так вышло.
Верни эти годы, верни!
Но словно из вечности слышно:
«Давно отпылали они...»

* * *

Онытылды инде күз яшьләре,
Онытылды антлар, вәгъдәләр...
Тик... йөрәкнең почмагына поскан
Намус кына нидер дәгъвалар.

Акты сагыш күз яшьләре белән,
Бушатты ул тулган күңелне.
Күңел ачык... Кем беренче керә? –
Кем керсә дә барыбер түгелме?

Керде күпләр күңел түренә үк,
Исән-саулык сорап тормады...
Сәерсенеп, тәрәзәдән карый
Гаҗәпләнгән шәһәр урамы.

Күлмәкләрен салды яшь каеннар,
Йөрәкләрен сузды миләшләр...
Төн аларны кочагына алды...
Ал миләштән тамды ал яшьләр.

Таң атуга, кипте күз яшьләре...
Онытылды антлар, вәгъдәләр.
Буш күңелләр тулыр шатлык белән,
Намус кына нидер дәгъвалар...

* * *

Ну что ж! Освободился я от слёз,

От обещаний, клятв перед любимой.
Но почему мучителен вопрос,
Ответить на который – выше силы?..

Ушла печаль слезами из груди,
Душа освободилась от тревоги.
Просторно в ней...
Кто первый? – Заходи!
Не стой, стесняясь, на её пороге!

Не надо слов приветствий, встречи слёз –
В неё и без приветствий заходили...
Она свободна, словно дом на снос,
В котором окна не заколотили.

За окнами – без листьев тополя
И сердцем обнажённые рябины,
А дальше – лес и голые поля –
Лик незнакомой дорогой долины.

Рассвет мне облегчение принёс,
Когда душа простора попросила.
В душе просторно...
И гудит вопрос,
Ответить на который – выше силы...

## Рельслар

Поездларны юлга күп озаттым,
Тик берсен дә каршы алмадым...
Шул поездлар белән киткән инде
Сөюемнең чыны-ялганы.

Син дә киттең, кояш чыгып калды,
Китеп бардың офык ягына.
Мин – әйтерсең синең поездыңның
Тагылмыйча калган вагоны.

Хат язгансың: «Син күрмәгән гөлләр,
Син белмәгән йолдыз бар бездә.
Йөрәгемдә яңа утрау таптым,
Кил, – дигәнсең, – булчы Робинзон».

Сагышларым төяп, юлга чыктым,
Шатлыкларың белән каршыла.
...Үз хатасын төзәтергә теләп,
Поезд бүген шундый ашыга.

Шпалларның кайгыларын эчеп,
Юл буенда сары гөл үсә.
Алга карыйм, алда матур ялган –
Кушылалар кебек рельслар.

## Рельсы

Отходят и отходят поезда.
Так будет вечно, как и было прежде.
Они с собой уносят навсегда
Несбывшейся любви моей надежды.

В одном из них уехала и ты.
Гремит состав по дальним перегонам,
А я среди вокзальной суеты
Остался здесь отцепленным вагоном.

...Письмо твоё: про звёзды, про цветы,
Про остров в одеянии зелёном...
В мечтах тот остров разыскала ты
И позвала меня – стать Робинзоном.

Я в путь собрался, взяв с собой печаль,
Встречай меня приветною улыбкой.
Как поезд мчит в неведомую даль,
Прося прощенье за свою ошибку!..

Как жёлты придорожные цветы,
Они напились горького тумана.
Два рельса, две судьбы, как две мечты,
Вдали соединяются обманно.

* * *

Елмаерга өйрәтермен сине... –
Тик елама гына, елама.
Сабый шул син. Ярны сынамыйча,
Карагансың текәп елгага.

Ышанырга өйрәтермен сине... –
Үткәннәрең генә уйлама.
Бер ишелгән, әйдә, ишелсен дип,
Елга ярын юри буйлама.

Мин көләргә өйрәтермен сине... –
Тик елама гына, елама.
– Ул үлде, – дип җавап бирдем бүген
Сине сорап килгән елларга.

* * *

Я научу улыбаться тебя...
Только не плачь, прошу.
Берег обрывист. А ты, как дитя,
Слушаешь речки шум.

Я научу тебя верить в любовь...
Только о прошлом забудь.
Берег обрывист, опасен, крут –
Ты осторожной будь.

Я научу смеяться тебя,
Чтоб ты любить могла...
Годы сегодня пришли за тобой,
Я им ответил:
«Она умерла...»

## Әкият

Фирүзәдәй зәңгәр күк астында
Икәү калдык. Башка беркем юк.
Рәхәт монда. Юк гайбәтләр, сүзләр...
Дөнья тора оеп, онытылып.
Әллә кая качкан аек акыл,
Ваклык качкан, качкан явызлык.
Ел елгасы акмый, тып-тын тора...
Сират күперләрен тиз уздык.
Көмеш сарай кебек айлы төннәр...
...Әкият тәмам. Алда – ялгызлык.

## Сказка

Под синим шатром
лучезарного неба
с тобою остались вдвоём –
я и ты,
и в мире вовеки
как будто бы не было
наветов, злословья,
игры, суеты.

Ни тонким расчётом,
ни грубою фальшью –
ничем наши души
теперь не смутить.

Всё кануло в Лету,
что мучило раньше,
и вечно с тобою
отпущено жить.

...На этом
кончается сказка.

А дальше –
одиночество...

## Соңгы мәхәббәт

Мәхәббәттән өмет өзгән чакта,
Синең белән нигә кавыштым?
Сау бул инде! Шушы кавышуым
Булса иде соңгы ялгышым.

Кавыштырмый икән уртак кайгы,

Кирәк икән уртак хыяллар.
Сау бул инде! Сөю бакчасында
Бар агачлар яфрак койганнар.

Кешеләргә бәхет биргән сөю
Миңа бирде күзләр сагышын.
...Сау бул инде, соңгы мәхәббәтем,
Сау бул инде, соңгы ялгышым!

## Последняя любовь

Зачем на склоне ветреного дня
Нас свёл опять бездумный этот вечер?
Я ухожу...
Да будет для меня
Последнею ошибкой эта встреча!

Не обернусь, окликнутый судьбой.
Я всё испил из этой горькой чаши.
Прощай!
Пускай останутся с тобой
Восторги наши и прозренья наши.

Бездумный вечер!
Для чего ты вновь
Разжёг свою лукавую улыбку?
Прощай, моя последняя любовь,
Прощай, моя последняя ошибка!..

* * *

Төн карасына каләмемне манып,
хатлар язам,
карам беткәнче язам...
Ә син
шуны да белмисең,
йөрәгеңне кулларыңа тотып
килмисең.

* * *

В чернила ночи окуная
Перо печальное любви,
Пишу письмо тебе, родная,
И предо мной глаза твои.

## Саубуллашыр өчен баргач...

Саубуллашмый киткән идем синнән,
«Хуш мәңгегә» сүзен әйтер өчен
Кире килдем.
Өегезгә исәнләшеп кердем.
Кулың бирдең.
Күз куеныннан алып,
Чәчәкләргә

Җылы сулыш өрдең.
Ә соң нигә өрдең?
Алда кыш торганын,
Табигатьнең догма икәнлеген
Күрдең бит син, күрдең.

Үткән барыбер кире кайтмый,
Ул кайтмаска киткән.
Саубуллашыр өчен баргач,
Исәнләшмә икән...

* * *

К былому возврат невозможен...
Зачем я вернулся тогда?
Зачем я подумал, что должен
Сказать ей: «Прощай навсегда»?

Вернулся...
Мне двери открыли,
Я руку зачем-то подал...
И сердце моё позабыло
О том, что я перестрадал.

О том, что под ветром холодным
Не могут цветы расцвести,
И что по законам природы
Зиме уже надо прийти.

К былому возврат невозможен...
Зачем я вернулся тогда?
Зачем я был неосторожен,
Зачем я ей руку подал?..

## Тау кызына

Тауларың тора томанда
Туңып, өшеп, калтырап.
Бозларын эретер идем,
Җан җылысына урап.

Төш инде, төш син түбәнгә,
Мин мәңге тауга менмәм.
Сулар да ага үзәнгә,
Ташлар тәгәри түбән.

Кыяларда яши алмый
Үзән җирдә туган тән...
Сикер әйдә! – Колач җәеп,
Упкын төбендә көтәм.

Таудан биек горурлыгың...
Син Сак, ә мин Сок[1] кебек.
...Әфлисуннар лимон булды,
Туган ягын сагынып.

## Горянке

Закрыты туманами горы твои,
Продрогли они подо льдами.
Я льды растоплю по веленью любви,
Чтоб не было льда между нами.

Спустись с этих гор ледниковых, спустись!
Лиши себя мнимой свободы!
Ведь камни и те обрываются вниз,
И вниз устремляются воды.

Рождённый в долине я жить не смогу
В холодных заоблачных высях,
Но даже и в мыслях себе не солгу:
Лишь ты в моих думах и мыслях.

Мы грустные птицы – ты Сак, а я Сок[1] –
В разлуке с тобой неповинны.
...И бродит лимонный томительный сок
В стволах и плодах апельсина.

## Кыз сурәте

Ул йончыган, талган, хәлсез калган
Һәм караган алга, ымсынып...
Хәрәкәтсез килеш басып тора,
Үз-үзенә куйган сын кебек.

Сүз башлавын көттем. Тик бер кабат
Төште миңа аның карашы:
Яман уйга катгый нокта кебек –
Күзләренең янган карасы.

## Портрет девушки

Она застыла без движенья,
Она доверчива к судьбе,
Усталой неги продолженье
Века копившая в себе...

И красотой необычайной
Она смущает ум живой.
В её глазах я вижу тайный
Высокий отсвет роковой.

Сейчас как будто слово молвит,
И взглядом пристальным пронзит.
Но только свет потухших молний
В очах задумчивых сквозит.

* * *

Тау юлыннан килүеңне күреп,
Өнсез калдым, хәтта тын алмадым.

«Сөям!» – диеп, аннан оран салдым, –
Юлыбызны ак кар томалады.

* * *

Слово «любовь»
Слишком громко крикнули...
Горную дорогу завалило холодным снегом.

## Дулкын

Чем-кара карлыгачлары,
Гөнаһсыз иде яры.
Ник шунда гына калмады,
Ник дулкын китте ары?

Тарсынып язмыш ярларын,
Ул диңгезгә юл алды.
Тау дулкыннар арасына
Кереп күздән югалды.

Күз яшьле акчарлаклары...
Күренми инде яры...
Зәңгәр күк һәм зәңгәр диңгез,
Йолдызлар монда бары.

Бар иде гөлләр, таллары...
Ник китте икән ары?
Елга ярын сагынып елый
Диңгезнең дулкыннары.

## Волна

Чёрных-пречёрных ласточек пенье,
берег обрывист и ясен до дна...
Так отчего же – и в звоне, и в пене –
здесь не оставшись, умчалась волна?

Есть у волны, очевидно, причина
выйти из русла привычной судьбы,
раз уж грохочет морская пучина
зовом безвестной и новой борьбы.

Чайки со стоном летят на просторе,
нет берегов у волны на виду.
Синее небо и синее море.
Звёзды горят с мирозданьем в ладу.

Были цветы на виду, были ивы –
бросила всё, нетерпенья полна.
О, как мы в юности нетерпеливы.

Что же ты плачешь, морская волна?

* * *

...Әйе, минем көчле рухымнан
җир вә күкләр калтырар.

*Һади Такташ*

Елый-елый, сугыша-сугыша, җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса, үзем үзгәрәм.

Аңламыйлар, җилне зәңгәр дисәң,
Тормышыбыз – Сабантуй, дисәң.
Һәрнәрсәгә минем үз атамам:
Айны Кояш диям, теләсәм.

Чәчәкләргә үз исемем бирәм,
Мең тереләм көнгә, мең үләм.
...Үлем белән якалашканда да,
Акны кара диеп сөйләмәм.

Дуслар юкта, чын дуслыкны мактыйм...
Бу дөньяда яшәү – мең рәхәт!
Адашыпмы, кайчак килеп чыга
Безнең йөрәккә дә мәхәббәт.

Кайчак ялгыш уңны, сулны бутыйм,
Булгалый ла инде, булгалый...
Кешеләрдән гел яхшылык телим,
Мин хыялый бугай, хыялый.

Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,
Матурлыкны күреп тезләнәм.
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса, үзем үзгәрәм.

* * *

На моё могучее дыханье
Отзовутся небо и земля.

*Хади Такташ*

Плача и скорбя, искал свободы
Светлый разум.
Не нашёл. Но пусть...
Или мир я изменю сегодня,
Или сам сегодня изменюсь.

Не поймут, когда скажу, что ветер –
Голубой, а время – Сабантуй.
Имена всему свои на свете
Дам я, понимая красоту.

Всем цветам я дам свои названья.

За день я воскресну и умру...
Но и в миг последнего дыханья
Чёрным белое не назову.

Воспою товарищество строгое.
Жить на свете – нет прекрасней слов!
После долгих, тяжких дней дороги
К нам в сердца является любовь.

Я могу обман принять за правду,
Да, бывает, что там говорить...
Мне тепла и света много надо.
Может, я наивен, может быть...

От несправедливости свободен,
Перед красотою преклонюсь.
Или мир я изменю сегодня,
Или сам сегодня изменюсь...

## Тормыш

– Кояш ерып,
чыклы аланда
таңнан нишләп йөрисең?
– Мин бит сабый,
мин урманда адаштым.

– Кояш таптап,
чәчәкле аланда
иртән нишләп йөрисең?
– Мин – яшүсмер,
җирне каргыйм:
ярлы да ул, саран да.
Мин – яшүсмер,
мин урманда юл таптым.

– Кояшны онытып,
җиләкле аланда
көндез нишләп йөрисең?
– Мин бит гашыйк...
Мин бәхеттә,
мин хәсрәттә адаштым.

– Төнгә каршы
сары аланнан
кая болай ашыгасың?
– Кояш артыннан.

– Айны саклап,
кара җирдә
төнлә нишләп йөрисең?
– Мин – кайтаваз,
Җирне зурлыйм:
бик бай да ул, юмарт та!

Мин – кайтаваз,
мин кояшны югалттым.

## Жизнь

– По росной поляне
зачем ты гуляешь,
тревожа траву и росу?
– Я маленький мальчик,
ещё несмышлёныш,
и я заблудился в лесу.

– По алой малине,
по малой поляне
что бродишь, роняя слезу?
– Я – отрок, подросток,
земля скуповата,
а я заблудился в лесу.

– На знойной поляне,
сквозь полдень палящий –
откуда б испытывать страх?
– Я вырос, влюбился,
мне солнце открылось,
но я заблудился в страстях.

– По жёлтой поляне
на пламя заката
к какому стремишься лучу?
– За солнцем лечу.

— Луну охраняя,
По чёрной поляне
Что бродишь, будя чернотал?
– Я – эхо,
я призван расширить пространство.
Я солнце своё
потерял.

## Бер көнем

Бәхет атлы хыял дәүләтенә
Бара торгач, туры юл салып,
Онытылган тормыш кануннары,
Онытылган хәтта усаллык.

Кемнәр дошман, кемнәр дус соң миңа? –
Буталып ла беттем дөньяда...
Чал карт булып кич йокыга ятам,
Сабый булып таңда уянам.

Яхшыларын, матурларын гына
Җыеп куям җанга сүзләрнең.
Һәр иртәне зәңгәр күккә баккач,

Зәңгәрләнә тагын күзләрем.

Сәламләгән чакта кешеләрне
Булмасын дип каты кулларым,
Саф чишмәгә барам. Беләм чөнки
Дорфалыкны аның юарын.

Бусагадан, сабый бала кебек,
Атлап китәм тәүге адымны.
Бөтен дөнья миңа көлеп карый,
Бөтен дөнья шундый ягымлы.

Урман-кырлар тыңлый сүзләремне,
Һәр сүземә минем ышана.
Кешеләр дә көләч, шат күңелле –
Бүленмәгән дуска, дошманга.

Бәхет атлы хыял дәүләтенә
Карап барам, үзем юл салып...
Бар күңелем тулы кояш белән,
Тамчы да юк җанда усаллык.

Аяз күкне кинәт болыт баса...
Мин кычкырам: «Хыял, алдадың!»
Күкләр күкри...
Әйтерсең лә ул мин
Яңагына сугам ялганның.

Егылам да торып алга атлыйм,
Абынам да тагын егылам.
Һәм кемнәрдер, кулларымнан тартып,
Яздырмакчы була юлымнан.

## Мой день

Кто друг мне, кто недруг – порою не знаю.
И в том огорчения нет.
Я вечером старцем седым засыпаю,
младенцем встречаю рассвет.

Чтоб вечером доброй сложилася песня,
чтоб светлыми были слова,
я каждое утро гляжу в поднебесье –
и входит в глаза синева.

Чтоб чёрствостью рук не обидеть знакомых
во время приветствия вдруг,
иду к роднику я с рассветом из дома –
и чёрствость снимает серебряный друг.

Иду поутру от порога родного,
и птаха взлетает, звеня,
и мир, каждый раз молодеющий снова,
встречает улыбкой меня.

Я – сын молодого родимого края,
сегодня мне всё по плечу.
Кто друг мне, кто недруг – пока что не знаю,
а может, и знать не хочу.

Нет в сердце обиды, и зависти нету,
лишь солнце ликует в душе!
Четыре прекрасные стороны света
раскрыли объятья уже!

Но вот надвигается туча тревожно,
и гнётся под ветром лоза...
Природе спокойною быть невозможно,
коль в небе грохочет гроза.

Я падаю ниц от громового звука,
Вселенную и небо кляня...
Мне враг подаёт ненадёжную руку
и тянет с дороги меня.

Наверно, я долго б с испугу проплакал,
не видя ни зги впереди.
Но друг подаёт разгоревшийся факел:
– Ты видишь дорогу? Иди!
Кемдер мине әйди алга таба:
Кулларына янар ут алган...
Ә кемнәрдер дәшә башка юлга –
Яхшы белән яман буталган.

Кулларымны тартып алам да мин
Үз сукмагым буйлап йөгерәм.
Ябылганда,
Офык капкасына
Көч-хәл белән килеп өлгерәм.

Офык сала алтын бишегенә...
Мин саташам, тирлим, ут янам.
...Чал карт булып кич йокыга талам,
Сабый булып таңда уянам.
Закат догорает. Закату – я знаю –
ворота пора закрывать.
Избитый, уставший, я всё ж успеваю
в ворота заката вбежать.

...Глаза в тишине перед сном закрываю.
Я в жаре, я брежу, горю...
Я вечером старцем седым засыпаю,
младенцем встречаю зарю.

## Кеше

Бу дөньяның мин бер кисәкчеге,
Мин – кечкенә генә материк.

Таулар да бар миндә, упкыннар да,
Батырлык бар миндә, матурлык.

Бу дөньяның мин бер кыйтгасыдыр...
Урман миндә чәч дип атала...
Минем кояш – бәхет, аем – шатлык,
Яңгыр булып миннән тир тама.

Кайгыларым җир тетрәве төсле,
Сагышларым – гүя ак томан,
Чишмәләрем – чиста күз яшьләрем,
Ә сүзләрем – буран, җил сыман.

Култык та бар миндә, бугаз да бар,
Ике күзем ике күл кебек.
Ә йөрәгем – утрау, утыра ул,
Дулкын күбегенә күмелеп.

Тарих миндә хәтер дип атала...
Ак битләре инде аз аның.
Очы да юк аның, уртасы да,
Күреп булмый аның азагын.

Баш миенең сырларына ятып,
Хәтер сөйли үзенең үткәнен...
Ничек итеп җирләр, кыйтгаларның
Океанга батып беткәнен...

Ул заманда җир дә җир дип түгел,
Башка исем белән аталган...
Чәчләремне, күзләремне капшыйм...
Алар – миңа мирас атамнан.

Кеше атлы нәни бер кыйтга мин...
Матурлык бар миндә, батырлык.
Күпме тырышсаң да, булмый мине
Хәят диңгезендә батырып!

## Человек

Мира живого живая частица,
малоизвестный, но я – материк.
Хищник в горах моих диких таится,
чистый в долине струится родник.

Лес – мои кудри, луна – сновиденья,
пот мой – как дождь, что внезапно настиг.
Мне-то известно, что я от рожденья
крошечный вовсе, но всё ж материк.

Каждый мой гнев – изверженье вулкана,
каждый мой стих – укрощенье огня,
вечность – безбрежная синь океана –
всю мою жизнь омывает меня.

Память моя – летописец бессонный,
сколько ни пишет, не видно конца.
Сам перед нею, тоской опалённый,
слёзы глотаю, не пряча лица.

Всё ей подвластно – событья и даты.
Помнит о том, как в туманной дали
канули в Лету однажды когда-то
земли, которых нигде не нашли.

Снова листаю страницы святые,
с миром своё утверждаю родство...
Скулы крутые да брови густые –
это мне всё от отца моего.

Я – материк. Я зовусь Человеком.
Что бы моя ни сулила звезда –
ядерным взрывам и атомным рекам
не уничтожить меня никогда!

## Идел

Ярларына ятып, Идел ага,
Казан тора аны озатып.
Акчарлаклар күз яшедәй – елга...
Күбек дулкын – гүя акбүз ат.

Ярга бәрде дулкын Болгарны да,
Гасырларны алды якадан.
Әтил дә ул, Идел дә ул булды,
Волга дип тә инде аталган.

Җир әйләнсен, елга аксын гына! –
Килсен Пугач, йөзсен Разиннар...
Аны мактап җырлар чыгарсыннар,
Яр комына дастан язсыннар.

Бер җәйделәр аны, бер кыстылар...
Ә безгә ул гел зур, гел көчле.
Идел койган диңгез саега бара,
Кешеләрнең хәтере шикелле.

Афәт килсә, аны каргадылар,
Һәм башланды имеш-мимеше...
Югыйсә бит бозлар – кыш бүләге,
Ә дулкыннар – давыл, җил эше.

...Елга да мин. Башка беркем дә юк.
Әйтерсең лә җирдә без генә.
Ярларына кысылып, Идел ята,
Кысаланган иске көзгедәй.

## Идель

Идель бежит, на берега ложится,
Казань следит за ней из-под ладони:
как слёзы чаек, искрится водица,
и сизы в пене волны, словно кони.

Она на берег булгарский вздымалась,
века брала за ворот в жизни долгой,
звалась – Итиль, Иделью называлась,
теперь во всю длину зовётся Волгой.

Земле – вертеться, рекам – течь вовеки!
Пугач и Разин в удальстве мятежном
гуляли здесь, и алой кровью предки
дастан писали на песке прибрежном!

То расширяли реку, то сужали,
по-всякому её пытались ранить,
но всё ж она могуча, хоть в печали
мелеет Каспий, как людская память.

В ней видели то счастье, то угрозу,
над ней мудрили, чтобы сжить со свету!
Давно пора оставить льды морозу,
давно пора оставить волны ветру.

Река и я. Мы не были врагами.
Мы – два героя в бесконечной драме.
Лежит Идель, зажата берегами,
как зеркало прабабки в новой раме.

## Борынгы Болгарда

Болгар җире, Бөек Болгар иле...
Тарихка мин саклыйм зур үпкә.
Бабамнарның мәгърур җаны кебек
Күтәрелә тургай биеккә.

Басу буйлап берәү җырлап килә,
Чал тарихтан килә диярсең.
Барысы да мең ел элеккедәй...
Аргамаклар чаба иярсез.

Барысы да мең ел элеккедәй:
Ай-кояшы, зәңгәр күге дә...
Бөек илдән чүлмәк ватыклары
Бүләк булып калган бүгенгә.

Бөтен нәрсә монда якын миңа,
Әйтерсең мин әнкәм куйнында.
Бөтен нәрсә монда Болгарымның
Оныклары кебек тоела.

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар...

Бабайларның сүзен сөйләр өчен,
Тик кылганнар гына калганнар.

...Болгар иле – бабамнарның иле,
Тургай моңы – минем моңнарым.
Мин тургайны түгел, бүген гүя
Бабамнарның җырын тыңладым.

## В стране булгар

Великий Булгар... Напрягая слух,
на тьму веков серчаю я жестоко...
Как предков гордый и бессмертный дух,
взмыл жаворонок в небеса высоко.

Вот человек – из древней старины
идёт и с песней переходит поле,
и как в десятом веке, скакуны,
узды не зная, скачут здесь на воле.

Всё, как тогда, – и солнце, и луна.
Закат, как прежде, ярок и малинов...
Оставила нам древняя страна
лишь черепки от глиняных кувшинов.

Так драгоценно всё в родной стране,
так всё полно надежд и откровений,
что звук любой и отзвук, мнится мне,
лишь эхо стародавних песнопений.

Развалины, руины – злая быль;
угадывая прошлого приметы,
я вижу – жив ещё седой ковыль,
чтоб передать мне дедовы заветы.

Великий Булгар – древнее жнивьё.
Тобой я счастлив, болен я тобою.
Настороженно кружит вороньё
над пеплом лет, над скорбной головою...

## Музейда янгын

Яна музей Казан үзәгендә,
Яна таңда Дәүләт музее.
Яна кебек гүя бабам йорты,
Яна кебек минем үз өем.

Ут эчендә – энже, асылташлар,
Кулъязмалар, нәсел башыбыз...
Гасырларны салып җилкәләргә,
Подвалларга китап ташыйбыз.

Бу китаплар инде ничәнче кат
Исән чыккан яудан, янгыннан.

Гасырларның кара табы булып
Битләренә корым ягылган.

Тәрәзләрдән ургый кара төтен,
Шомга салып якын-тирәне.
Яна музей, әйтерсең лә яна
Халкыбызның соңгы кирмәне.

Үрли ялкын, гасырларга үрли,
Үткәннәрдән күчә бүгенгә.
Күчә ялкын ил һәм халыкларга,
Күчә ялкын безнең күңелгә.

Безнең тарих, ничә тапкыр янып,
Күтәрелгән көлдән, күмердән.
Патшалардан чыккан янгыннарны,
Утка кереп, халык сүндергән.

Янәшәдә – Җәлил. Кул – богаулы,
Күзләрендә – халкым газабы,
Богауларны өзеп ташланыр күк...
Саклар өчен уттан Казанны.

...Янды музей. Ә без һаман исән.
Исән чыктык тагын янгыннан.
Подвалларда бүген безнең тарих...
Тарих биктә... Музей ябылган.

## Пожар в музее

В Казани на заре объят огнём
музей родного края: искры – роем!
Горит музей, горит, как отчий дом.
Горит музей, как дом, который строим.

В огне, как слёзы, тают жемчуга,
народа рукописные преданья...
Столетия спасая от врага,
мы носим кипы книг в подвалы зданья.

Ведь эти книги уж который раз
пытается огонь голодный слопать:
веков тамгою чёрной – напоказ,
на древности страниц – зола и копоть.

Из окон чёрный буйный дым валит,
страшит округу пламени свирепость...
Горит музей – последняя горит
векам ещё не сдавшаяся крепость.

Рычит, грозится, воет и ревёт
огонь, который на рассвете тушим;
кидается на землю, на народ
дракон свирепый, угрожая душам.

В истории моей сплошной угар;
земля не раз из пепла возрождалась.
И если деспот разжигал пожар,
народ гасил огонь в дыму пожарищ.

Напротив изваяньем встал Джалиль.
В глазах – тревога, но в оковах руки.
И кажется, что из последних сил
он снова рвётся в пламя, в боль и муки!

Сгорело зданье. Только целы мы.
Мы вышли из огня в рассветной рани.
Столетья ждут среди подвальной тьмы.
До времени закрыт музей в Казани.

* * *

Егет икән, әйдә, егет булыйк!
Ак мендәрне кочып елыйк та...
Акыл, йөрәк, горурлыкны алып
Чыгып китик моннан еракка!

Кара җирдән ап-ак бәхет эзләп,
Картлар киткән, киткән малайлар.
Әйтерсең лә, далаларга китеп,
Язмышыннан качкан бала бар...

Күлләр диңгез булган, диңгезләр – күл,
Буталганнар таулар, үзәннәр.
Тәне анда, җаны илдә килеш
Яшәгәннәр алар, түзгәннәр.

Бәхет туган җирдә икәнлекне
Ышандырган вакыт аларга.
Кара түбәтәйле картлар кайта
Шул туфракка ятып карарга.

* * *

Зачем, имея ум и сердце,
Ушли в далёкие края
И стар и млад, отцы и внуки –
Судьбой гонимая семья?

Прошло сто тысяч лет, но знала
Судьбой гонимая семья,
Что за горами, за морями
Была у них своя земля.

И был порог облит слезами...
И снилось старцу и юнцу,
Как он вернулся к пепелищу
И пепел тот поднёс к лицу.

# Шагыйрь

*Шарль Бодлерга*

Сабый чакта урындыктан егылды.
Көне буе әнисен көтеп,
еламыйча,
уч төбендә бер тамчы кан саклап йөрде.
Аңламадылар.

Малай булгач,
беренче тапкыр
йолдыз атылганын күрде.
Кешелеккә яңалык сөйләр өчен,
йокламыйча,
төне буе таңны көтеп ятты.
Тыңламадылар.

Урам тутырып җырлылар да,
җырсызлар да җырлап үтте.
Күз яшенә малайлыгын кушып,
ул җыр язды.
Җырламадылар.

Кайгыларның
ак төстә дә, зәңгәр төстә дә
булуына инанып янды.
Еллардан ул бәхет үтенмәде,
тик ашыкмауларын сорады.
Еллар көлде, юллар көлде. Кешеләр белде.
Еллар соңламадылар.

Менә бүген
барысы үтте, барысы бетте.
Кешеләр аны әрнеп тыңладылар...
Аңладылар... Соңладылар...
Каберенә башларын орып,
җырын җырладылар.

# Поэт

*Шарлю Бодлеру*

Он, будучи ещё младенцем,
Разбил себе ладони в кровь.
Он молча к взрослым обратился.
Все промолчали...

Он, будучи ещё подростком,
Открыл восход ночной звезды.
Он ночь не спал, но утром люди
Не стали слушать...

За окнами терзали песню.

А он, страдая, написал
О маленьких, в крови, ладонях.
Нет, не запели...

Улиткой горе проползало,
Летели годы, как стрела.
Он крикнул: «Не спешите, годы!»
А годы – мчали...

И вот всё кончено.
Навечно замолкло сердце у него.
И люди песнь его запели.
А он не слышал...

## Һәйкәлләр

Күңелләргә сыймый дала моңы,
Җырларга ул ничек сыйсын ди?!
Һәйкәл булып өстән карый шагыйрь,
Булмаса да зурдан буй-сыны.

Без бөек тә, таш һәйкәл дә түгел,
Без бу җирдә – гади кешеләр.
Дус-дошманга ачык күңелебез...
Без – акыллы һәм без – шыр юләр.

Урамнардан җырлап узабыз без,
Юллар безнең арттан иярә...
Ай-йолдызга менеп булмас, ахры...
Безнең язмыш гади иярдә.

Без – кешеләр, гади кешеләр без.
Без очрашкан мәлләр – шәп мәлләр!
Ә бөекләр һәйкәл булып калган...
Тик очраша алмый һәйкәлләр.

## Памятники

Во мне не вмещается дума просторов,
Тем более в песню её не вместить.
Над нами возносятся камни, в которых
Поэты навеки останутся жить.

А мы не великие, мы не из камня,
Из крови и плоти сработаны мы,
С врагами мы бьёмся живыми руками
И к жизни живой устремляем умы.

Мы песни поём, оглашая округу,
За нами дороги клубятся вослед,
Светила над нами проходят по кругу,
В душе оставляя живительный свет.

Мы любим с друзьями прекрасные встречи,

И жизнь мы прославим за это одно!
Конечно, неплохо стать камнем навечно,
Но камням встречаться, увы, не дано.

## Мәңгелек ут

Һәйкәл тора мәйдан уртасында,
Мәһабәт тә йөзе, салкын да...
Каршысында яна мәңгелек ут,
Салкын һәйкәл карый ялкынга.

Урамда кыш. Сугыш күптән тынган.
Дөнья тыныч. Тик кул күшегә.
Ут янына җылынырга килә
Бала-чага, олы кешеләр.

Җылынырга килгән чал чәчле карт
Нигә салган әле бүреген?
Бу ялкында таныш чалым күреп,
Дустын уйлый, ахры, ул бүген.

...Медале дә юк иде бит хәтта...
Болай гына... гади бер батыр.
Атакада пуля тигәч аңа:
«Син туктама, – диде, – бара тор...»

Кабереннән күтәрелгәнме ул,
Җимереп чыккан мәллә төрмәне?!
...Һәйкәл булып тәне кайткан илгә,
Мәңгелек ут булып – йөрәге.

## Вечный огонь

Стоит солдат, одетый в камень,
Солдат народа своего.
И вечное святое пламя
Колышется у ног его.

Здесь головы склоняют низко.
Давно окончена война...
Здесь, у подножья обелиска,
Торжественная тишина.

Я часто вижу в парке этом:
К огню приходит человек,
И тихим, и горючим светом
Мерцают слёзы из-под век.

Он помнит всё, как это было,
И боли в сердце не унять:
Вперёд пехота уходила,
А в друга пуля угодила,
И он остался там лежать...

...Но вопреки законам смерти
Он снова в полный рост стоит!
Он стал гранитом.
Только сердце
Огнём по-прежнему горит!

* * *

Мин – яшьтәше атом бомбасының...
Мин мәңгелек уйда утырам.
Галимнәр, сез бомба ясаганда,
Әниләр бит безне тудырган.

Безгә күптән акыл теше чыкты...
Акыл кердеме соң аларга?
Матдәләрнең җанын суыра-суыра,
Галимнәрнең чәче агара.

Илләр бүләр өчен, атом бүлеп,
Сак йокысын бүлеп кешенең,
Бәхеткәме, ләхеткәме икән,
Тарих, безгә юллар түшәдең?

Җәй җиттисә, шомлы күк күкрәде,
Без яшенгә кушылып яшьнәдек.
Мин – яшьтәше атом бомбасының,
Икәү бергә чакта яшәү юк!

* * *

Я – сверстник бомбы атомной. Как раз.
Меня гнетёт вопрос, зовёт к ответу.
В мученьях женщины рожали – нас,
а властелины мира – бомбу эту.

Зуб мудрости есть у меня давно.
Мудреют ли земные властелины?
Им душу у материи дано
отнять, и страсти их неутолимы.

Планету спутав с атомным ядром,
они её разъяли, расщепили.
И кончится ли это всё добром?
Куда ведёшь, история? К могиле?

С приходом лета молния, разя,
поёт стрелой, – что значат песни эти?
Я – сверстник бомбы атомной.
Нельзя нам сосуществовать на белом свете!

## Тормыш арифметикасы

Әткәй кайтты. Сугыштан соң тудым.
Саннар тапкырларга өйрәндем.
Һәр җан җирдә бары тик бердәнбер.

Кушканнар да безне, бүлгәннәр дә...
Җир тарихын яттан өйрәндем.
Санап бетә алмыйм – җирдә күпме кабер.

Бәхетлегә саннар кирәк түгел.
Бурычым күп. Кайчан түләрмен?!
Кемгә – кабер илдә, кемгә – хөрмәт-кадер.

Ике давыл арасында яшим.
Мин бер генә тапкыр үләрмен...
Бер кат яшим җирдә, бары тик бер!

Гомер? Гомер!

## Арифметика жизни

Отец вернулся. Я – послевоенный.
Считать у жизни научился я.
Один умножить на один – один:
Закон несокрушимый бытия.

Чингизы, Грозные прошли по жизни...
Судьбу земли я знаю назубок.
Но все могилы сосчитать земные
За десять жизней я б и то не смог!

Не надо мер, чтоб мерить беспредельность,
Не нужно сердце глупостями ранить –
Кому судьба могилу сохранила,
Кому нетленную народа память...

Мы все живём под небом ярко-синим.
Мы знаем – были, будут ураганы.
В какой стране мы в звёзды души кинем?
Один умножить на один...
Как странно...
Всего один.

* * *

Мин яу булып түгел, яучы булып
Бусагаңа бастым, Европа.
Дөньябызда әле хаксызлык күп –
Берәү елый, берәү елата.

Без күтәргән йөкне кем җиңел ди!
Кем кайгыны безнең аз дия?!
Азияне Европага димлим,
Европаны сиңа, Азия.

* * *

Нет, я не ратником – послом
Вступаю на порог Европы.

Земля сотворена не злом,
Но злом наполнены окопы.

Земное горе не измерить,
Не исчерпать страданий, слёз.
К порогу веру я принёс:
Настало время в мир поверить.

## Көтү

Әнисеннән ул елмаю көтте,
Әтисеннән – киңәш,
Дошманнардан иң көчлесен көтте,
Дусларыннан – тиңдәш.

Болыт килсә, ул кояшны көтте.
Аяз булса – болыт.
Юкәләрдән һаман алма көтте,
Тупыллардан – шомырт.

Шагыйрьләрдән акыллы сүз көтте,
Музыканттан – зур хис.
Кешеләр аннан көлеп сөйләделәр:
«Ул көтәргә хирыс...»

Ә хатыны тап-тар бүлмәсендә
Көтте кара малай.
Язмыш көтте, җилдән бишек асып
Кәкре карамага.

## Ожидание

Он ждал совета от отца,
От матери – улыбки.
Он ждал с рожденья, без конца,
Не ведая ошибки.

Он солнца ждал в дождливый день,
В погожий день – тумана,
Добра он ждал от злых людей
И яблок – от каштана.

Он жаждал силы от врага
И равенства – от друга.
«Он ожиданьями богат», –
Смеялась вся округа.

Он от поэта ждал ума,
От музыканта – чуда.
И вот явилась жизнь сама –
Он ждал её покуда...

В квартире собственной, пустой
Глаза жены увидел:

«Не плачь, родимая, постой...
Чем я тебя обидел?..»

И долго зыбку он качал,
Не ведая ошибки:
Лишь ветер плачем отвечал
Из необжитой зыбки...

## Иң беренче тирәк

Эшлә, дисең. Кулларыма минем
Тоттырасың көрәк.
Эш – мәңгелек, эш ул – тамак ялы.
Миңа бәхет кирәк.

Чокыр казы. Менә шушы төшкә
Утырт, дисең, тирәк.
Утырттым ди. Үсә бирсен әйдә...
Миңа бәхет кирәк.

– Төбен йомшарт, яраларын бәйлә,
Суын сипмә сирәк.
– Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

– Үскән инде. Калдыр тирәгеңне.
Ары киттек тизрәк.
Үстер, дисең, бакча. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

– Хәзер инде шушы һөнәреңне
Башкаларга өйрәт.
– Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

...Эш күрсәтеп, кулларына бирдем
Балта, пычкы, көрәк.
Кабатлады алар, миңа кушылып:
«Безгә бәхет кирәк».

Сорадылар аннан: «Бәхет ни?» – дип,
Ярсып типте йөрәк...
Сүз тапмадым. Искә төште шулчак
Иң беренче тирәк.

* * *

Меня приучали к работе,
И я терпеливее стал.
Работу любил, а ночами
Я только о счастье мечтал.

Мальцу мне вручили лопату:
– Копай!
Я усердно копал.

– Сажай!
Посадил я берёзу.
Но только о счастье мечтал.

– Взрыхли и полей! – приказали.
Взрыхлял и водой поливал.
Я слушался старших, но всё же
Я только о счастье мечтал.

– Закладывай сад, ты умеешь.
И я заложил, не устал.
– Я сделаю всё, – говорил я,
Но тайно о счастье мечтал.

– Теперь обучи-ка ты сына,
Чтоб сам он себя испытал.
И я обучал. И опять же
Я только о счастье мечтал.

Я сыну дал в руки лопату:
– Копай!
Он усердно копал.
И я пожелал, чтоб он тоже
Всю жизнь о счастье мечтал.

* * *

Дөнья матур,
Шуның өчен дә бит
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан...

*Һади Такташ*

Дөнья матур, Такташ җырлаганча,
Тукай шигыре кебек оптимист.
Мәшрикъ белән мәгърип буталдылар...
Менә гаҗәп! – таң аттырдык кич.

Айны ваклап, йолдыз ясадылар,
Кеше саен хәзер бер йолдыз.
Юллар тигез, арттан еллар куа.
Без соң әле кая барабыз?

* * *

Мир прекрасен – и потому
Не могу удержаться от крика...

*Хади Такташ*

Такташ, понятен мне такой восторг.
Улыбчив мир, он – как стихи Тукая.
Перемешались запад и восток.
Живу, рассветы вечером встречая.

У каждого из нас своя звезда,
Свои надежды и свои тревоги.

И оттого что гонят нас года,
Опять бегут за горизонт дороги.

## Бер кайтырмын әле...

*Сибгат Хәким истәлегенә*

Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,
Туу белән үлем булган чакта.
Чәч агаргач, шигырь язып кара...
Һәркем шагыйрь юләр балачакта.

Еллар йөге баскач иңнәреңә,
Очып кара хыял канатында.
Гомер буе җыйган байлыгыңны
Син чәчәргә тиеш, таратырга.

Ай-кояшка тиңдәй, Тукай барда,
Туфан барда, шагыйрь булып кара...
Охшатам мин моңлы язмышымны
Кояш нуры иңгән болытларга.

Гашыйк идем язгы бураннарга,
Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.
Исемемне онытмаслар әле,
Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.

Мин киткәч тә, дөнья матур булыр.
Моңсуланыр Аккош күле генә...
Аккош булып бер кайтырмын әле,
Ышанмагыз минем үлемемә.

## Я ещё вернусь

*Памяти Сибгата Хакима*

В поэтах не станет особой нужды –
признаемся честно и трезво.
Ты вот напиши, если пряди седы,
а в юности всяк пишет резво...

Дерзни, если рот зажимают тебе,
взлететь, словно вправду на воле,
всей горькою жатвою в пику судьбе
засеять грядущее поле...

Попробуй писать, если рядом – Тукай,
стань рядом с Туфаном-поэтом!
Судьба же моя, как в неё ни вникай,
что туча, пронзённая светом...

Любил я бураны по ранней весне,
влюблялся я в марево лета.
Пока есть любовь – память есть обо мне,

кто любит, тот вспомнит поэта.

Уйду, и Лебяжье окутает грусть,
но мир не прервёт круговерти.
Я лебедем белым однажды вернусь,
не верьте в бессмыслицу смерти.

## Трамвайда

Көтмәгәндә яңгыр түккән өчен
Сүгә-сүгә болыт ертыгын,
Чыланудан качып, трамвайга
Болай гына кереп утырдым.

Трамвайга кыйбла кирәк түгел,
Аңа барыбер, кая барса да...
Рельслардан чыгып булмый ла шул, –
Китәр идек туры Арчага.

Чабар идек Тукай якларына,
Әй, тәгәрәр иде «Кисекбаш»...
Бер-беребезне аңлар идек әле, –
Тукай белән без бит гасырдаш.

Кая илтә мине язмыш юлы? –
Тирә-юньдә юк дус, юк таныш...
Авыр сулап, кемдер әйтеп куйды:
«Килеп җиттек. Соңгы тукталыш».

## В трамвае

Из окаянного дождя,
разрывы туч кляня,
в трамвай случайный
впрыгнул я,
и... он увёз меня.

Ему лишь рельсы и нужны,
катит себе, пыля...
Попасть бы с Арской стороны
в бессмертные поля!

К Тукаю, как к себе домой,
прибыть бы и – шабаш!
Эх, и катился б вслед за мной
базарный Кисекбаш[1]!

В какой приехали мы край?
Ни друга, ни огня...
«Конечный пункт. Слезай давай!» –
и гонят вон меня.

## Авылга кайту

Ашыктырып этә иңнәремнән
Туган якка буран.
Өянкеләр авыл башынача
Каршы чыгып торган.

Карт өянке, давылдандыр инде,
Каерылган, сынган.
Күтәрелеп килә алсу кояш, –
Җир йөрәге сыман.

Ал кояшка таба йөзне тотып,
Күпме юллар үттем!..
Дөньяда тик безнең авылдадыр
Ипи исле төтен.

Олы хисләр, олы омтылышның
Туган якта башы.
Шушы җирдә туган хыялларым
Шунда чынга ашты.

Туган авыл – соңгы станция...
Кайтам сине уйлап,
Ике рельс кебек ялтыраган
Чана юлы буйлап.

## Возвращение

Оставив прежние заботы,
Иду в родной аул.
Метель.
Сейчас за ближним поворотом
Знакомую увижу ель.

Она моей руки коснётся.
Её снега не замели.
В её ветвях мерцает солнце,
Как сердце матери-земли.

Воспоминания вернули
Меня к восторгам молодым:
Лишь здесь, лишь здесь, в родном ауле,
Печёным хлебом пахнет дым!

Свершенья все мои не здесь ли
Своё начало обрели?
Здесь все мои рождались песни,
И здесь начало всей земли!

Аул мой! Станция надежды!
Уже с дороги не свернуть:
Как будто рельсы –
            яркий, свежий,
Горит, сияет санный путь.

# Сабантуй

Байрак булып күккә күтәрелгән
Сабантуйның чуар сөлгесе.
Ат уйнатып йөри чабышчылар,
Мәзәк сөйли шаян теллесе.

Аксакаллар әнә горур атлап
Узып бара мәйдан түренә.
Ә малайлар, иң беренче тапкыр
Көчне сынап, билгә үрелә.

Авызларга кашык кабып кына,
Су ташыйлар авыл кызлары;
Берәүләрнең күзе юл башында –
«Алмачуар быел узармы?!»

Яулык белән күзне бәйләсәң дә,
Челпәрәмә килә чүлмәкләр.
Көрәшченең биле кысылганда,
Кысылалар безнең йөрәкләр.

Кызлар гына түгел, табигать тә
Аллы-гөлле яңа киемнән...
Якты күзен олы итеп ачып,
Хәтта кояш җиргә иелгән...

Яшел чирәм яшел ястык кебек,
Хозурланып, җиргә ятарлык.
...Тәүге шатлык килә Сабантуйда,
Һәм кылына тәүге батырлык.

# Сабантуй

Июнь раскинул скатерть на полмира.
И праздник горячит людскую кровь.
Благослови рождение батыра
И первую благослови любовь!

И вот расшитый женскими руками
Над Сабантуем взвился яркий флаг...
Храпят под молодыми седоками
Лихие кони – не сдержать никак!

Вон аксакалы ходят по майдану,
Спокойные седые старики.
Борцы себя готовят к испытанью,
На прочность проверяют кушаки.

И вот они стоят друг против друга –
Товарищи, соперники, борцы;
Вот ноги отрываются от круга –
И замирают старцы и юнцы.

На Сабантуе сложные задачки:
С повязкой на глазах горшок разбить,
Быть первым на горячей конской скачке.
Да только ль скачке! Всюду первым быть!

Река, поляна – всё вокруг прекрасно,
И значит, все прекрасны быть должны!
А солнце в небе так сияет ясно,
И так глаза у девушек ясны!

Июнь раскинул скатерть на полмира.
И праздник горячит людскую кровь!
Благослови рождение батыра
И первую благослови любовь!

## Авылда туй

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә!
Авылда туй. Тракторчы егет
Сыер савучыга өйләнә.

Урамнар тар бүген егетләргә,
Җыр агыла басу ягына.
Бии бабай. «Кеше көлдермә» дип
Еламсырап, әби ялына.

Коеларның суы эчелеп беткән,
Аргамаклар баткан күбеккә,
Иске җырлар яңа булып яңгырый, –
Тургай кунганмыни күреккә!

Авылда туй. Гап-гади бер егет
Гап-гади бер кызга өйләнә.
Машиналар тынып калган бүген...
Атлар чаба, чаба... әл-лә-лә!

Калым да бар, бирнә дә бар туйда...
«Нинди искелек бу?» – димә лә.
Егет батырлыгы калым булса,
Кызның мәхәббәте – бирнәгә.

Чаба-чаба тезгеннәрне өздек,
Тик һаман да җырлар өзелми!
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Кыңгыраулар ярсып зеңгелди.

Урамнарны иңләп, шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны! –
Керсен бәйрәм татар өенә.

## Свадьба в деревне

Ворота – настежь!
Светом окружённый,
Татарский туй выходит из ворот!
Сегодня тракторист весёлый
в жёны
Доярку чернобровую берёт!

Тесна сегодня для парней округа,
Поспорит с солнцем свет девичьих глаз!
Старуха тянет за рукав супруга:
«Стыдись!» А тот уже пустился в пляс!

Копытами постукивают кони,
И каждый конь – испытанный в бегах!
Сегодня широка душа гармони –
Не жаворонки ли в её мехах?!

В деревне свадьба.
Слушают просторы
Парней запевки, звонкий смех девчат.
Пускай молчат железные моторы,
Пускай копыта конские стучат.

Приданое – достойное калыма:
Не пережиток то, не старина.
Принёс в калым он доброту и силу,
А красоту в приданое – она.

Вот-вот порвутся конские поводья,
Но не прервётся песенная нить.
И колокольцы, чтимые в народе,
Пусть не устанут радостно звонить!

Взлетают песни, день сияет ясный!
Раздайся шире, праздничный народ!
Ворота – настежь! Радостный, прекрасный,
Татарский туй выходит из ворот!

## Мәҗүси

Мин, кыйбламны эзли-эзли,
Берүзем җир буйлап барам.
Язлар белән яшелләнәм,
Кышлар белән чал агарам.

Оҗмахым да – бу тормышым,
Тәмугым да – бу тормышым...
Әкиятләргә ышанырга,
Табынырга күп тырыштым.

Барып кердем урманнарга,
Килеп чыктым киң кырларга...
Сызгырмадым урманнарда,
Ашыкмадым җыр җырларга.

Оста барда, телең тый, ди...
Телем тыйдым, тургай барда.
Бәхет керсә төшләремә,
Куркып яттым уяныргa.

Сокландым мин имәннәргә,
Сокландым мин усакларга...
Агачларны бергә җыеп,
Их, бер кысып кочакларга!

Мин нарасый бала бугай...
Шаман кебек шашып көлдем,
Барып чыктым җир читенә...
Очрамады миңа үлем.

Очсам – күгем, йөзсәм – күлем,
Иярләнгән атым көтә...
Бер мәҗүси бала кебек –
Табынам гел табигатькә.

## Язычник

Рожден не охать и не ахать,
иду по жизни. Даль видна.
Зимой бела моя рубаха,
весной, как листья, зелена.

Не верю сказкам! Ярче брызни,
лавина солнечных лучей!
Я рай познаю в этой жизни
и ад познаю только в ней.

Вникаю в речь ручья лесного,
в полях терпению учусь.
И не спешу промолвить слово,
и песню спеть не тороплюсь.

Есть мастера – молчи и слушай!
Вот соловей поёт. Молчу.
Усну, а песня льётся в душу,
и просыпаться не хочу.

Берёзам кланяюсь, осинам,
я целый лес обнять готов,
себя почувствовав единым
с весёлым трепетом листов.

Да! Я, наверное, язычник,
Смеюсь, ступив на край земли.
– Где смерть моя? – окликну зычно.
Лишь эхо катится вдали.

Вот небеса – лети, как птица!

Течёт река – ныряй, плыви!
Душа, гармонии частица,
волнуйся, радуйся, живи!

## Юлларым

Юлларым, юлларым, юлларым,
Юлларым уралган буранга.
Уйларым, уйларым, уйларым...
Кагылма ярама, сорама.

Кырларым, кырларым, кырларым,
Кырларым шатлыгы – тургайлы!
Урманым, урманым, урманым...
Ул миңа гел бәхет юрады.

Инешем, ак чишмәм, тауларым,
Талларым, кырларым, кошларым!
Мин сездә күпме җәй җәйләдем,
Мин сездә күпме кыш кышладым.

Мин киттем. Калдыгыз, калдыгыз...
Юлларым, иң якын дусларым!
Ә хәзер йортым да, юлым да –
Җырларым, җырларым, җырларым.

## Дороги

Леса, родники и дороги
В привольном родимом краю.
Как много, однако, как много
Вмещается в душу мою!

Хоть я и не лезу в пророки,
Родные люблю берега.
Мир вам, родники и дороги,
Леса, небеса и луга!

Быть может, умру я до срока.
Не плачьте по мне, соловьи,
Ведь лес, и родник, и дорога
Вливаются в песни мои.

## Урман

Ил урманы көн-төн шаулый.
Урманда без куак түгел.
Әйдә, түрдән узыйк әле, –
Без бит монда кунак түгел.

Сыйпап узыйк чәчәкләрне:
Алар – олы урман яме.
Олысына, кечесенә
Бер үк җылы нур тияме?

Анда берәр сөрхәнтәе
Тимәгәнме кырмыскага?
Кечеләрне кимсетергә
Кайберәүләр, һай, оста ла.

Күрә калсаң андыйларны,
Йөзенә бәр, әйт турысын.
Каеннар да, мин ак, диеп,
Алгы рәткә чыкмый торсын.

Тыңлап торма: «Нарат яхшы,
Усак начар», – дигәннәрне.
Һәр агачның үз урыны –
Күккә чөймә имәннәрне.

Урман булгач, урын җитәр
Имәнгә дә, үләнгә дә.
Аланнарда пешсен җиләк,
Гөмбә үссен күләгәдә.

Монысы карт, кирәксез, дип,
Ташлап китә күрмә тагын,
Ныграк назла андыйларны,
Ә корыса, кис ботагын.

Ил урманы көн-төн шаулый.
Урманда без куак түгел.
Түргә атла хуҗа булып,
Син бит монда кунак түгел.

## Лес

День и ночь шумят леса родные,
мы в родных лесах не сухостой,
мы идём вперёд и не впервые
званы в лес, пожить иль на постой.

Головы живых цветов погладим,
и, кому быть рослым суждено, –
вырастет, и мы всегда поладим –
солнце греет общее, одно.

Кто по муравьиной пирамиде
прошагал, живое потопча?
Множество сирот в глухой обиде,
но простят слепого палача.

Тем слепцам, бездумным и бездушным,
встретив, растолкуй закон лесной.
Пусть берёзы в образе воздушном
не бегут хвалиться белизной...

Отмолчись, когда сосну восславят

в качестве царицы всех лесов.
Все равны. И дуб, который правит
службу свою испокон веков, –

равен всем, и всем хватает места,
хватит всем и солнца, и судьбы.
Созревает ягода-невеста,
а в её тени растут грибы.

Если видишь сирых или хилых,
задержись, уйти повремени,
коль в тебе, когда помочь ты в силах,
больше всех нуждаются они.

День и ночь шумят леса родные,
мы в родных лесах не сухостой,
мы идём вперёд и не впервые
званы в лес, пожить иль на постой.

## Аучы

Дары. Ядрә. Мылтык. Ике көпшә.
Бармак капшый корыч күрекне.
Җәнлек кача. Аучы өзгәләнә,
Ычкындырдым, диеп, бүрекне.

Тагын дары. Тагын ядрә. Мылтык.
Ат, ат тизрәк! Нәрсә көтәсең?
...Аучы күкрәгенә ачу белән
Кире бәрә мылтык түтәсе.

Һәр көн саен шулай, һәр ел саен,
Шулай булган мең ел, гасырлар.
Усалланган кеше. Бар кошларны,
Җәнлекләрне читкә качырган.

...Җәнлек тунын нигә кия кеше?
Лаеклырак үзен саныймы?
Әллә соң бу, үзе дә аңламыйча,
Маймыл бабаларын сагынумы?

## Охотнику

В патроне порох, дробь и пыж.
А на морозе зябко.
И ты с досадою глядишь:
Мол, ускакала шапка.

Уходит в ствол другой патрон.
Быть может, в нём удача?..
Тяжёл приклад. И лупит он
Тебя в плечо отдачей.

Так было сто, и двести лет,

И триста лет, и тыщу.
Зверья давно в помине нет,
И птицы не отыщешь.

Ужель без шубы жизнь не в жизнь?
Без меха жить нельзя ли?
Хотя, конечно, мы же из
Породы обезьяньей.

## Язгы урман

Җил зәңгәре сеңгән карга –
Күк үзе көнләшерлек!
Ак каеннарның күзенә
Күренә тик яшеллек.

Бар агачлар караганнар
Көзгедәй күлләвеккә.
Алтын кояш нур җебеннән
Аларга күлмәк тегә.

## Весенний лес

Весенний ветер отдал синеву
Снегам, они уже полны водою.
Уже берёзы бредят наяву
Листвой – зелёной, сочной, молодою!

Вот-вот горластый выбьется ручей
На волю из-под синего покрова,
А солнце ткёт из золотых лучей
Деревьям изумрудные обновы.

## Дисбе

Орчык тартып, әби җеп эрләде,
Эрли-эрли, җырын җырлады:
«Йон бәйләгән кабам кояш кебек,
Орчык җебем – кояш нурлары...»

Әби, әби, синең истәлекне
Ничек кенә инде яңартыйм?!
Кулларымда синең серле дисбең,
Күз алдымда җылы мич артың...

Минем әткәй – синең шахтёр улың,
Зур Исмәгыйль аның исеме, –
Күчтәнәчкә җимеш алып кайткан,
Төшләреннән җыйган дисбеңне.

Шул дисбеңне тартып ялваргансың,
Нык булсын дип шахта тирәве.
Теләкләрең кабул булган синең...
Әле дә тибә әткәм йөрәге.

Сугыш килгән. Шул дисбеңне тартып,
Син озатып аны калгансың,
Күз яшенә манма сүзләреңне
Ишеткән тик яшел намазлык.

Әткәй хәзер телевизор карый,
Алланы ул бераз оныткан.
Тик шулай да сине онытмаган,
Кабереңә каен утырткан.

Күз яшьләрең сеңгән намазлыкны
Яшереп куйган сандык төбенә.
Искә төшкән саен алып карый,
...Ул кадәр үк «көфер» түгел лә.

Кулларыма серле дисбең тотып,
Мич артында уйлап утырам...
Мич елый да елый, әллә инде
Эченә кайгы кереп утырган.

Минем хәзер, әби, үз иманым,
Минем, әби, хәзер үз Аллам...
Тик шулай да, кайгы килгән чакта,
Кулга дисбең алып уйланам.

## Чётки

*(Памяти бабушки)*

Твой светлый образ
            ясно, чётко
Запечатлён в моей судьбе.
Отполированные чётки
Напоминают о тебе...

Твой сын, шахтёр,
            в земле глубокой
И днём и ночью соль рубил.
Из фиников, плодов Востока,
Тебе он чётки смастерил.

Перебирая чётки эти,
Молила Бога ты всегда,
Чтобы канат у шахтной клети
Не оборвался никогда.

Случались дни крутых событий...
И, силясь одолеть беду,
В твоих руках по тонкой нити
Метались чётки, как в бреду.

Они ль спасли отца-солдата
В огне войны?
Конечно, нет.

Но каждая лихая дата
На чётках оставляла след.

Минули годы торопливо...
Я не забуду ничего.
Отцом посаженная ива
Склоняет ветви молчаливо
У изголовья твоего...

Горит огонь в старинной печи,
Не нарушая в доме тишь.
И ты со мной заводишь речи,
Под шёпот чёток говоришь:

«Сруби свой дом.
            Пусть сын родится.
Пусть радость вселится в твой дом.
А если умереть случится –
То в день, заполненный трудом...»
Йорт салыгыз, уллар үстерегез,
Бәхет керсен, диден, өйләргә...
Насыйп булсын, диден, туган җирдә
Буразнага ятып үләргә.

Иген чәчмим, әби, ачуланма,
Бер «җилкуар» шунда, җыр язам.
Ә җыр язу шулкадәрле авыр,
Җибәрми ул, алса бугаздан.

Дисбеӊ исән... Күрсәӊ иде, әби,
Дөнья хәзер ничек үзгәргән...
Ә мин һаман тугрылыклы сиӊа:
Дисбе тезәм, әби, сүзләрдән.

Прости меня:
            я хлеб не сею,
Не добываю в шахте соль.
Я песни лишь слагать умею,
И то – когда подступит боль.

И эти песни, словно чётки,
Напоминают о тебе.
Твой светлый образ
                  ясно, чётко
Запечатлён в моей судьбе.

## Игенчеләр нәселе

Җиргә ятып сабан сөргән бабам,
Чалгы селтәп чапкан печәнне.
Аршын түгел, метр, сажин түгел –
Өмет булган җирнеӊ үлчәме.

Гомерендә алтын күрмәгән ул,

Янчык тулы көмеш йөртмәгән.
Алтын төсен күргән игеннәрдә,
Көмеш сулар эчкән чишмәдән.

Ракеталар очмаса да ул чак,
Ай турында җырлар җырлаган.
Ачмаса да серен йолдызларның,
Күккә карап, язмыш юраган.

Вакыт җитте безгә, галәм иңләп,
«Карурман»ны җырлап үтәргә...
Тик һаман да туган җирне сөю
Җитеп бетми әле күпләргә.

Нәселемә мин хыянәт итмәм! –
Игенчеләр безнең ыруда.
...Буразналар ярып барсаң иде
Шигъриятнең олы кырында.

## Род земледельцев

Мой дедушка за плугом, словно тень,
Ходил по полю, отдыха не зная.
За горизонт (измерит ли сажень?)
Ушла навеки борозда земная.

За всю свою натруженную жизнь
Ни серебра, ни злата не дождался,
Зато держал в ладонях злато ржи
И в родниковом серебре купался.

До спутников ещё мир не дорос –
А дед пел о луне и мирозданье.
И, не постигший тайн высоких звёзд,
По звёздам он загадывал желанья.

Настало время: сокрушаем льды
И бороздим космические дали.
Вот только б не забыть нам борозды,
С которой деды наши начинали!

* * *

Яшьләрне бит галәм кызыктыра,
Кызыктыра мода, рок-н-ролл.
Озакламый салып куярбыз күк
Ай янына кадәр такыр юл.

Бөтен нәрсә җирдә җитешмени! –
Күзләребез күккә төбәлгән.
Ә Җир безгә, ятим бала кебек,
Гаҗәпләнеп карый түбәннән.

Безнең өчен урман – ял урыны,
Алып бара анда машина.

Кайвакытта, гидка ияреп без,
Чыккалыйбыз авыл башына.

Исәплибез бүген көн буена:
Ракеталар күпме юл узган,
Булмаганмы давыл Меркурийда,
Атмаганмы вулкан йолдызда...

Без төп-төгәл әйтеп биралабыз
Йолдыз белән йолдыз арасын.
Ачтык әнә музей, күргәзмәләр –
Үткән буын килеп карасын.

...Картлар йөри шәһәр урамында,
Моңсуланып, җиргә сыенып,
Йөри алар, кибет саен кереп,
Ипи муллыгына сөенеп.

* * *

Нас манит космос.
Мы спешим за модой,
Постигли твист, и шейк, и рок-н-ролл,
Давно уже
на ты с самой природой,
Которая даёт и дом, и стол.

И это всё прекрасно:
и музеи,
И космос, и протоны, и кино.
Но,
в телескоп иль на экран глазея,
Не позабыть бы всем нам про одно –

Про то,
о чём отцы не позабыли,
И деды повторяют меж собой:
«Как хорошо, что хлеба – в изобилье,
Как хорошо, что он
недорогой!»

## Җиргә мәдхия

Бу агачлар агач түгел әле,
Бу агачлар – җирнең өмете.
Бу далалар дала түгел әле,
Бу далалар – җирнең киң бите.

Елгалар да елга түгел әле,
Алар бары җирнең күз яше.
Таулар да тау түгел – җир сакчысы,
Ә болытлар – җирнең түшәге.

Давыл, туфан, вулкан берни түгел,
Алар – җирнең көче, тавышы.

Бу бомбалар бомба түгел әле,
Бу бомбалар – кеше ялгышы.

Кояш кояш түгел – җир яктысы,
Ә йолдызлар – җирнең маягы,
Мине сугыш исән калдырмады,
Мине шушы җирем аяды.

Ул ул түгел әле, ул – минем дус,
Күк күк түгел – Киек Каз Юлы.
Мин мин түгел әле, мин уйламыйм,
Минем аша Җир бу, Җир уйлый.

## Ода Земле

Дебри лесные земля породила,
пашни – надежда и соки земли,
степи – её затаённая сила,
в древних морщинах и знойной пыли.

Слёзы её – полноводные реки,
стражи – вершины скалистой гряды.
Помнят присягу, верны ей навеки,
ночью и днём стерегут от беды.

Но пострашнее природной стихии
были жилища в дыму и в огне,
помнит земля наши годы лихие,
кровью вспоили её на войне.

Чёрной работой себя натрудила
матерь-земля ради нового дня.
Это меня не война пощадила,
это земля сохранила меня.

С ней свои лучшие дни коротаю
в милом своём плодородном краю,
я её вечные мысли читаю,
я её вечные песни пою.

## Казан белән саубуллашу

Казанның җәе шәп иде,
Шәп иде бураннары.
Казанда көз кызгылт иде...
Ә монда никтер... сары.

Казанда сөю бар иде,
Актан иде йортлары.
Нигә үпкәләде Казан? –
Озатырга чыкмады...

Без дала балаларына
Казанда юллар тармы?

Белмим, белмим... Мин – Мәскәүнең
Миллионынчы татары...

## Прощание с Казанью

Лето солнечно в Казани,
А зима – метель, мороз.
Осень в красном сарафане,
А в Москве – из жёлтых роз...

Белокаменный мой город,
Черноокая, прости!
Улыбаясь светофорам,
По Москве бежит такси...

По Таганке, по Арбатской
От судьбы или к судьбе?..
Миллионный сын татарский
Я в сегодняшней Москве.

* * *

Бу төн шундый озын,
Бу төн шундый чиксез, –
Хәтта атылган йолдыз да
Җиргә төшеп җитми.

* * *

Ночь до того глубока,
Что и падучей звезде
Спящей земли не достичь.

## Самолётта

Самолётта очам, самолётта...
Аста калды Мәскәү, Касыймнар.
Монда инде мәңге болыт булмый! –
Аермачык монда гасырлар.

Рәхәтият иле шушы мәллә?
Шушы мәллә минем өлешем?
Бөтен нәрсә монда күктәгечә:
Хәтта кызлар кәнфит өләшә.

Җирнең генә түгел, кояшның да
Буйсынам мин тарту көченә...
Бабам хыялланган күккә мендем!
Нәрсә кирәк тагын кешегә?!

Гасырлар һәм чорлар кысылдылар,
Тарих сыйды сәгать эченә...
Сәгать нәрсә? – Аяз күктә вакыт
Чак(ы)рымнар белән үлчәнә.

Самолётта очам, самолётта –
Мин дә менә күккә мендем бит!
Ут кабызган аэропортлар кебек,
Бар йолдызлар тора тезелеп.

## В самолёте

Лечу в самолёте, качает слегка,
Промчали Москву и Касим.
И наш самолёт надрезает века
Крылом реактивным, косым.

Не я ль очутился в счастливой стране,
Что выше знакомой планеты?!
Небесные девушки запросто мне,
Смеясь, предлагают конфеты.

А до Казани лететь только час...
Мечтал ли мой дед о подобной судьбе!
Не только земля, но и солнце сейчас
Притягивает к себе.

Событья столетий вместились в часы,
Сместились понятия в мерах.
Здесь крылья – полётных нагрузок весы,
А времени счёт – в километрах.

Попробуй-ка с неба меня столкни,
Я силою полн неземною!..
Аэропорта мерцают огни,
Как звёзды, что рядом со мною.

## Казан поезды

Мәскәүдәге Татар зиратыннан чыккач,
Казан вокзалына килеп,
мин һәрвакыт поезд көтәм, –
Казан поездын.
Шпаллар хыянәтен
бары тәгәрмәчләр белә торган,
тарих китабыдай тигезсез тавышлы,
ике рельслы
поезд көтәм, –
Казан поездын.
Вокзал өстендәге
«Мәскәү» дигән язуларны,
Сөембикә манарасы шәүләләрен,
ерактагы азаннарны уйлап,
поезд көтәм, –
Казан поездын.
Тепловозга
«Татарстан» вагоннары урынына
ялгыш
башкаларны тагарлар дип курка-курка,

поезд көтәм, –
Казан поездын.
Килер,
аклы-каралы шлагбаумнарны һуштан
яздыра-яздыра
килер ул поезд!

Мин бүген –
марка ябыштырмыйча,
почта әрҗәсенә ташланган хат кебек.
Үзем һаман поезд көтәм, –
Казан поездын...

## Казанский поезд

Когда я выхожу с Татарского кладбища в
Москве,
Всегда прихожу на Казанский вокзал
и поезд жду,
Казанский поезд.
С колёсами,
лишь которым известны преступления шпал,
неровноголосый, как книга истории,
поезд жду,
Казанский поезд.
Думая о надвокзальных надписях,
о призраках башни Сююмбике,
о далёких азанах,
поезд жду, Казанский поезд,
боясь, что вместо зелёных вагонов «Татарстана»,
прицепят другие, чужие,
поезд жду,
Казанский поезд.
Придёт,
с ума сведя чёрно-белые шлагбаумы,
придёт этот поезд!
Я сегодня – как письмо
без марки, опущенное в почтовый ящик.
А сам всё ещё поезд жду,
Казанский поезд...

## Театр

Әйләнә карусель, әйләнә...
Карусель корылган хәйләгә.

*Мостай Кәрим*

Әйләнә дөньялар, кешеләр, –
Кышларым язларга әйләнә.
Шаккатып, онытып торам мин
Йөрәгем ярасын бәйләргә.

Әйләнә авыллар, шәһәрләр,
Кайгылар шатлыкка әйләнә.

Чуалган, таралган уйларым
Тезелә шулвакыт сәйләнгә.

Сәхнәгә чыгуга, һәрвакыт
Нигәдер телләрем бәйләнә.
Әйтерсең язмышым шушында
Түгәрәк бәхеткә әйләнә.

Бу залга керүгә, бар кеше
Иң яхшы кешегә әйләнә, –
Кайгысын калдырып урамда,
Кергән күк илаһи бәйрәмгә.

Патефон табасы шикелле,
Театр сәхнәсе әйләнә.
Елата, җырлата, юата, –
Театр корылган хәйләгә.

## Театр

Карусель всё вертится и вертится...
Карусель построена на хитрости...

*Мустай Карим*

Вращается вода, весь мир вращается,
В свой срок снега в поляны обращаются,
И сердца боль вовек не прекращается,
Покуда есть круговорот утрат.

Да, никогда родник не истощается,
Да, радости с душою не прощаются,
А думы мои к дому возвращаются,
Как лебеди, выстраиваясь в ряд.

Вхожу в театр. И время быстротечное
Движенье останавливает вечное,
И кажется:
Раздумьями просвечена,
Душа здесь лучше слышит во сто крат.

А впрочем, это и не мной замечено:
Душа любая будет здесь излечена,
Погода здесь сугубо человечная:
На смену декабрю приходит март.

Вращается пластинкой патефонною
В безмолвном зале сцена полутёмная.
И пробуждает чувства в нас огромные
На хитрости построенный театр!

## Иске көймә зары

Тыңладым мин машиналар шавын,
Күрдем кызлар кирпеч өйгәнен.

Әй, беләсе иде ни уйлавын
Яр буенда иске көймәнең?

...Актарылды туфрак, ауды таллар,
Күтәрелде гасыр тузаны.
Моңсуланып карап торды көймә
Горур атлап заман узганын.

Урамнарны иңләп йөрде заман...
Ә заманга урын гел түрдән.
Кирпечләрдән чәчәк ясый-ясый,
Такыясын ташчы кыз үргән.

Карт көймәнең күңелендә сагыш...
Япа-ялгыз калгач, нишләсен?
Дулкын бәргән саен, талпына ул,
Онытадыр, ахры, үз яшен.

«Рәтләсеннәр, төзәтсеннәр иде,
Төясеннәр иде кирпеч, таш.
«Мин төзүче!» – диеп әйтер идем,
«Син кем?» – диеп дуслар сорагач.

Тирә-юньдә шундый дау барганда,
Кем тик ятар түзеп, кем йоклар...
Көне-төне дулкын яра әнә
Теплоходлар – минем оныклар.

Оныттылар мине, оныттылар...
Урын, диләр, сиңа музейда.
Бу якларны ташлап китә алмам...
Тән тузса да, йөрәк тузмый ла.

Иске яр да калыр минем белән,
Мине аңлый бары ул гына.
Яңа заман, яңа утлар, йортлар,
Яңа ярлар – яңа буынга...»

...Ишеттем мин машиналар шавын,
Күрдем кызлар кирпеч өйгәнен.
Һәм тыңладым моңсу хикәясен
Яр буенда иске көймәнең.

## Печаль старой лодки

Подходят самосвал за самосвалом,
Кирпич мелькает в девичьих руках.
И вдруг я вижу: лодка у причала
Качается печально на волнах.

О чем её печаль? Иль показалось?
Нет. Грустная уключина скрипит...
Зачем грустить ей, вызывая жалость,
Когда кругом строительство кипит?

Смолёная, она прошла все воды,
Она сама работницей была.
Но позади остались жизни годы –
Буруны от весёлого весла.

Она возила хлеб
и соль возила,
Кирпич тяжёлый, лёгкий разносорт.
А сколько раз волна разбить грозила
Её непрочный деревянный борт!

Она свой век в работе отслужила,
И что с того, что затужила вдруг?
Ведь не покинешь этот берег милый,
Когда такое здесь кипит вокруг.

Ведь твой причал –
он в пристань превратится
И станет памятью твоей любви.
А катера, летящие, как птицы, –
Ведь это внуки малые твои!

В могучем рёве дизельных моторов,
Который эхом разносился вдаль,
Я слышал скрип уключины, в котором
Почудилась мне тихая печаль...

## Кояш көлә

Кояш
Алтын тешләрен күрсәтеп
Көлә...
Карт бөркетләр
Таулар җырын җырлый,
Җырлап калыйм, дия.
Кояш көлә.
Капка астыннан башын тыгып,
Көчек өрә:
Тавыш сыный.
Кояш көлә.
Акчарлаклар,
Шаулы диңгез сорап,
Көне-төне елый:
Тавыш сыный...
Кояш көлә.
Сандугачлар, көне-төне сайрап,
Гөлҗимешләр сорый:
Тавыш сыный.
Кояш көлә.
Колагыңны җиргә карат!
Кояш көлә, димә.

## Смеётся солнце

Смеётся солнце
Золотозубо...
И пересохло
У птицы горло.
Из горла – клёкот,
И слышат горы:
То плачет беркут.
Смеётся солнце...

Из подворотни
Скулит от жажды
Щенок кудлатый.
Смеётся солнце...

В пыли деревьев
И дни и ночи
Из соловьиных
Раскрытых клювов
Мы слышим стоны:
Роса пропала.
Смеётся солнце...

Не слушай смех
Золотозубый –
Послушай землю
В такую пору!..

## Диңгездә ява яңгыр

Искә төшә әллә ниләр...
Сагышлар бигрәк авыр.
Инде менә ничәнче көн
Диңгездә ява яңгыр.

Чүлләрнең кипкән ирене,
Сөяк булган саксаул.
Оеп утыра барханнар –
Диңгездә ява яңгыр.

Саргайган йөзе болынның,
Иелгән бодай башы.
Күзе күктә игенченең,
Моңсу аның карашы.

Тын калган басу юллары,
Юк бер юлчы узганы.
Бер көндә куна тарихның
Бер гасырлык тузаны.
Искереп бетте кояш та,
Уңды күкнең буявы.
Күңел төбенә күмелгән
Бар сагышлар уянды.

Каралды күптән инеш тә –

Елганың зәңгәр җиңе...
Диңгезгә барып егылды
Даланың кайнар җиле.

Кунды йөзгә җыерчыклар –
Җир-анага, һай, авыр.
Әлсери кырда игеннәр...
Диңгездә... ява яңгыр.

## Море штормит

Жара такая – сгину вскоре.
Земля обуглится вот-вот.
Неужто вправду где-то море
Штормит
И ливень где-то льёт?

Сегодня травы бездыханны,
А ветер горячо дохнул,
Как раскалённые барханы,
Как почерневший саксаул.

Луга повсюду пожелтели.
В глазах крестьянина мольба.
А что, когда и в самом деле
Погубит засуха хлеба?
Растут заботы и тревоги.
В пыли деревья и кусты.
И в поле тропки и дороги
Который день уже пусты.

Нас птичьей песней не встречали
Давно и рощица, и лес.
Воскресли древние печали.
Зелёный свет вокруг исчез.

Ручьи затихли, обмелели.
Но где-то ведь идут дожди
И шторм грохочет...
Неужели?
Крута волна...
Проверь поди.

Невесел клён на косогоре,
И сиротливы тополя...
И, словно упрекая море,
Молчит усталая земля.

## Утлы хәтер

*(Реквием)*

### 1. Кырык беренче ел Сабантуе

Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,

Соңгы тапкыр кояш балкыды.
Таң атмады бүген, таң атмады, –
Алды җирне сугыш ялкыны.

Алды ялкын ил һәм дәүләтләрне,
Алды ялкын кыш һәм җәйләрне...
Туган якның данлы Сабантуе
Канлы Сабантуйга әйләнде.

Томырылды атта яшь егетләр...
Гомер буе көтәр чын ярлар.
Янса янар, әмма Берлингача,
Берлингача атлар чабарлар.

Европада – канлы Сабантуе,
Җирдә бүген – ялкын, көл исе.
Җиңү байрагыдай янып калды
Сабантуйның биек сөлгесе.

**2. Хатлар язам**

Әнкәем, хат язам:
Ничек соң хәлләрең?
Юрама яманга,
Килмәсә хәбәрем.

Әбкәем, хат язам
Сугышның эченнән.
Әйтерсең тәмугы
Бу җиргә күченгән.

Дусларым, хат язам:
Сез кайсы якларда?
Үлсәк тә, без тиеш
Дуслыкны сакларга.

Сөйгәнем, хат язам
Сугышның үзеннән...
Тик шәүләм сүнмәсен,
Китмәсен күзеңнән.

# Огненная память

*(Реквием)*

**1. Сабантуй сорок первого**

Вчера лучистым золотом сияло
Над нами солнце мирной тишины.
Сегодня небеса кроваво алы
Не от зари – войной обагрены.

Кого-то подпалил, кого-то сжёг дотла
Огонь войны, разлившийся рекой.
В тот год не Сабантуй весна нам принесла,

А пир смертельный на крови людской.

Несут джигитов скакуны дорогой длинной...
Девушкам своих парней до самой смерти ждать.
Пусть всё вокруг огнём горит, но до Берлина,
До самого Берлина коней джигитам гнать.

В Европе идёт адский пир на крови,
Зола, пепел, пламень лютует...
Подобно победному стягу горит
Священный рушник Сабантуя.

**2. Письма с фронта**

Здравствуй, мама моя,
Как дела, как сама?
Не грусти, если долго
Не будет письма.

Здравствуй, бабушка, ты
Знаешь, где это – ад?
Здесь дорогу к нему
Знает каждый солдат.

Где теперь вы, друзья
Мирных, радостных дней?
Будем дружбу хранить,
Станем смерти сильней.

Я к любимой пишу
С того света почти...
Затоскуешь, письмо
Разверни и прочти.
Әткәем, хат язам:
Юк башым игәнем,
Һәрвакыт хәтердә
«Сынатма!» дигәнең.

**3. Сугыш икмәге**

Чайкала арышлар, чайкала бодайлар,
Чайкалып куялар хатыннар.
Хәле юк, көче юк, дошманга үче бар,
Ватанга биргән зур анты бар.

Чайкала арышлар, чайкала бодайлар...
Айкала җаннары сагыштан.
Ашыга, каршыда ирләре көткәндәй,
Алар бит шушында табышкан, кавышкан.

Чайкала арышлар, чайкала бодайлар...
Кем әйтер, алар, дип, сугышка китмәде?!
Хатыннар сөюе, сагышы сеңгәнгә,
Татлы ул, ачы ул сугышның икмәге.

**4. Мәхәббәт һәм нәфрәт**

Сугыш килде безгә сорамыйча,
Шакымыйча керде ишектән.
Кабатладык шулчак, тешне кысып:
«Без җиңәргә тиеш ничек тә!»

Туп тавышы аяз күкне түгел,
Күңелләрне ныграк тетрәтте.
Ник уяттың, сугыш, вәхшилекне,
Ник уяттың кеше нәфрәтен?

Ни эшлисең, сугыш, илләр буйлап? –
Син кермәгән өйләр калмады.
Тик берәү дә сине колач җәеп,
Кунак итеп каршы алмады.

Туган җирнең азатлыгын тою,
Җир җылысын тою мең рәхәт! –
Дошманнарга нәфрәт арткан саен,
Туган җиргә артты мәхәббәт.
Не упал я, отец,
В грязь у вражеских ног,
Помнил главный наказ:
«Не сдаваться, сынок!»

**3. Хлеб войны**

Колышется рожь и пшеница колышется...
Женщин шатает и валит их с ног
Усталость великая, плач в поле слышится,
Нет никого, кто бы в горе помог.

Но сил добавляет им ненависть лютая,
Клятва священная в строй ставит их.
В прожилках межи – желтоглазые лютики,
Скорбь и величье в хлебах налитых.

На порохе с кровью опара замешена...
Хлеб для Победы, что твой пулемёт!
С любовью горбушку военную ешь – она
Горше, чем горе, и слаще, чем мёд.

**4. Любовь и ненависть**

В мирный дом непрошено и грубо
Ворвалась война, бряцая сталью.
Мы твердили, крепко стиснув зубы:
«Победим, во что бы то ни стало!»

Канонада тысячи орудий,
Нет, не небо, души бередила.
Столько зверства, ненависти в людях
Ты, война, зачем же пробудила?

Для чего ты бродишь по планете,
Наполняя мир нещадной болью?
Ведь никто у нас тебя не встретил
У ворот радушно хлебом-солью.

Воевать все как один мы выйдем
За свободу – мы непобедимы!
Чем врага сильнее ненавидим,
Тем сильнее любим край родимый.

**5. Егерме миллион**

Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,
Сугыш ул – аларга тик уен.
Ә минем уемда кайтмыйча калганнар –
Егерме миллион, егерме миллион.

Тол килеш картайды, агарды чәчләре,
Ишләрен тапмады күп куен.
Куенга алыр да терелтер идем мин...
Егерме миллион, егерме миллион.

Яз килгәч, шыталар кан төсле чәчәкләр,
Котлыйлар Җиңүне – ил туен.
Мәйданда ут яна, мәйданда – чәчәкләр...
Егерме миллион, егерме миллион.

Карыйм да кояшка, эндәшәм дөньяга:
Тынычмы күңелең, ни гамең, ни уең?
Мин түгел, мин түгел, эндәшә дөньяга
Егерме миллион, егерме миллион...

**5. Двадцать миллионов**

Двор на двор в войну играют мальчики-солдаты,
Из фанеры автоматы, из шарфов знамёна.
Вспоминаю не доживших до победной даты –
Двадцать миллионов, двадцать миллионов.

Седовласы стали вдовы, подросли сироты,
Разрослись под мирным солнцем кроны старых клёнов.
Оживить бы всех бойцов невозвратной роты –
Двадцать миллионов, двадцать миллионов.

По весне взойдут цветы цвета крови алой,
В День Победы слёз не счесть и не счесть поклонов.
Над могилами горят звёзды пятипалы –
Двадцать миллионов, двадцать миллионов.

Выйду в мирные поля и спрошу планету:
Хорошо ль тебе, Земля, с небом целоваться?
Нет, не я спрошу, а те, которых с нами нету –
Двадцать миллионов... двадцать... двадцать... двадцать...

# Яз

Утызы да тулмый, февраль киткән...
Урамнарга шыплап март тулган.
Агачларның саллы җәясенә
Ук түгел лә... яфрак тартылган.

Каргалар да безгә каркылдамый...
Без мәңгелек инде бу җирдә.
Бер туйганчы күккә карыйк әле,
Ике кулны куеп бөергә.

Кайгыларны салыйк гөрләвеккә,
Тургай итеп чөйик шатлыкны!
Яз хәбәрен ишетеп, барча кошлар
Безнең якка таба ашыкты.

Такса таксын дошман төрле исем...
Бар табигать безне үз итә...
Безне сагынып, кошлар килә бүген,
Күңелләрдә бүген боз китә.

# Весна

Март не позволил февралю
Хотя б ещё два дня продлиться.
И лист, как с тетивы стрела,
Вот-вот из почки устремится.

И кажется: нам вечно жить
Под этим вечным небосводом.
Давай с тобою постоим
И поглядим, как мчатся воды.

Давай ручьям доверим мы
Свои печали и невзгоды,
Давай с тобою встретим птиц,
Они к нам прилетят с восходом.

Душа ликует:
ледоход
И долгожданных птиц
прилёт!

# «Әфган дәфтәре»ннән

**1. Адаштым мин Кабул урамында**

Адаштым мин Кабул урамында...
Тел белмәгәч, дәшмим, сорамыйм.
Өмет өзеп, җан талкынган мәлдә
Кемдер дәште: «Сәлам, шурави!»

Нәрсә өчен җирдә яшибез соң?

Нәрсә өчен җирдә туабыз?
Мең сорауга җавап бирде кебек
Кинәт яңгыраган бу аваз.

 Япь-яшь солдат нидер сөйли миңа,
Кабалана, ымлый, ашыга...
Һәм аннары... чәчәк кадап куя
Мылтык көпшәсенең башына.

Күрсәтә ул аннан ал кояшка,
Күрсәтә ул таулар ягына.
...Беләм, дустым, берсүзсез дә аңлыйм:
Тынычлыкны җаның сагына.

Юлны өйрәт. Адаштым мин бүген...
Мин генәме? – Илләр адаша.
Тамашачы булып калып булмый,
Җирдә барса сугыш-тамаша.

Кырык бердә киткән ирләр кайтмый,
Алар әле һаман яуларда...
Шул елларның ачы кайтавазы
Ишетелә сезнең тауларда.

Тәмуг сыман кайнар урамнарның
Баса-баса утлы ташына,
Солдат белән җитәкләшеп чыктык
Мин югалткан юлның башына.

Борылды да аннан китеп барды,
Кул болгады: «Сәлам, шурави!»
Кочагына алып кысты аны,
Йотты аны Кабул урамы.

Шул солдатның кырыс елмаюы
Төшләремә мең кат керәчәк.
...Баш очында яна уртак кояш,
Мылтык көпшәсендә – ал чәчәк.

# Из «Афганской тетради»

### 1. Я заблудился в Кабуле

Чужую речь на улицах Кабула
понять не мог я, хоть кого зови...
Уже надежда выбраться уснула.
«Салям! – вдруг слышу. – Здравствуй, шурави!»

Афганца вижу, юного солдата.
Спешит и суетится паренёк.
И вдруг втыкает в дуло автомата
весенний распустившийся цветок.

Показывает им на солнце, горы

своей красивой, страждущей страны...
Я понял, не нужны нам разговоры:
желает сердце мира, тишины.

Путь укажи мне. Заблудился нынче
не только я, а многих стран синклит.
Свидетелем стоять – не наш обычай,
когда земля страдает и горит.

Тех, кто ушёл на подвиг в сорок первом –
не возвратить: они ещё в бою.
Крутые эти годы горьким эхом
вернулись в землю горную твою.

По огненным каменьям, адским кругом,
средь узких улиц нам пришлось идти,
чтоб вместе с молодым афганским другом
к потерянному выбраться пути.

Ну а потом ушёл он восвояси,
пожал мне только руку: «Шурави!»
Его Кабул принял в свои объятья,
усталые, бессонные, в крови.

Его улыбка, как в ночи оконце,
ещё не раз блеснёт в полночный срок...
В груди его – предутреннее солнце,
а над плечом – пылающий цветок.

**2. Мин Җәлилне укыдым**

Тау битендә, хәрби частьта...
Качкан чагы йокының.
Палаткада солдатларга
Мин Җәлилне укыдым.

Сөйләп бирдем язмышын да, –
Сүзгә-сүз, дим, бәйләнсен.
Җирдә муллык арткан чакта,
Артсын шигырь бәясе!

Тирә-юнь тын. Шомлы тынлык,
Килми сүзсез ятасы.
Күктәге ай әйтерсең лә
Гильотина балтасы.

Укы, диләр, тагын укы,
Күңел моңга сусаган!..
Эчте алар таңга кадәр
Шигырь тулы тустаган.

– Җәлил нинди булган? – диләр. –
Юашмы ул? Усалмы?..
Нәрсә әйтим? Мин үзем дә
Бүген ачтым Мусаны.

Шагыйрьләрнең язмышлары
Уртак, ахры, күрәсең...
Моабитка охшаттым мин
Пули-Чархи төрмәсен[1].

Ил буена шигырьләрнең
Төшкән чакта тиражы...
Шигырь укып, таң аттырдык,
Өнемме бу, миражмы?

Бәясе арта шагыйрьнең,
Афәт килгәндә илгә...
Солдат булып атакага
Барды бүген Җәлил дә.

Тау битендә, хәрби частьта
Укыдым мин Мусаны...
Шушы төнне минем өчен
Бар кеше намусланды.

**2. Читаю Джалиля**

На горе,
в палатке пыльной,
при бессонном огоньке
я читал стихи Джалиля
на родимом языке.

Я поведал о поэте:
краток был к бессмертью путь.
Чем труднее жить на свете,
тем стиха ценнее суть.

Ночь вокруг. Мрак страшен: вроде
и захочешь – не уснёшь,
и луна на небосводе,
словно гильотины нож.

Парни почитать просили:
жаждет этих строк душа!
До утра созвучья пили,
дух впивали, не дыша.

А каков он был обличьем,
Исполин земной красы?
Что сказать? Я только нынче
понял сам стихи Мусы.

У поэтов судьбы схожи,
непохожи лишь стихи.
Моабиты в мире тоже
на манер Пули-Чархи[1].

От границ страны далёкой

далеко пошёл тираж.
До зари звучали строки:
это явь или мираж?

Как растёт стихов значенье,
если бой – не стих, а быль!
Шёл в атаку, не в ученье,
в ряд с солдатами Джалиль.

На горе, к боям готовясь,
вновь звучат стихи Мусы.
Тает мрак, не дремлет совесть,
утра близятся часы.

**3. Йолдызлар белән янәшә**

*Советлар Союзы Герое хәрби очучы*
*В.Гайнетдинов истәлегенә*

Елыйсы да килә бүген,
Килә күк көләсе дә...
Карап барам... ак чалмалы
Һиндекуш түбәсенә.

Соры таулар, ак кыялар...
Күңел сыктый яшелгә.
Әй, Һиндекуш, кочагыңда
Яманлыкны яшермә!

Хәнҗәр кебек очлы кыяң
Җан ярама кагыла.
Кыялар да иминлекне,
Хөрриятне сагына.

Янәшәмдә – ак болытлар...
Кара төс юк биектә.
Тик агармый кара кайгы,
Ак болытка тиеп тә.

Биекләргә менгән саен,
Офык ягы яктыра.
Очам кебек йолдызларга
Хыялым канатында.

Сүнәр тиздән ай-йолдызлар,
Төн үтәр, сагыш узар.
...Кабыныр шулчак күңелдә
Зираттагы йолдызлар.

**4. Тыйнаклык**

Әфганстан – горур таулар иле...
Мин – Иделдән, иркен үзәннән.
Күзләремне ала алмый тордым
Ак пәрәнҗә япкан гүзәлдән.

Безнең кызлар хәзер ярымшәрә,
Шәрә йөрү бездә – «дәрәҗә».
Каплый алмас безнең гөнаһларны,
Яшерә алмас бары пәрәнҗә.

**3. Наравне со звёздами**

*Памяти Героя Советского Союза*
*военного лётчика В.Гайнетдинова*

То ли душат слёзы душу,
то ль рыдаю я средь тьмы:
вижу, близясь к Гиндукушу,
непорочные чалмы.

Горы жёлты, скалы белы,
где ж зелёные листы?
Гиндукуш, в свои пределы
много прячешь темноты!

Каждый пик, как штык на взводе,
в рану сердца мне проник.
О покое, о свободе
грезит каждый горный пик.

Сверху – облачное море,
снизу – чёрная страна.
Не отбеливает горя
облачная белизна.

Самолёт в полёте грозном.
Развидняется заря.
Распахну объятья звёздам,
о надежде говоря.

Ночь уходит, утро близко,
звёзды гаснут, но во мгле
звёзды скромных обелисков
ярче светят на земле.

**4. Скромность**

Афганистан – край горделивых гор.
Я – с Волги. Далека она уже.
В диковину не отводить мне взор
с красавиц в белоснежной парандже.

Открытость лиц давно у нас в ходу,
плеч нагота – достоинство у нас.
Что до греха – на счастье ль, на беду –
какая скроет паранджа сейчас?

Сезгә килгәч, калдым тыйнакланып,
Чистарды җан, уйлар үзгәрде.

Пәрәнҗәңнең бер почмагын гына
Күтәрсәңче, әфган гүзәле!

Башка берни кирәк түгел миңа,
Тик бер елмай, әгәр яраса...
Шәрә кызлар тыйнакланыр хәтта,
Күзләреңне сирпеп карасаң.

Серле булган саен арта икән
Гүзәллеге хатын-кызларның.
Еллар буе җуйган хисләремне
Монда табып, бүген кызардым.

Яхшыгамы, әллә ямангамы? –
Бер гасырда күпме үзгәрдек!
Пәрәнҗәсе сагындырмый аның...
Сагындыра тыйнак гүзәллек.

Йөрәк менә нигә каккан икән,
Менә нигә җаным сызлаган...
Күзләремне ала алмый тордым
Таулар кебек горур кызлардан.
Я стал скромней, попав в далёкий край,
Я помыслами чист, нет в сердце лжи...
Красавица-афганка, только край
приподними укромной паранджи!

В чужих краях нет помысла странней,
лишь краешек улыбки, блеск очей...
Не стали б наши девушки скромней,
из-под ресниц увидев свет лучей?

Чем больше тайны, тем сильней влечёт
она к себе, такие вот дела.
Здесь все мечты я знал наперечёт,
но эта тайна в краску вогнала.

К добру ли это или не к добру?
Назад уже не преступить черты.
Скажу: тоска по парандже – совру!
Но скромность, тайна, кротость красоты.

Вот отчего душа болит, прости,
забилось сердце, замутился взор...
Стоял, не в силах взгляда отвести
от девушек, что краше белых гор.

## Өмет

Больницаның ап-ак стенасы
Ничәнче кат керде төшемә.
...Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?

Яктыра да тәрәз, тагын сүнә...
(Ник сүнәсең? Сүнмә, гел яшә!)
Ә больница шушы тәрәз аша
Җиһан белән гүя сөйләшә.

Янәшәдә генә Идел ага,
Болыт йөзә күктә агарып.
Бер кайгысыз кошлар агачларда
Уйный әле һаман шаярып.

Яр буеннан парлар үтеп бара,
Бала-чага таган атына.
Больницага хәбәр җибәргәндәй,
Төпсез күктә йолдыз атыла.

...Ә палата ап-ак... чиста, тынлык...
Оҗмахы да шундый булмасын...
«Сәгатең бор. Туктамасын, кызым...
Ә аннан соң... дару юлларсың...»

...Больницаның ап-ак стенасы
Бүген тагын керде төшемә.
Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?!

## Надежда

Всё тот же сон ночами донимает:
Больничный запах, белая стена...
И кто-то штору тяжко поднимает
И опускает. А она – черна.

Окно то просветлеет, то померкнет...
«Не меркни, – говорю ему, – светись!
Пусть каждый день
с инспекторской проверкой
В окно моё заглядывает жизнь...»

И плещется волной большая Волга,
Плывут над ней бесшумно облака.
И птицы за окном воркуют долго,
И счастливы они наверняка.

Гуляют пары, разговор их весел,
Шумит-кричит мальчишечья орда,
А вечером в бездонном поднебесье
Улыбкой ободрит меня звезда.

В палате чисто, и бело, и тихо...
Не жизнь, а рай... Как хорошо... И всё ж:
«Сестрица, заведи часы, пусть тикают...
Ну а потом... лекарство принесёшь...»

Навязчивый, ночами донимает

Всё тот же сон: белым-бела стена...
И кто-то штору тяжко поднимает
И опускает. А она – черна...

## Елмайсын сабыйлар

Агара, чалара әнием чәчләре...
Агармый тик кайгы карасы.
Мәйданда Мәңгелек ут яна,
Ул – минем йөрәгем ярасы.

Сабыйлар елмайган чагында,
Кайгының юллары ябыла.
Кешеләр кайгысын таратып,
Елмайсын сабыйлар тагын да!

Мин беләм: бары тик бер адым
Кайгылар, бәхетләр арасы.
Менә шул мәңгелек арада
Сулкылдый йөрәгем ярасы.

Бәхетләр ягына юл тотып,
Безгә бит әле күп барасы.
Сабыйлар елмайса дөньяда,
Төзәлер йөрәгем ярасы.

* * *

Светлеют пряди
        наших матерей,
А горя цвет
        вовеки чёрным будет.
Горит огонь
        в ладонях площадей,
Он
    боль в моём тревожном сердце
                будит.

Беду и счастье разделяет
                шаг.
Да, это так.
        Так говорят в народе.
И этот шаг
        нельзя пройти никак,
Чтоб не изранить
        сердце по дороге.

Но не страшны беда мне и гроза,
Пока под небом
        голубой Вселенной
Я буду видеть
            детские глаза,
Наполненные
            смехом
                и весельем.

## Тормыш Сабантуе

Билне буып, без көрәшкә чыктык
Иң беренче булып мәйданга.
Егылсак та, җир күтәрде безне,
Юатырга картлар бар янда.

Яманлыкны күрсәк, Җәлилләрдәй,
Без атылып кердек уртага.
Дөреслекне эзләп, дөнья кичтек,
Зарланмадык бер дә юл тарга.

Алда өч юл – әкияттәге кебек...
Бәхетлесен, дидек, кем сайлар?
...Юл өзелде... Сугыш... Яуга китте
Мылтык буе уйчан малайлар.

Тешне кысып, без көрәшкә чыктык
Беренчеләр булып мәйданга.
Үтте сугыш, йөрәкләрне таптап,
Күмеп безне яшькә һәм данга.

...Чаба атлар – тормыш Сабантуе!
Кемнәр кыю? – Билдән алышыйк!
Малайларның йөрәк түрендәге
Батырлыкны эзләп табышыйк!

## На майдане жизни

Опоясав себя кушаками,
Мы выходим, борцы, на майдан.
И совет, и завет
стариками
Нам в напутствие каждому дан.

Мы учились борьбе у Джалиля,
Против варварства выйдя на бой.
Мы крутые дороги торили
И не плакали перед судьбой.

Мы у правды прошли подготовку,
Мы мужали в суровые дни.
Были мальчики ростом с винтовку,
Когда взяли винтовку они.

Зубы сжав,
на майдане сраженья
Знали точно, за что мы дрались:
Есть у жизни одно продолженье –
Молодая, растущая жизнь.

...Мчатся кони – ветра Сабантуя!
Мы с мальчишками рядом стоим,

И ликует майдан, салютуя
Новым, храбрым батырам своим!

## Бөеклек

Туган чакта бөтенебез тигез.
Ә үлгәндә? – Белмим ул ягын.
Һәрбер аксак нигә Байрон түгел?
Һәр саңгырау түгел Бетховен?

Һәр акыллы нигә бөек түгел,
Һәрбер батыр түгел Газинур[1]?
Һәр авыру Тукай булса әгәр,
Бер минутта мең том язылыр!

Һәр кешедә баш бар, кул, йөрәк бар,
Бөек фикер килә һәркемгә...
Ләкин аны күпләр таный алмый.
Таныганнар кыймый әйтергә.

Фикер җирдә шәрә килеш йөри –
Яңа туган сабый баладай.
«Асрамага бала бирәм», – диеп
Чыгаралар аны базарга.

Каксалар да, суксалар да күп чак...
Бөтен кеше аңа бик якын.
Итекче карт Вәли[2] аңлый аны,
Ишетә аны саңгырау Бетховен.

Ашаталар, сөеп үстерәләр,
Кидерәләр тыйнак киемгә...
Ул дөньяга чыга. Килеп керә
Бәхет булып һәркем өенә.

Намуссызлар өчен намус була,
Өметсезләр өчен – ак өмет.
Җан өләшә җаны үлгәннәргә,
Ул терелтә тик бер кагылып.

Урамнарда йөри ятим фикер,
«Асрамага, – диеп, – кем алыр?»
...Һәрбер сукыр нигә Гомер түгел,
Батыр түгел һәрбер Газинур?!

## Величие

Мы все равны в своём рожденьи.
Так было, будет так всегда.
И всё же байроновский гений
Не всякому хромому дан.

Не всяк, чахоткою страдавший, –
Тукай. Не всяк слепой – Гомер.

Не всякий, силой обладавший,
Был Газинуром[1], например.

Но к каждому, я в том уверен,
Приходит истина подчас.
Стучится в запертые двери:
«Открой мне двери!» – просит нас.

«Открой – и я в тебе открою
Божественный высокий дар».
А мы же, приютив, порою
Её выносим на базар.

Но непродажна, неподкупна,
На нас не держит зла она.
Вали-сапожнику[2] доступна,
Глухому Людвигу верна.

Пускай ты глух – пусть не Бетховен,
Пускай ты слеп – пусть не Гомер –
Пред истиной немногословной
Открой кромешной ночью
Дверь.

## Картлар зары

Безнең йөрәкләрне
сулган дисез,
анда
мәхәббәт чишмәсе
күптән кипкән,
ялкыннары сүнгән дисез...
Коры әйберне
ялкын тиз алганын
белмисез.

## Жалоба старца

Не говорите, что у старца
Остыло сердце,
Не говорите, что в душе
Иссох родник любви.
Известно ль вам:
Чем суше хворост,
Тем легче он
Огню подвержен?

## Вакыт

Арыдым бүген.
Дөньядагы барлык сәгатьләрне
туктатып,
бер йоклыйсы иде.
Әй, Җир!

Үзең белән әйләндереп
тилмертмәче мине.
Әй, Җир!
Бер минутка гына туктыйсы иде.
Арыдым бүген.
Кичтән бирле
үзем генә киләм.
Әй, Җир!
Кирегә әйлән әле!
Ул бит артта калды...
Әй, Җир!!!
...Тыңламый Җир...

## Время

Устал сегодня я.
Земля!
Останови свои часы,
Дай мне заснуть,
Моя Земля!
Меня вращением своим
Ты закружила, унесла.
Остановиться б хоть на миг,
Устал сегодня я, Земля.
Я с вечера иду один.
Земля, поворотись назад:
Любовь осталась позади!
Земля!!!
...Не слушает Земля...

## Бумеранг

Ташладым мин юлда дусларымны...
Дошман булып кире кайттылар.
Кайттылар да, ялгышларым җыеп,
Таш урынына йөзгә аттылар.

Онытттым мин бик күп чибәрләрне...
Гайбәт булып кире кайттылар.
Вәгъдәләр һәм антларымны җыеп,
Йөз бәягә артык саттылар.

Ялгышлар һәм гайбәтләрне җыеп,
Еллар елгасына аттым да...
...Чыгалмыйча шунда баттылар.

Һәм тагын да чибәр кызлар булып,
Шатлык булып, якын дуслар булып
Минем янга кире кайттылар.

## Бумеранг

Я друзей потерял по дороге.
Возвратились врагами они.

Их обиды лежат на пороге
грудой камня – попробуй сверни.

Я красавиц не помню. В тумане
проступают их лица едва.
Пересуды о каждом «романе»
троекратно вернула молва.

Я собрал все обиды и сплетни,
размахнулся – и в Лету швырнул...

И поток, к моему удивленью,
и друзей, и любимых из Леты
шумной радостью в сердце вернул.

## Тормыш асылы

Ни җәй түгел, ни көз түгел җирдә –
Табигатьнең яңа фасылы...
Оныттылар кошлар сайрауларын,
Нидер көтеп җил дә басылды.

Кышкы пристаньдай буп-буш йөрәк.
Сөенеч тә юк, каргыш, ачу да.
Туй төшәсе йорттай... күңелемнең
Капкалары шәрран ачылган.

Җиңел үлем булмый. Качып елый,
Болытларга качып елый җәй...
Көз – җиңүче! Көз тантана итә!
Ике бите ике алмадай.

...Тынычлыгын бүлдерергә куркып
Исеме юк шушы фасылның,
Әкрен генә көзгә кереп барам,
Аңлый барам тормыш асылын.

## Суть жизни

В природе и не лето и не осень –
Знать, мало году четырёх времён.
Уходит – тает птиц разноголосье,
И ветер погрузился в странный сон.

И сердце зимней пристанью пустует,
Ни радости и ни проклятья в нём.
Душа моя, – как будто перед туем
Ворота распахнувший настежь дом.

Без боли смерти нет. И плачет лето,
Украдкой в тучи грустные сбежав.
А осень торжествует час победы,
Как яблоко созревшее, свежа.

Мне б чудо это не спугнуть словами,
Его не просто выразить, назвать.
Тихонько-тихо в осень я вплываю,
Суть жизни начинаю понимать.

## Төсләр

**1. Үгиме әллә мин?**

Бихисап дөньяда буяулар...
Җир үзен яшелгә буяган...
Тургайлы үзәнгә карыйм да
Җанымны җылыткан уй табам.

Кызыл төс күрдисәм, кан уйный,
Зәңгәр төс күңелгә моң сала.
Нигәдер төсләргә табынам,
Тормышым бертөсле булса да.

Сап-сары көземә күз багып,
Җаныма сагышлы уй табам,
Салават күперенә сокланып,
Уйларда, хисләрдә буталам.

Үгиме әллә мин дөньяда?!
Илдә җәй, ә миндә кыш һаман...
Буранда югала бар төсем –
Дөньяда ак, кара төс кала.

**2. Җир белән саубуллашу**

Нишлим инде, тагын китәм...
Сау бул, җир, сау бул, күгем.
Мәңге монда яшь түгәргә
Мин ялгыз каен түгел.

Кара балчык – матәм кебек,
Кызыл балчык – кызыл кан,
Сары балчык – минем кайгы,
Ак балчыгың... югалган.

Барысын ташлап китәм инде,
Миңа зәңгәр төс кирәк.
Бәлки, дулкыннар күтәрер
Биеккәрәк, өскәрәк...

**3. Диңгездә**

Саумы, диңгез, саумы, давыл!
Саумысыз! дип кычкырам.
Дулкыннары, мине күреп,
Каршыларга чыктылар.

## Разноцветье

**1. Разлад**

Какое в мире разноцветье!
Душе пора добро творить.
Цвета бесчисленные эти
Должны б мне душу озарить.

Но нет! С цветами я в раздоре:
Печалит сердце синева,
Пурпур зари кричит о горе,
О зле – зелёная трава.

Мне желтизна разлуку прочит,
Слезами вечными страша.
И радуги принять не хочет
В разлад пришедшая душа.

Не пасынок я в мире этом,
Тогда на что же ополчась,
Я только с чёрно-белым цветом
Согласен в этот грустный час?..

**2. Прощание с землёй**

Прощай, земля.
Довольно лить мне слёзы.
Меня лазурь морская позвала.
Неужто я – плакучая берёза,
Что к берегу корнями приросла?

Твой чернозём лишь траур означает,
Я в красной глине вижу крови цвет,
У жёлтой глины цвет моей печали,
А светлой глины для меня здесь нет.

Прощай, земля.
Меня уже встречает
Морская гладь, где город Коктебель.
Меня волна в ладонях укачает –
Лазурная морская колыбель.

**3. Море**

Кричу я морю:
– Здравствуй, голубое!
Вот, наконец, я встретился с тобой.

Тауларга менеп кычкырдым,
Үзәнгә өстән карап:
«Монда алтын балык иле,
Монда ярык тагарак!»

Таулар күкрәп куәтләде,
Тик эндәшмәде үзән...
Алтын балык та килмәде...
Яшь тәгәрәде күздән.

Ярык тагарак югалган,
Ак йолдызлар сүрелгән;
Үләннәре, томырылып,
Ярга таба үрелгән.

Диңгез зәңгәр түгел икән,
Дулкыннар бишек түгел.
Бар өметемне югалттым...
Калды түгәрәк күгем.

**4. Диңгез белән саубуллашу**

Кара балчык – кызлар чәче,
Кызыл балчык – таң кебек,
Сары балчык – сагыну күк,
Ак балчыгым – ак өмет.
Җирдә – шатлык, җирдә – җылы,
Җир – кояшның сүзе күк!

Ә диңгездә акчарлаклар –
Канатлы сагыш кебек.
Оно бежит навстречу мне прибоем,
У ног моих колышется прибой.

Взойдя на горы, я окинул взглядом
Морской простор.
И показалось мне:
Вот избавление от разлада –
　　　　рядом!
И золотая рыбка на волне!

...Но нет!
Туманом море вновь закрыто,
В горах умолк торжественный мой крик,
На берегу – разбитое корыто.
Уходит в море золотой плавник...

Лазурь темнеет и тускнеет солнце,
Над морем опускается гроза.
Морской прибой угрюмо в скалы бьётся
И застит взор солёная слеза...

**4. Прощание с морем**

...У чёрной глины – цвет косы любимой,
А у красной – отсвет песни соловья,
У жёлтой с белой – цвет неповторимой
Любви твоей, любимая моя.
Земля – как многоцветная лужайка.
Под радугой – сияющая даль.

...А там, над морем, с криком вьётся чайка –
Далёкая крылатая печаль.

# Көз

Аягүрә йортлар елап тора...
Кызганалар бугай дөньяны.
Көз китергән сары күлмәк киде
Җир шарының менә бу ягы.

Саубуллашмый-нитми кошлар китте,
Кошлар китте кояш артыннан.
Кошлар халкын уйлап басып тордым,
Чапкан чакта төшеп атымнан.

Җир нарасый, сабый бала кебек,
Юынды да һаман юынды.
Чистармады лəкин пычрагыннан...
...Мин югалттым бугай юлымны.

Мине ташлап аргамагым качты,
Чабып китте дала ягына...
..................
Ияренə менгермəсə дөнья,
Асылынып барыйк ялына!

Кабат кайтмас яфракларын сагынып,
Бар агачлар ятып елады.
Агачларга кушылып, мин еладым,
Сагындым да үткəн елларны.

Урамнарда йөрдем дəрвиш кебек...
Ай урамда йөзə, ай арган.
Боз астында катып калыр кебек...
Айны кудым пычрак сулардан.

Кышны уйлап, моңсуланып йөрдем,
Каурыйларын койган казлардай.
Бар өметем минем кышта инде...
Кыш артында чөнки язлар бар.

* * *

Земля в осенние оделась платья,
Гуляет ветер хмурый по полям.
Мне кажется, земля вот-вот заплачет
Вослед кричащим в небе журавлям.

Не попрощавшись, улетели птицы
В невидимые дальние края.
Не знал я, что мой конь гнедой умчится,
Когда с него на землю спрыгнул я.

Не знал я, что мой конь не возвратится,
Что навсегда его поглотит даль...
Гнедому в гриву надо бы вцепиться,
Да в гриву жизни вцепишься едва ль!..

Деревья жаль, что обронили листья,
И жаль луну: замёрзнет подо льдом...

Скорей, зима!
Пусть вьюга отозлится.
Зато весна – за вьюгою потом!

## Көз офыгы

Көз әле алтынсу биләүдә –
Мин инде җәйләрне сагынам.
Сагышның мәйданы киңәя,
Офыклар киңәйгән чагында.

Соңгы кат сөенеп калыйм дип,
Каеннар таң белән торганнар.
Күңелгә көз моңын иңдереп,
Каңгылдый һавада торналар.

Яңгырый хушлашу авазы
Күкләрдән, таулардан – бар яктан;
...Йөрәгең өзелер бер мәлдә,
Агачтан өзелгән яфрактай.

Тик һаман кошларга ияреп
Талпына күңелем югары.
Бәхетнең үзенә илтә күк
Күктәге кошларның юллары.

## Осенний небосклон

Деревьев позолота молодая
Своим сияньем высветила даль.
Летит листва к земле, в душе рождая
По лету уходящему печаль.

Берёзы на обветренном пригорке
Внимают грустно тишине полей.
Тревожит душу запах прели горький
И крик летящих к югу журавлей.

И кажется, что лето не вернётся,
И слышится метели дальний свист.
Сейчас как будто сердце оборвётся,
Как с ветки клёна пожелтевший лист.

И всё-таки надеждою согрета
Душа средь засыпающих долин.
Ей ведомо:
          не на зиму, на лето
Указывает журавлиный клин...

* * *

Һәр көз саен таллар телсез калган,
Телсез калган юкә, имәннәр:
Яфракларын җилгә чәчә-чәчә,
Язга кадәр алар үлгәннәр.

Яфраклары үлгән, карлар күмгән,
Җир җылыткан ләкин тамырын...
Көзге җилләр телем алсалар да,
Тамырымда мәңге калырмын.

* * *

Каждую осень
листва облетает с деревьев,
каждую осень
лишаются речи они.
Видно, навек заведён
календарь этот древний:
листья лепечут
в весенние ясные дни.

А до весны
будут теплить надежду им
корни.
Было так прежде
и будет всегда наперёд...
Знаю, умолкну и я
с тихой болью во взоре.
Но не умру никогда,
коль мой стих
не умрёт.

* * *

Көз.
Чибәр кызый,
елый-елый,
ияләшкән күлмәген алыштыра.
Бөтен гәүдәсеннән,
кызыктырып,
байлык, муллык ташып тора.

Көз.
Оялчан шул кызый...
Күрсәтергә курка байлыгын.
Керфекләрне бөгә, күзгә өрә,
биткә каплый
сөттәй яулыгын.

Көз.
Түз, йөрәгем,
түз.

* * *

Осень.
Красивая девушка в плаче
меняет привычное платье своё,
и запахом плоти её,
не иначе,
пронизано всё –
дерева, ковыльё.

Осень.
Стыдясь наготы, затаится
красивая девушка.
Кружит в степи платок кружевной
или белая птица...
А может, на счастье
упала ресница...

Осень.
Терпи,
моё сердце,
терпи.

## Туган көндә

Сорамагыз аның яшен бүген,
Юрамагыз ниләр көтәсен.
Тәрәзәдән ташып аксын шатлык,
Көлүеннән кайгы үртәлсен.

Көнләшүдән күзен чекерәйтеп,
Тәрәзәдән йолдыз карасын.
Шундый кичләр якынайта бугай
«Бүген» белән «Бәхет» арасын.

Очар кошлар көздән качып китте,
Чәчәкләр дә бетте бит сулып.
Ә ул һаман яз гөлләре төсле,
Тамчы да юк анда моңсулык.

Ул беләдер дус һәм туганнарның
Бар афәттән аны йоласын.
Көз аенда туган кеше өчен
Көзге яңгыр әнә еласын.

Илнең генә түгел, Җир шарының
Аңлый алган уен, бар гамен...
Ул кояшы төсле шушы йортның,
Ул – шатлыгы шушы дөньяның.

Сорамагыз аның яшен бүген,
Юрамагыз ниләр көтәсен.
Бөтен дөнья бүген, бәхет теләп,
Күккә кадәр аны күтәрсен!

## В день рождения

Не спрашивайте возраст у неё,
Загадывать о будущем не надо.
Она жила и проживёт своё,
И каждый день да будет ей отрадой!

Пускай в её окно глядит звезда,
От зависти пред юностью сгорая.
И пусть любовь взаимная всегда
Её среди счастливых выбирает...

Осенних птиц приблизился отлёт,
Трудны и высоки у них дороги.
А у неё в душе весна цветёт,
И в сердце нет ни грусти, ни тревоги.

И что с того, что дождь осенний льёт,
Что небеса грозятся холодами?
Её от холодов убережёт
Любовь друзей и слово доброй мамы.

## Диңгез дулкыны

Тын торган ярларын калдырып,
Юл тотты диңгезгә дулкыннар.
Аларны сагынып, ярларның
Йөрәге бик озак сулкылдар.

Шундый зур, шундый киң һәм иркен,
Куәтле һәм назлы ул диңгез.
Теләсәң, тын гына күккә бак,
Теләсәң, талганчы йөз дә йөз.

Ияртте аларны үзенә
Диңгезнең ягымлы агымы...
Тик бераз баргач та, иңнәргә
Усал җил куллары кагылды.

Калтырап, сискәнеп куйдылар
Дорфалык күрмәгән дулкыннар...
Әйттеләр: «Без – диңгез баласы,
Тияргә нинди, – дип, – хакың бар?»

Ә җилләр шаркылдап көлделәр,
Ачынып кычкырды акчарлак.
Аңлады дулкыннар бик тиздән:
Җилләргә иярми юк чара.

Ә җилләр әйләнде давылга...
Диңгездә тоз исе, яшь исе.
Кабатлый туктаусыз дулкыннар:
«Бик килә яш-ши-се, яш-ши-се!»

Яр калган тарафка күз атып,
Борылды кирегә дулкыннар.

Ярларны тапканчы, йөрәкләр
Шашынып, авыртып сулкылдар.

Җил белән көрәшеп талдылар,
Күзләрдән тамчылар чәчрәде...
Кайттылар дулкыннар тын ярга...
...Агарган, чаларган чәчләре.

## Эскиз моря

Жарким днём покатились валы
На просторе морском порезвиться...
Долго будет у старой скалы
В сердце грусть одиночества биться.

А простор – и широк, и далёк –
Задыхается воображенье:
Вдоль плыви иль плыви поперёк,
Или будь облаков отраженьем!

А волнам лишь на воле легко,
А волнам хорошо на просторе...
Далеко, далеко, далеко
Увлекло их течение моря.

И у самого края земли
Ветры дикие их поджидали,
И, дождавшись, игру завели –
Рвали в клочья и в бездну кидали.

Беспощадная эта игра
Даже чаек с ума посводила.
«Нам к скале возвращаться пора –
Покидают последние силы...»

И вернулись прибоем они,
Поседевшие в страхе и горе.
Тихо звёздные плещут огни,
Отражаются в ласковом море...

* * *

Зәңгәр кабырчыклар эзләп килдең.
Табалмагач, ташка эндәштең.
Үтенүләр, ялварулар нигә?
Аңлыймыни диңгез күз яшен?..

Диңгездә тик зәңгәр сагыш яши.
Бу хаклыкны күптән ачканнар.
Бәхетеңне генә югалтырсың,
Йөрәгемә төшмә, акчарлак.

* * *

Кул астында кәгазь булмаганга,

Календарьга яза башладым.
Ел үтүгә, иске календарьны,
Белмим, кемдер ертып ташлаган.

Ак карларга язсам, язын эреп,
Ташыр иде шигъри елгалар...
Ә мин яздым гади календарьга,
...Ә ул инде беткән... югалган...

* * *

За синими ракушками пришла ты
на дикий берег, камни вопрошала.
Но просьба безответна, хоть крылата,
и глухо море с самого начала.

Когда грохочет море многопенно,
лишь синяя тоска – его утайка.
Ты счастье потеряешь непременно –
на сердце не пикируй мне, о, чайка!

* * *

Для стихов в том году не хватало бумаги,
я записывал их на листочках календаря.
Год прошёл, календарь потерялся...
Лучше было б писать на ладони или на снегу...
Только не было у меня ни бумаги, ни снега,
ни ладошки белой твоей...
И писал я стихи на листочках календаря.

* * *

Сәгатенә ничә шигырь туа...
Бер көн җитәр,
язалмассың, тема бетәр, дисеңме.
Дөнья бетеп,
тик берүзем калсам да,
берне түгел,
бер мең тема табармын.
Һич югында:
«Дөнья бетте,
шигырь яши!» –
диеп язармын.

* * *

Сколько стихов рождается ежечасно!
Мне говорят,
что наступит день,
и писать будет не о чем –
темы иссякнут.

Я не согласен.
Я знаю:
даже если останусь один на земле,

всё равно в моём сердце будут
звучать
сотни, тысячи стихотворений.

В крайнем случае
я напишу:
«Вот пришёл конец света,
а поэзия всё живёт».

* * *

Минем турыда шигырь язмыйсың дип,
Үпкәләгән әле хатыным.
Бүген тагын ашы тозлы булган,
Кабартмыйча җәйгән ястыгын.

Төннәр буе күздән кичеп ятам
Идән белән түшәм арасын...
Тозлы ашын, ястыкларын ташлап,
Балачакка килә кайтасым.

Үткәннәрне күпме сагынып була?
Яз, ди, чынны, яз, ди, бүгенне,
Йолдызлар да гел ай күңелендә...
Җир соң әллә матур түгелме?

Барын беләм, барын күрәм, иркәм:
Шигырь белән бөтен җир тулы.
Нишлим? – Бүген карбыз кискән чакта,
Ай турында тагын җыр туды.

* * *

Снова разобиделась жена,
что о ней в моих стихах ни слова.
Вновь пересолила суп она,
жёсткую постель постлала снова.

Я не сплю. Простор квартиры скуп –
в потолок я упираюсь взглядом...
Бросить бы уют, солёный суп,
в детстве скрыться – ведь оно же рядом!

– Всё хандра, все мысли о былом, –
говорит жена мне поминутно. –
К звёздам ночью тянешься и днём,
на земле-то разве неуютно?

– Дорогая, грешен, сознаюсь,
много тем в быту для вдохновенья!
Только... Если режу я арбуз –
о луне пишу стихотворенье.

## Беренче кар

Җиргә тагын карлар ява инде,
Җир төренә тагын аклыкка.
Җир яшерә үзенең гөнаһларын,
Җир күмелә сафлык, пакьлеккә.

Нигә миндә кышлар булмый икән?
Күңелемдә нигә көз генә?
Гөнаһларым җирнекеннән күбрәк...
Карый алмыйм хәтта көзгегә.

Кайнарлыгым карлар басар иде,
Охшап калыр идем болытка...
Кешеләр кышка керә. Ә мин янам
Көз калдырган моңсу бу утта.

Ап-ак карлар гүя шәфкать кызы,
Ап-ак карлар җирне дәвалый...
Ә мин янам, ә мин һаман янам,
Мин әйтерсең көзнең дәвамы.

## Первый снег

Опять на землю падают снега,
Чисты земли безгрешные убранства.
Но никогда не заметёт пурга
Моей души осеннее пространство.

В моей душе осенние огни
Горят, пылают золотом опавшим,
И не дают покоя мне они,
И не дают забыть о дне вчерашнем.

Нет, не остудит, видно, душу мне
Ни первый снег, ни третий, ни последний.
Горю, горю на медленном огне
Осенних дней, осенних озарений...

## «Әтисез» бала

Ул,
Дөньяга килгәнче үк,
Йодрыклары белән бәреп,
әтисен чакырды.

## Безотцовщина

Он,
до появления на свет,
стуча маленькими кулаками,
звал отца своего.

## Декабрь

*Яшьли вафат булган дустыма*

Кайгыларның кара төсен күрдем,
Әй күрәсе иде бер кадер!..
Өләшенеп бетте көз алтыны...
Күңелләргә керде декабрь.

Җәйләр, көзләр күргән бу күңелем
Бик сусаган икән ак төскә.
Кыш салкыны баса кайнарлыгым,
Күңелләрдә ап-ак җил исә.

Ап-ак уйлар, ак хыяллар килә,
Туй күлмәге керә төшемә...
Ап-ак кышның салкын мәгънәсенә
Кемнәр генә икән төшенә?

Ап-ак карлар күмде кайгыларым...
Кар астында калды ул кабер...
Салкын да мин, ап-ак та мин бүген...
Күңелемә керде декабрь.

## Декабрь

*Памяти друга, рано ушедшего из жизни*

Душе навеки ярких красок хватит,
Казалось мне. Мир ликовал, горя.
Но осень, своё золото растратив,
Впустила в душу птицу декабря.

Она коснулась белыми крылами
Печальных струн встревоженной души,
И белые ветра по-над долами
Запели песнь в декабрьской тиши.

О чём ветра декабрьские плачут?
О том ли, что всему придёт конец?..
Во сне я видел свадебное платье
И над фатою ледяной венец.

Летят снега на холм земли далёкой,
Летят на холм. Вот замели уже...
Душа подобна птице одинокой...
Уже декабрь властвует в душе...

* * *

Аның гомере шатлыклардан – кайгы,
Кайгылардан шатлык эзләп үтте.
Бар төшләрен гел яманга юрап
Өзә иде безнең үзәкне.

Менә бүген, бар нәрсәсен биреп
Берни алмый, бу дөньядан китте.

Кабере өстендәге япь-яшь каен
Аңлый алмас инде бәхетне.

* * *

Вся жизнь его
была невзгод навал,
замешенных на капельке
удачи.
Он каждый сон свой
грустно толковал
и этим нас печально
озадачивал.

Он всё раздал,
себе оставив слёзы.
Нам видеть было их
не суждено.
...Над головой его
растёт берёза –
и ей изведать счастья
не дано...

## Шәһәр пейзажы

Төтен ташый завод торбасыннан,
Каплап китәр төсле кояшны,
Урам агачының тамырлары
Инде күпме капшый бу ташны.

Кызыл карлар шушы җирдә ява...
Язлар монда көзгә охшаган.
Кибетләрдә генә үсә гөлләр,
Бар тереклек монда тышауда.

Кибетләрдә генә чәчәк, гөлләр,
Базарларда гына алмалар...
Елга буйларына качып киткән
Яшел өянкеләр, ак таллар.

Инде мең кат башын киссәләр дә,
Юк, табигать әле үлмәгән!
Кояш нуры кылыч кебек уйный,
Хәнҗәр кебек калка үләннәр.

## Городской пейзаж

Заводская дымная труба.
Через дым уже не видно солнца.
Корень – в камень,
ветка в небо рвётся:
С городом неравная борьба.

Красный снег здесь валится с небес,

Здесь весна – больное время года.
Ты погибнешь, дорогая, здесь,
Уходи из города, природа!

Уходи к излучине реки,
В даль лугов,
где есть для лёгких воздух,
Где стоят живые цветники,
Где ещё сияют в небе звёзды.

Над кудрями бедной головы
Ножницы безжалостные свищут!
...Но кинжалы яростной травы
Неустанно новой схватки ищут!..

## Чәчәк бәйләме

Язмыш мине алга әйдәде дә...
Гомер бирде, чәчәк бәйләмедәй.

Яңгырларда калдым, күрдем карны.
Гөлләремне юлга сибеп бардым.

Килеп җиттем инде җир читенә.
Ялгыз бару юлда, һай, читен лә.

Үткәннәргә борылып карадым да...
Чәчәк эзләп, кире барам менә.

Кайда соң син, кайда, умырзаям?
Үткән мәллә яшь гомерем зая?

Кайда соң сез, кайда гөләпләрем?
Үтәлгәнме олы теләкләрем?

Бәхетлеме соң мин, әйт, ромашка!
Хыялларым чынга ашканнармы?

Язмыш мине тагын алга әйди,
Чәчәкләрдән бәйләм бәйли-бәйли.

## Ищу подснежник

Была судьба догадлива иль нет,
моих годов вручая мне букет?..

Шёл через снег я, шёл через дожди,
Цветами путь засыпал позади...

Теперь я возвращаюсь по следам,
Своим не верю собственным глазам:

Ищу подснежник, где подснежник мой?
Он снегом скрыт, он занесён зимой.

Ищу тюльпан, ну где же мой тюльпан?
Укрыл его густой, слепой туман.

Ищу ромашку – вижу: лепесток
Вдруг вылетел печально из-под ног...

Скажи, судьба, добра ты или нет,
Коль даришь мне опять живой букет?

# Эчтәлек

# Содержание

Дулкын биеклеге. *Р.Зәйдулла* ....................
Материк поэзии. *Р.Мустафин* ....................

Мизгел ................................
Мгновение. *Перевод Ю.Дулесова* ..................
«Минем гомер әле башланмаган...» ..................
«Я жизнь свою ещё не начинал...». *Перевод Д.Даминова* .......
Яшьлек ................................
Молодость. *Перевод Д.Даминова* ..................
Бәхет ................................
Счастье. *Перевод И.Фаликова* ....................
«Кабул булмый нигә бар теләгем?..» .................
«Конечно, судьба не щедра на подарки...» *Перевод Д.Даминова* ..
Язгы шигырь ..............................
Весенний стих. *Перевод И.Фаликова* ................
Гашыйк булгач .............................
Любовь... *Перевод Р.Валеева* ....................
Ядкарь ................................
Память. *Перевод И.Фаликова* ....................
Метаморфозалар ...........................
Превращения. *Перевод И.Фаликова* .................
Яңгыр иле ..............................
Страна дождя. *Перевод Д.Даминова* .................
«Мин күктәге йолдызларга гашыйк...» ................
«Сколько звёзд во тьме высокой!..». *Перевод Д.Даминова* ......
Алма ................................
Яблоко. *Перевод Д.Даминова* ....................
Мәхәббәт ................................
Любовь. *Перевод Д.Даминова* ....................
Кабатлана язлар ............................
Вернётся весна. *Перевод И.Фаликова* ................
Соңгы үтенеч ..............................
Чтоб ты знала. *Перевод А.Адиля* ...................
Рәсем ................................
Рисунок. *Перевод В.Баширова* ....................
Вәгъдә ................................
Обещание. *Перевод В.Баширова* ...................
Тамашачы бугай... ..........................
Зритель. *Перевод Д.Даминова* ....................
«Иң беренче төшкән карлар...» ....................
«Говорят, что первый снег...». *Перевод И.Фаликова* .........
Гаепле ................................
«Всему виной весна. Она...». *Перевод Д.Даминова* .........
«Сине эзләп, мин тауларга мендем...» ................
«Взошёл я на крутые горы...». *Перевод Д.Даминова* ........
«Син күрмисең, әйе, күрмисең син...» .................
«Останься, проникнись участьем!..». *Перевод Д.Даминова* .....
«Көзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...» .................
«Я зеркала и окна разобью...» *Перевод Н.Алешкова* .........

«Бертуктаусыз уйный, шаярасың...» ..................
«Ничто тебя сегодня не тревожит...» *Перевод Д.Даминова* .....
«Иң беренче...» .............................
«Любимая!..». *Перевод Д.Даминова* .................
Сине озатканда .............................
Твой отъезд. *Перевод Д.Даминова* ..................
Сөйләмә мәхәббәт турында .......................
Не говори мне о любви. *Перевод Д.Даминова* ............
Чакырма ................................
Не зови. *Перевод Д.Даминова* .....................
Урман чишмәсе .............................
Лесной родник. *Перевод Д.Даминова* .................
Мәхәббәттә алданганнар җыры .....................
Утраченная любовь. *Перевод Д.Даминова* ..............
«Бүген тагын мине ташлап киттең...» .................
«Ушла...». *Перевод Д.Даминова* ...................
«Мажаралар дөньясында...» ......................
Экспромт. *Перевод Д.Даминова* ...................
«Юкәнең – балланып килгән...» ....................
«Была пора цветенья клёна...». *Перевод Д.Даминова* ........
«Хатларыңны утка яктым синең...» ..................
«Сегодня я сжёг твои письма...». *Перевод Д.Даминова* .......
«Онытылды инде күз яшьләре...» ...................
«Ну что ж! Освободился я от слёз...». *Перевод Д.Даминова* .....
Рельслар ................................
Рельсы. *Перевод Д.Даминова* .....................
«Елмаерга өйрәтермен сине...» ....................
«Я научу улыбаться тебя...». *Перевод Д.Даминова* ..........
Әкият .................................
Сказка. *Перевод Д.Даминова* .....................
Соңгы мәхәббәт .............................
Последняя любовь. *Перевод Д.Даминова* ...............
«Төн карасына каләмемне манып...» .................
«В чернила ночи окуная...». *Перевод Д.Даминова* ..........
Саубуллашыр өчен баргач... ......................
«К былому возврат невозможен...». *Перевод Д.Даминова* ......
Тау кызына ..............................
Горянке. *Перевод Д.Даминова* .....................
Кыз сурәте ...............................
Портрет девушки. *Перевод Д.Даминова* ................
«Тау юлыннан килүеңне күреп...» ...................
«Слово «любовь»...». *Перевод Р.Валеева* ...............
Дулкын .................................
Волна. *Перевод И.Фаликова* ......................
«Елый-елый, сугыша-сугыша, җирдә...» ................
«Плача и скорбя, искал свободы...». *Перевод Д.Даминова* ......
Тормыш ................................
Жизнь. *Перевод И.Фаликова* .....................
Бер көнем ...............................
Мой день. *Перевод Д.Даминова* ....................
Кеше ..................................
Человек. *Перевод Л.Барбас* ......................
Идел .................................
Идель. *Перевод Р.Бухараева* .....................
Борынгы Болгарда ..........................
В стране булгар. *Перевод Р.Бухараева* ................
Музейда янгын .............................
Пожар в музее. *Перевод Р.Бухараева* .................
«Кара җирдән ап-ак бәхет эзләп...» ..................
«Зачем, имея ум и сердце...». *Перевод Д.Даминова* ..........
Шагыйрь ................................
Поэт. *Перевод Д.Даминова* .......................
Һәйкәлләр ...............................
Памятники. *Перевод Д.Даминова* ..................
Мәңгелек ут ..............................
Вечный огонь. *Перевод Д.Даминова* ..................

«Мин – яшьтәше атом бомбасының...» .................
«Я – сверстник бомбы атомной. Как раз...». *Перевод И.Фаликова* .
Тормыш арифметикасы .........................
Арифметика жизни. *Перевод А.Адиля* .................
«Мин яу булып түгел, яучы булып...» .................
«Нет, я не ратником – послом...». *Перевод Д.Даминова* .......
Көтү ..................................
Ожидание. *Перевод Д.Даминова* ....................
Иң беренче тирәк ............................
«Меня приучали к работе...». *Перевод Д.Даминова* ..........
«Дөнья матур, Такташ җырлаганча...» ................
«Такташ, понятен мне такой восторг...». *Перевод И.Фаликова* ....
Бер кайтырмын әле... ..........................
Я ещё вернусь. *Перевод Р.Бухараева* ................
Трамвайда ................................
В трамвае. *Перевод Р.Бухараева* ....................
Авылга кайту .............................
Возвращение. *Перевод Д.Даминова* .................
Сабантуй ................................
Сабантуй. *Перевод Д.Даминова* ....................
Авылда туй ..............................
Свадьба в деревне. *Перевод Д.Даминова* ..............
Мәҗүси ................................
Язычник. *Перевод Н.Алешкова* ....................
Юлларым ...............................
Дороги. *Перевод Д.Даминова* .....................
Урман .................................
Лес. *Перевод И.Фаликова* .......................
Аучы ..................................
Охотнику. *Перевод О.Охапкина* ..................
Язгы урман ...............................
Весенний лес. *Перевод Д.Даминова* .................
Дисбе ..................................
Чётки. *Перевод Д.Даминова* ......................
Игенчеләр нәселе ............................
Род земледельцев. *Перевод Д.Даминова* ................
«Яшьләрне бит галәм кызыктыра...» .................
«Нас манит космос...». *Перевод Д.Даминова* .............
Җиргә мәдхия .............................
Ода Земле. *Перевод Л.Барбас* .....................
Казан белән саубуллашу ........................
Прощание с Казанью. *Перевод А.Адиля* ................
«Бу төн шундый озын...» .......................
«Ночь до того глубока...». *Перевод И.Фаликова* ...........
Самолётта ...............................
В самолёте. *Перевод А.Гаврилова* ..................
Казан поезды .............................
Казанский поезд. *Перевод Н.Нимбуева* ................
Театр ..................................
Театр. *Перевод Д.Даминова* ......................
Иске көймә зары ............................
Печаль старой лодки. *Перевод Д.Даминова* ............
Кояш көлә ...............................
Смеётся солнце. *Перевод Д.Даминова* ................
Диңгездә ява яңгыр ..........................
Море штормит. *Перевод И.Фаликова* ................
Утлы хәтер *(Реквием)* ........................
1. Кырык беренче ел Сабантуе ..................
2. Хатлар язам ...........................
3. Сугыш икмәге ..........................
4. Мәхәббәт һәм нәфрәт .....................
5. Егерме миллион .........................
Огненная память *(Реквием) Перевод Н.Ишмухаметова* .......
1. Сабантуй сорок первого . ..................
2. Письма с фронта. .......................
3. Хлеб войны. ..........................

4. Любовь и ненависть. ......................
5. Двадцать миллионов. ....................
Яз ....................................
Весна. *Перевод Д.Даминова* .....................
«Әфган дәфтәре»ннән .........................
1. Адаштым мин Кабул урамында ................
2. Мин Җәлилне укыдым ....................
3. Йолдызлар белән янәшә ....................
4. Тыйнаклык ...........................
Из «Афганской тетради» *Перевод Р.Бухараева* ...........
1. Я заблудился в Кабуле. ...................
2. Читаю Джалиля. ........................
3. Наравне со звёздами. ............... ......
4. Скромность. ................... ......
Өмет ..................................
Надежда. *Перевод Д.Даминова* ...................
Елмайсын сабыйлар ..........................
«Светлеют пряди...». *Перевод Д.Даминова* .............
Тормыш Сабантуе ...........................
На майдане жизни. *Перевод Д.Даминова* ..............
Бөеклек ................................
Величие. *Перевод Д.Даминова* ...................
Картлар зары .............................
Жалоба старца. *Перевод Д.Даминова* ................
Вакыт .................................
Время. *Перевод Д.Даминова* ....................
Бумеранг ................................
Бумеранг. *Перевод Н.Алешкова* ...................
Тормыш асылы ............................
Суть жизни. *Перевод А.Гаврилова* .................
Төсләр .................................
1. Үгиме әллә мин? ........................
2. Җир белән саубуллашу ....................
3. Диңгездә ............................
4. Диңгез белән саубуллашу ...................
Разноцветье. *Перевод Д.Даминова* .................
1. Разлад .............................
2. Прощание с землёй ......................
3. Море ..............................
4. Прощание с морем .......................
Көз ...................................
«Земля в осенние оделась платья...» *Перевод Д.Даминова* .....
Көз офыгы ...............................
Осенний небосклон. *Перевод Д.Даминова* .............
«Һәр көз саен таллар телсез калган...» ................
«Каждую осень...». *Перевод Д.Даминова* .............
«Көз. Чибәр кызый...» ........................
«Осень. Красивая девушка в плаче...». *Перевод И.Фаликова* ...
Туган көндә ..............................
В день рождения. *Перевод Д.Даминова* ................
Диңгез дулкыны ............................
Эскиз моря. *Перевод Д.Даминова* ..................
«Зәңгәр кабырчыклар эзләп килдең...» ................
«За синими ракушками пришла ты...». *Перевод И.Фаликова* ....
«Кул астында кәгазь булмаганга...» .................
«Для стихов в том году не хватало бумаги...». *Перевод Э.Блиновой* .
«Сәгатенә ничә шигырь туа...» ....................
«Сколько стихов рождается ежечасно!..». *Перевод Н.Алешкова* ...
«Минем турыда шигырь язмыйсың дип...» .............
«Снова разобиделась жена...». *Перевод Р.Бухараева* ........
Беренче кар ..............................
Первый снег. *Перевод Д.Даминова* .................
«Әтисез» бала ............................
Безотцовщина. *Перевод Р.Валеева* ..................
Декабрь ................................
Декабрь. *Перевод Д.Даминова* ....................

«Аның гомере шатлыклардан – кайгы...» ...............
«Вся жизнь его...» *Перевод Д.Даминова* ..............
Шәһәр пейзажы ............................
Городской пейзаж. *Перевод И.Фаликова* ..............
Чәчәк бәйләме .............................
Ищу подснежник. *Перевод Д.Даминова* ...............

Разил Вәлиев *(Тормышы һәм иҗаты)* ................
Разиль Валеев *(Жизнь и творчество)* ................

Разил Вәлиев турында .........................
О Разиле Валееве ...........................

Басма китаплары ...........................
Изданные книги ............................

Компакт-дисклар, аудио- һәм видеокассеталар ............
Компакт-диски, аудио- и видеокассеты................

Иҗаты турында ............................
О творчестве ..............................

Литературно-художественное издание

**Валеев** Разиль Исмагилович

**ОСЕННЕЕ ОЗАРЕНИЕ**

*Стихотворения*

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

**Вәлиев** Разил Исмәгыйль улы

**КӨЗ БАЛКЫШЫ**

*Шигырьләр*

Мөхәррире *Г.Ф.Сибгатова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.06.2011. Форматы 60х108 $^{1}/_{16}$.
Басма табагы 21,0. Тиражы 3000 д. Заказ Р-789.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843)519-45-22
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**
«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.